На территории Республики Башкортостан живёт 66,1% населения муниципальных образований бассейна, 29,9% – в Республике Татарстан и 3,9% – Оренбургской области. Самым населенным муниципальным образованием в регионе является Туймазинский район – 131,0 тыс. чел. (20,5%), далее идут г. Октябрьский с населением в 114,1 тыс. чел. (17,8%) и Белебеевский район с населением в 95,7 тыс. чел. (15,0%).

На территории Республики Татарстан наиболее населенным является Азнакаевский район (60,1 тыс. чел.), где живёт 9,4% населения региона.

Из пяти городов бассейна три (Октябрьский, Туймазы и Белебей) расположены на территории Башкортостана и два (Азнакаево и Бавлы) – в Татарстане. По объёму отгруженных товаров и услуг по всем видам деятельности в регионе лидирует г. Октябрьский (24,8%), среди районов – Белебеевский (17,3%), Азнакаевский (17,0%) и Туймазинский (14,7%). Самыми маломощными являются Шаранский (0,4%), Бакалинский (0,4%) и Бижбулякский (0,5%) районы. По объёму сельскохозяйственного производства в регионе лидирует Татарстан с 60,5% против Башкортостана с 35,6% и Оренбургской области с 4,2%. Наиболее крупными производителями сельскохозяйственной продукции являются – Актанышский (14,4%), Туймазинский (13,6%), Азнакаевский (12%), Мензелинский (9,9%) и Муслюмовский (9,2%) районы. На Татарстан приходится 50,5% пашни муниципальных районов бассейна р. Ик, на Башкортостан – 40,7% площади, на Оренбургскую область – 8,8%. Как видно, наиболее продуктивно пашня используется в Татарстане, затем – в Башкортостане.

Экономическое будущее зависит от инвестиций в основной капитал. В данном случае в инвестициях на душу населения лидируют муниципальные образования Республики Татарстан (на 18% выше среднего показателя по региону) (см. табл.1).

*Таблица 1.*

***Показатели сравнительного анализа***

| Районы/ Критерий | Площадь районов, км² | Чис-сть населения, чел. | Объём отгруж. товаров и услуг по всем видам деят-и (без субъектов малого предпринимательства, тыс. руб. | Объём инвестиций в основной капитал за счет средств муницип. бюджета тыс. руб. | Площадь пашни, га | Объём с/х производства, тыс. руб. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Республика Башкортостан | | | | | | |
| Бакалинский | 1951 | 25726 | 543652,5 | 11571 | 70151,61 | 2385216 |
| Белебеевский | 1911,20 | 95653 | 22764052,1 | 26492 | 47638,69 | 2136871 |
| Бижбулякский | 2133,90 | 21458 | 602223,8 | 19838 | 70624,19 | 2425096 |
| Ермекеевский | 1436,58 | 15695 | 1232481,4 | 9050 | 55120,51 | 1983725 |
| Туймазинский | 2403,52 | 130977 | 19282964,3 | 64073 | 60666,95 | 7110669 |
| Шаранский | 1384 | 19364 | 519490,6 | 6605 | 42704,3 | 2092948 |
| г.Октябрьский | 105,83 | 114100 | 32603708,6 | 63293 | 459,81 | 364864 |
| Республика Татарстан | | | | | | |
| Азнакаевский | 2168,65 | 60129 | 22302575,7 | 25437 | 101590,41 | 6276302 |
| Актанышский | 2037,8 | 29384 | 6340444,5 | 11592 | 93978,05 | 9604398 |
| Бавлинский | 1222,85 | 34479 | 12941547,8 | 9175 | 50842,4 | 3330730 |
| Мензелинский | 1919,75 | 27686 | 5397129,4 | 5869 | 75217,4 | 5173062 |
| Муслюмовский | 1464,3 | 19326 | 1364279,9 | 64959 | 72754,4 | 4822713 |
| Ютазинский | 760,57 | 20248 | 3989857,6 | 2935 | 36888,3 | 2423721 |
| Оренбургская область | | | | | | |
| Абдулинский | 1700 | 25189 | 1460643,9 | 20995 | 75175,7 | 2191569 |

Экономическое развитие региона, начиная с военных лет, определяется добычей нефти. Разрабатываются Туймазинское, Бавлинское, Ромашкинское месторождения нефти. Начало добычи нефти обусловило возникновение городов, обслуживающих данное производство. Если г. Белебей изначально строился как уездной город, Туймазы – как железнодорожная станция, то г. Октябрьский строился для нефтяников по принципу соцгорода. Так назывался первоначально и сам город.

Можно отметить, что башкирская часть региона в настоящее время является более индустриально развитой и населенной. Часть Татарстана – более аграрная, но развивающаяся более динамично. Поэтому 7–8 тыс. чел. из данных районов Башкортостана вахтовым методом работают в Татарстане. Что касается ежедневных поездок на работу (маятниковая миграция), то она также достигает значительных величин. Причем, имеют место поездки в обе стороны границы.

Экономический центр региона – г. Октябрьский – является одним из двух центров трансграничной Альметьевско-Октябрьской агломерации [Трансформация: 2020. С. 55]. В этой агломерации близко расположены города Октябрьский и Туймазы, Бавлы, поселки городского типа Уруссу, Ютазы, которые образуют экономическое сердце региона.

Бассейн р. Ик населен многими народами. Преобладают, как было уже сказано, татары и татароязычные башкиры. Они составляют 402 570 человек против 182345 человек русского населения. Татароязычное население преобладает в г. Октябрьский, в Бакалинском, Бижбулякском, Ермекеевском, Туймазинском и Шаранском районах Башкортостана и во всех районах Республики Татарстан, образующих данный регион. Русское население региона в основном сосредоточено в Белебеевском (25,4%), Туймазинском (16,3%) районах Башкортостана, если быть точнее, в соответствующих городах, а также и в г. Октябрьском (24,3%) (см. табл.2).

*Таблица 2.*

***Национальный состав населения по данным территориям***

| Районы | Численность населения, чел. | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Всего | Башкиры, чел. | Русские, чел. | Татары, чел. |
| | Республика Башкортостан (2010 г.) | | | |
| Бакалинский | 28776 | 4964 | 6400 | 15360 |
| Белебеевский | 101896 | 12158 | 46248 | 23230 |
| Бижбулякский | 26080 | 5730 | 3059 | 6805 |
| Ермекеевский | 17165 | 4898 | 2021 | 6232 |
| Туймазинский | 131225 | 43903 | 29739 | 50205 |
| Шаранский | 22514 | 5589 | 2600 | 7404 |
| г.Октябрьский | 109474 | 14406 | 44379 | 41346 |
| | Республика Татарстан (2012 г.) | | | |
| Азнакаевский | 60129 | 339 (чуваши) | 7206 | 55578 |
| Актанышский | 29384 | 526 (марийцы) | 209 | 30989 |
| Бавлинский | 34479 | 2060 (чуваши) | 7346 | 23414 |
| Мензелинский | 27686 | 795 (марийцы) | 10403 | 17646 |
| Муслюмовский | 19326 | 598 (марийцы | 1388 | 19675 |
| Ютазинский | 20248 | 192 | 4604 | 16114 |
| | Оренбургская область (2010 г.) | | | |
| Абдулинский | 25189 | 4681 (мордва) | 16743 | 5731 |
| Численность населения МО бассейна ИК | 653571 | 91840 | 182345 | 319729 |

В регионе также живут чуваши, марийцы и мордва. В Бижбулякском районе чуваши являются самым многочисленным народом. Достаточно много чувашей проживают также в Белебеевском, Шаранском, Бавлинском районах, марийцев – в Шаранском районе. В Абдулинском районе Оренбургской области много мордвы.

Переход на рыночные отношения способствует межтерриториальной мобильности населения, ведет к укреплению связей внутри региона. В связи с этим следует отметить большое значение развития экономических и культурных связей в регионе.

## Литература

1. Трансформация социально-экономического пространства региона: методология и практика: монография/под общ. ред. д.э.н. Р.Ф. Гатауллина. Уфа: ИСЭИ УФИЦ РАН, 2020. – 296 с.

***И.К. Фазлетдинов***

# ФОЛЬКЛОРДА – ТУГАН ЯК ТАРИХЫ

*(«Башкортостан татарлары фольклоры» сериясен төзү тәҗрибәсеннән)*

***Аннотация:*** *Әлеге язма Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында «Башкортостан татарлары фольклоры» дип аталган яңа сериянең беренче өч китабы нәшер ителүгә багышланган. Автор биредә Башкортостанда яшәүче татарларның фольклор хәзинәсен өйрәнү тарихына күзәтү ясый, сериягә караган җыентыкларны төзү өчен фактик материал сайлап алуның методологик принципларын ача. Башкортостан татарлары фольклорының башка милләтләр белән тарихи һәм рухи-мәдәни бәйләнешләренә бәйле төбәк үзенчәлекләрен өйрәнүгә мәкаләдә аерым игътибар бирә. Автор фикеренчә, әлеге төбәк татарларының авыз-тел иҗаты әсәрләре Урал алды төбәгендә яшәүче башка төрки, фин-угыр һәм славян халыкларының тәэсирен кичерсә дә, гомумтатар фольклорының аерылгысыз өлеше булып тора. Урындагы фольклор үрнәкләренең идея-тематик эчтәлеге, алардагы архаик сюжет һәм мотивлар биредә яшәүче татар халкының борынгылыгын раслый.*

***Төрәк сүзләр:*** *фольклор, серия, Башкортостан татарлары, халык иҗаты, тарих, риваять, легенда, мифология, традиция.*

***Аннотация:*** *Статья посвящена изданию в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан трех книг новой серии «Фольклор татар Башкортостана». В ней проанализирована история научного изучения устного народного творчества татар данного региона; раскрыты методологические принципы создания свода, отбора фактического материала. Особое внимание уделяется изучению локальных особенностей фольклора татар Башкортостана, обусловленных исторически закономерным целостным сочетанием и взаимодействием в нем разных этнических традиций. Автор делает вывод о том, что произведения устного народного творчества татар Башкортостана являются неотъемлемой частью общетатарского фольклора, в то же время характеризуясь сильным влиянием традиций, сюжетов и мотивов других тюркских, финно-угорских и славянских народов, веками проживающих на данной территории. Обилие архаических сюжетов и мотивов в идейно-тематическом содержании произведений фольклора свидетельствует о древности татарского населения данного региона.*

***Ключевые слова:*** *фольклор, свод, серия, татары Башкортостана, народное творчество, история, предание, легенда, мифология, традиция.*

Татар халкының дүрттән бер өлеше генә Татарстанда яши. Калган дүрттән өч өлеше Русия Федерациясенең һәм дөньяның төрле почмакларында гомер кичерә. 2010 елгы халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча, Татарстаннан көнчыгышта урнашкан Башкортостан Республикасында гына да 1 миллионнан артык татар кешесе яшәгәнлеге мәгълүм. Сан буенча биредә татарлар өченче урынны алып тора, бу исә республикада яшәүче халыкның 24,8% дигән сүз [Булатова: 2021. С. 3]. Табигый, Башкортостан территориясендә яшәүче татар милләте вәкилләренең рухи мирасы – галимнәрдә зур кызыксыну тудыра торган өлкә, бу мирасны барлап, туплап өйрәнү гуманитар фәндә әһәмиятле бурычларның берсе.

Халыкның үз башыннан кичергән вакыйгалары турында сөйләгәнгә күрә, фольклор әсәрләре әдәби кыймматкә дә, тарихи әһәмияткә дә ия. Күренекле фольклорчы Ф.И. Урманчеев сүзләре белән әйтсәк, «риваятьләр, легендалар, мифлар теләсә кайсы халыкның иң борынгы һәм борынгы тарихын өйрәнүдә мөһим чыганакларның берсе булып торалар» [Урманче: 1998. С. 86]. Чыннан да, халык иҗаты жанрларында алдагы буыннарның тормыш фәлсәфәсе, тәҗрибәсе, тарихи үткәне, хәтере чагылыш таба.

Хәзерге Башкортостан Республикасы территориясендә яшәүче татарларның этногенезы, тарихи, мәдәни һәм тел үзенчәлекләре тикшеренүчеләр тарафыннан шактый өйрәнелгән, тарихчы һәм телче галимнәрнең бу өлкәгә кагылышлы әһәмиятле хезмәтләре дөнья күргән [Булатова: 2021; Давлетшина: 2001; История: 2016; Исхаков: 1993; Кузеев: 1992; Национально-культурные: 2003; Рамазанова: 1984; Рамазанова: 1993; Рахматуллин: 1988; Сибәгатов: 2020; Татары: 2021; Юлдашбаев: 1972 һ.б.]. Шулай булса да, биредәге татар телле халыкның милли үзбилгеләнеше мәсьәләсендә бәхәсләр әлегә кадәр тынганы юк. Бу җәһәттән Башкортостан республикасында борын-борыннан җирле халыкның зур өлешен тәшкил итеп яшәүче татарларның фольклор әсәрләрен җыеп, туплап бирү, тикшерелә торган ареалда татар халык авыз иҗатын җыю һәм өйрәнү тарихына, татар фольклорының биредәге торышына күзәтү ясау, безнең карашыбызча, бүгенге көндә актуаль мәсьәләләрнең берсе булып кала.

* * *

XVI–XVIII гасырларда Русия дәүләте күп кенә яңа территорияләргә, шул исәптән, хәзерге Башкортостан җирләренә дә ия булгач, төбәкләрне өйрәнү өчен, күп санлы гыйльми экспедицияләр оештырыла. Мәсәлән, 1768 елда, Русия Фәннәр академиясенең карары буенча, П.С. Паллас

җитәкчелегендәге экспедиция – Урал алдына, Көнчыгыш Себергә, Байкал күле артына, И.И. Лепехин җитәкчелегендәгесе Идел буена һәм төньякка юнәлә. Ике төркем дә бүгенге көндә Башкортостанга караган җирләр аша үтә. Алларына төбәкнең табигый-географик шартларын, ресурсларын, халыкның көнкүрешен өйрәнү бурычы куелса да, тикшеренүчеләр моның белән генә чикләнмичә, җирле халыкларның этнографиясе, фольклоры турында кызыклы гына мәгълүматлар теркәп калдыралар. Ике тикшеренүче дә үзләренең урындагы татарлар белән очрашуларын тасвирлап узалар. П.С. Паллас Уфаның көнбатыш, көньяк һәм төньяк-көнчыгышында татарлар яшәвен билгеләп үтә һәм алар нигезләгән авылларның Агыйдел белән Ык елгалары арасында аеруча күп булуын ассызыклый. Тикшеренүче Уфа һәм Казан татарлары арасында телдә, гореф-гадәтләрдә бернинди дә аерма булмавы турында яза, бары тик Уфа татарларының хатын-кыз киемнәре казаннныкыларга караганда күпкә матуррак икәнлеген билгели [Паллас: 1786. С. 7–11].

П.С. Паллас халык авыз иҗатына артык игътибар бирми. Шулай да аңа урындагы татарлар һәм башкортлар арасында таралган риваять, легендалар белән эш итәргә туры килүенә ишарәләр бар. Җир-су атамаларына бирелгән саран гына аңлатмалар шул хакта сөйли [Паллас: 1786. С. 58–59].

Икенче сәяхәтче И.И. Лепехин үзенең юлъязмасында хәзерге Башкортостан җирләренә урнашкан бер төркем татар авыллары аша үтүен билгеләп уза. Болар: Бакай, Байтуган, Камышлы, Усман, Авыргазы елгасы буендагы Корманай, Бәгәнәш, Сәет, Бугалыш. И.И. Лепехин аерым географик объектларга тасвирлама биргәндә аларның атамаларының мәгънәсен, тарихын ачыклый [Лепехин: 1771. С. 196; 1772. С. 7, 29, 141, 242].

1895 һәм 1897 елларда С.Г. Рыбаков тарафыннан тупланган йөздән артык татар һәм башкорт җыры ноталары белән бергә Петербургта басылып чыга [Рыбаков: 1895; 1897]. Аларның кайберләренең барлыкка килү тарихларын тасвирлаган риваятьләр дә китерелә. Бу әсәрләр шактый кыскартылып бирелсә дә, С.Г. Рыбаков хезмәтенең әһәмияте зур: монда күпчелек тарихи җырларның көй, сүз һәм риваять синтезы рәвешендә яшәвен ачык күзалларга мөмкин.

XIX гасыр азагында хәзерге Башкортостанның төньяк-көнбатышын үз эченә алган Уфа губернасында яшәүче татарларның теле, этнографиясе, фольклоры белән кызыксыну кискен көчәеп китә. Н.Ф. Катанов, Уфа губернасының Бәләбәй өязенә килеп, биредә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләрен аларның фольклор әсәрләре нигезендә өйрәнә һәм, Казанга кайткач, шул хакта өч фәнни хезмәт язып чыга [Катанов: 1898; 1900; 1901]. Монда ул Урал алды татарларыннан язып алынган берничә җыр, бәет һәм мөнәҗәт тә китерә.

1906 елда тарихчы һәм тел галиме Г.Н. Әхмәров Вятка һәм Уфа губерналарына килеп, җирле типтәрләрнең тел үзенчәлекләрен һәм этногенезын тикшерә. 1908 елда дөнья күргән «Типтәрләр һәм аларның килеп чыгышы» исемле мәкаләсендә ул «типтәр» атамасының килеп чыгышы турында халык арасында таралган берничә этнонимик риваять китерә [Ахмаров: 1907]. Галим фикеренчә, «бүгенге көндә типтәрләрнең күпчелеген татарлар тәшкил итә, дин, тел һәм гадәтләре, шулай ук торак урыннарының атамалары аларның Казан һәм Вятка губерналарыннан чыгуын һәм шушы губерна татарлары, ягъни Казан татарлары белән туганлыкларын дәлилли» [Ахмаров: 1907. С. 17–18].

1914–1915 елларда М.А. Васильев Идел-Урал төбәге буенча сәяхәт итеп, биредә яшәүче татарлар арасында таралган 60тан артык әкият, легендаларны җыеп, урысчага тәрҗемә итеп, 1924 елда аерым китап итеп бастырып чыгара [Васильев: 1924]. Шунысы куанычлы – биредә бүгенге көндә Башкортстанга караган территорияләрдә яшәүче татарлар арасыннан табып алынган легендалар да теркәлә. Мәсәлән, «Шүрәлене ничек алдарга» дигән хикәятне автор Стәрлетамак өязе, Миркәтле волосте, Толбазы авылында язып ала [Васильев: 1924. С. 175] (бүгенге көндә әлеге авыл – Башкортостанның Авыргазы районы үзәге), «Сак-сок» легендасын Бәләбәй өязендә кәгазьгә терки [Васильев: 1924. С. 169].

1910 елның 15 апрелендә Казанның «Шәрык клубы»нда укылган «Халык әдәбияты» исемле лекциясендә мәшһүр әдибебез Габдулла Тукай татарлар һәм башкортлар арасында таралган «Тәфтиләү», «Сак-сок», «Җизнәкәй» кебек халык җырларын анализлый, шунда ук аларның барлыкка килүе турындагы риваятьләрне дә китерә [Тукай: 2006. Б. 185–204]. Ул фольклор әсәрләрен җыю һәм өйрәнү эшенә аерым бер игътибар бирергә кирәклеге турында әйтә.

XX гасыр башында татар халкының, шул исәптән Уфа һәм Оренбург губерналарында яшәүче милләттәшләребезнең легенда-риваятьләрен, авыл тарихларын, башка фольклор әсәрләрен җыю, өйрәнү, фәнни анализлау, популярлаштыру өчен «Шура» журналы зур көч сала. Аның мөхәррире, күренекле мәгърифәтчебез Риза Фәхреддинов Килем авылында *(хәзер Башкортостанның Бүздәк районына карый. – И.Ф.)* хезмәтче Галләметдин Сәйфетдин улыннан морза Йосыф Тәфкилевнең үлеме турындагы риваятьне язып алып, бастырып чыгара; «Тәфтиләү» җырын һәм аның тарихын нәшер итә [Тәфтиләү: 1915. 97–99 бб.]; шулай ук туган як тарихын өйрәнүгә багышланып, үз эчләрендә күп санлы легенда һәм риваятьләрне анализлаган гыйльми мәкаләләр дә нәкъ шушы «Шура» журналында дөнья күрә [Вәлиди: 1913. 109–113 бб.; Дәүлиханов: 1915. 153–159 бб.].

Татар фольклорын өйрәнү эшенең төп юнәлешләрен билгеләүчеләрдән, тумышы белән хәзерге Башкортостанның Авыргазы районы Солтанморат авылыннан булган бөек әдибебез Галимҗан Ибраһимовның исемен аерым атарга кирәк. 1926 елда «Безнең юл» журналында аның «Тел, әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы. Татар халык әдәбияты турында» исемле зур гына мәкаләсе басылып чыга [Ибраһимов: 2019. 259–263 бб.]. Монда әдип хәтта тупланган фольклор материалларын да бастырып чыгару мөмкинлекләре чикле булуы хакында әйтә һәм бу мәсьәләдә Башкортостан татарларының авыз-тел иҗатын өйрәнү эшенең торышына аерым туктала. «Мәсәлән, Бөре кантоныннан Гата Исхакый иптәш тарафыннан татар әкиятләре җыелган. Барлыгы 31 дәфтәр, 500 битләр чамасы. Карар күптән булса да, бастырып чыгаруның юлын таба алганыбыз юк. Фазыйл Туйкин иптәшнең «Ил әдәбияты» дип җыйган кыйммәтле материаллары байтак ятты-ятты да, басар өчен чара булмаганлыктан, рәнҗеп, шелтәләп үзенә кире сорап алды. Большевик мөхәррир Афзал Таһиров иптәшнең дә яхшы материаллары бар. Якын арада Сәйфи Кудаш иптәш хат язып әйтә: «Җыйган нәрсәм бар, җибәрәм», – ди. Мәрхүм шагыйрьнең – Бабичның җыйганнары да шулай ук сакланып торалар. Болардан күренә ки, хәзер бездә халык әдәбиятын җыю төрле җирдә, төрле рәвештә башланган, моны бер җиргә туплап, тикшереп, коллективның хезмәте рәвешендә бастырып чыгару һәм тикшерүнең вакыты җиткәнлеге бик ачык күренәдер» [Ибраһимов: 2019. 260–261 бб.], – дип, Галимҗан Ибраһимов Башкортостан җирлегендә яшәүче татарларның фольклорын өйрәнү эше канәгатьләнерлек дәрәҗәдә алып барылмавын билгели. Шунда ук ул татар фольклорының Казан татарларының иҗаты белән генә чикләнмәвен, аның башка өлкәләрдә һәм республикаларда яшәүче татарлар арасында булган фольклор белән баетылырга тиешлеген әйтә. «Әле бездә моңарчы җыелганы башлыча Казан татарлары эчендә җыелганнар. Хәзер башка кабиләләргә дә кул салырга кирәк» [Ибраһимов: 2019. 262 б.], – ди ул һәм шунда ук, «җыйган вакытта һичнәрсәне үзгәртмәү, бозмау, халык авызында ничек ишетелгән, шул көенчә язып алу – беренче шарттыр. <...>. Кайдан-кемнән, нинди кабиләдән, кай районнан алынганын, әлбәттә, әйтеп җыярга, язарга кирәк» [Ибраһимов: 2019. Б. 261], – дип, фольклор җыюның төп фәнни кагыйдәләрен бирә.

Галимҗан Ибраһимов биредә татар халкын алты «кабилә»гә – Казан татарлары, Касыйм татарлары, мишәрләр, алатырлар, төмәннәр, типтәрләргә бүлә [Ибраһимов: 2019. 261 б.]. Күренекле тел галиме Р.Г. Әхмәтьянов, «кабилә» сүзенең рус телендәге «племя, род, клан» дигән терминнарга туры килүен күрсәтә [Әхмәтьянов: 2015. 332 б.], гомерен татар халкының рухи мирасын өйрәнүгә багышлаган язучы Адлер Тимергалин «кабиләчелек»

сүзе астында «провинциализм» дигән мәгънә ятуын билгели [Тимергалин: 2017. 28 б.]. Шулай итеп, Галимҗан Ибраһимов бу сүзләре белән татар халкының бер төбәктә генә яшәп, бер төрле генә булмавын, киресенчә, Евразия киңлекләре буенча сибелгән татарларның милли фольклорын, аның үзенчәлекләрен өйрәнү кирәклеген ассызыклый.

Хәзерге Башкортостанга караган җирләрдә туып үскән күренекле татар фольклорчылары Нигъмәт Хәким (*Кыйгы районының Еланлы авылы*) һәм Нәкый Исәнбәт (*Салават районының Нәсибаш авылы*) биредә яшәүче милләттәшләренең авыз-тел иҗаты үрнәкләрен җыюга сизелерлек өлеш кертсә дә, 1960-нчы еллар уртасына кадәр бу эш системалы рәвештә алып барылмый, фрагментар характерда гына була. Башкортостандагы татар халык иҗаты үрнәкләрен биредә яшәүче башка милләтләр фольклор әсәрләре белән чагыштырма-тарихи планда гыйльми анализлау өчен вакыт, гомумән, килеп җитмәгән була әле.

Башкортостандагы татар фольклор мирасының системалы рәвештә җыела һәм өйрәнелә башлавы 1960-нчы еллар уртасында фәнгә килгән Риф Мөхәммәтҗанов исеме белән бәйле. Биредә галим турында кыскача белешмә биреп китү дә урынлы булыр.

Риф Мирхәбибулла улы Мөхәммәтҗанов 1939 елның 2 июлендә Башкортостанның Ярмәкәй районы Аксак авылында дөньяга килә. Монда сигезьеллык мәктәптә белем алгач, 1957 елда Иске Турай урта мәктәбен көмеш медаль белән тәмамлый. 1957–1962 елларда Башкорт дәүләт университетының филология факультетында татар-рус бүлегендә укый. 1962–1966 елларда башкорт телендә нәшер ителүче «Совет Башҡортостаны» республика газитендә әдәби хезмәткәр вазифасын башкара, күп санлы очерклар, мәкаләләр яза [Энциклопедия: 2010. С. 117].

Ләкин балачагыннан ук туган авылы халкыннан мәзәкләр, сөйләкләр, йола үрнәкләре җыеп, аларны аерым дәфтәрчекләргә туплаган Риф Мирхәбибулла улының күңеле фәнгә тартыла [Хәмид: 2014. 22–27 бб.]. 1966 елда сәләтле белгеч Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасына эшкә чакырыла. Аңа «Татар халык иҗаты», «Татар әдәбияты тарихы» фәннәре, махсус курслар буенча лекцияләр уку, студентларның гыйльми эшләренә җитәкчелек итү бурычы йөкләтелә. Яшь галим яңа эшкә күңел биреп тотына һәм тиз арада хезмәттәшләре арасында зур абруй казана [Фазлетдинов: 2009. 30–31 бб.].

Риф Мөхәммәтҗанов 1967 елдан алып 1990-нчы еллар башына кадәр республиканың татарлар күпләп яшәгән районнарына утызга якын фольклор экспедициясе оештыра, йөзләрчә авылны урап чыга. Әлеге экспедицияләрдә җыелган материалларны саклау һәм өйрәнү өчен аның тарафыннан үзе эшләгән кафедра каршында фольклор фонды оештырыла.

Биредә тупланган фольклор материаллары тиз арада фәнни әйләнешкә кереп китә. Мәсәлән, 1976–1988, 1993 елларда Казанда дөнья күргән «Татар халык иҗаты» академик басмасының һәр китабында да Р.М. Мөхәммәтҗанов җитәкчелегендәге фольклор экспедицияләре барышында Башкортостанда яшәүче татарлардан язып алынган халык авыз иҗаты үрнәкләре урын ала. Ә инде «Йола һәм уен җырлары» томының нигезен, гомумән, Башкортостанда теркәлгән материаллар тәшкил итә. Академик басмага Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе кафедрасы каршындагы фольклор фонды материалларыннан меңнән артык – кыска, йөзләп лирик һәм тарихи җыр, йөзләгән йола һәм уен җыры, мәкаль һәм әйтем, табышмак, биш йөзләп балалар фольклоры үрнәкләре, утыз ике риваять, легенда, мифологик хикәят, утызлап тормыш-көнкүреш әкияте урнаштырыла. Болардан тыш аларда С.Г. Рыбаков тарафыннан бүген Башкортстанга караган районнарда язып алынган 16 кыска җыр, Нәкый Исәнбәт теркәп калдырган меңнәрчә мәкальләр һәм табышмаклар, Х. Ханзафаров кебек халыктан чыккан энтузиаст тикшеренүчеләр язып алган әкиятләр һәм бәетләр урын ала.

Өстәп, шуны да әйтик: Башкортостан татарларының фольклор үрнәкләрен җыюда диалектология белгечләренең (Г.Х. Әхәтов, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б.), фольклорчыларның (Б.Г. Әхмәтшин, С.З. Мөхәммәтнуров һ.б.) да билгеле өлеше бар. Аларның хезмәтләрендә 20дән артык авыл тарихы, тарихи, топонимик риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр урнаштырыла [Ахметшин: 1977. С. 112–117, 120; Материалы: 1978. С. 72–73; Материалы: 1983. С. 69, 72–74; Рамазанова: 1984. С. 183, 186, 187; Татар: 1980. 10, 14 бб.].

1973 елда Риф Мөхәммәтҗанов тарафыннан Башкортостандагы татар фольклорының төбәк үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган беренче кандидатлык диссертациясе яклана [Мухаметзянов: 1973]. «Башкортостан Ык буе татарларының йола поэзиясе» дип аталган фәнни эш күренекле башкорт фольклорчысы, филология фәннәре докторы, профессор Ә.Н. Кирәев (әдәби тәхәллүсе – Кирәй Мәргән) җитәкчелегендә башкарыла. Әлеге диссертация Татарстаннан читтә яшәүче татар халкының, аерым алганда, Башкортостанда яшәүче татарларның, милли фольклорын, аның төбәк үзенчәлекләрен, биредә яшәүче башка халыкларның авыз-тел иҗаты белән бәйләнешен чагыштырма планда, комплекслы һәм системалы рәвештә анализлаган беренче фәнни тикшеренү булып тора.

Риф Мирхәбибулла улы алып барган тикшеренүләр соңыннан студентлар өчен дәреслекләр, уку кулланмалары булып формалаша. 1977 елда аның – «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты: туй поэзиясе» [Мөхәммәтҗанов: 1977], 1982 елда – «Башкортстан Ык буе татарларының

йола иҗаты: календарь поэзия» [Мөхәммәтҗанов: 1982], 1984 елда рус телендә «Специфика татарских фольклорных жанров» [Мухаметзянов: 1989] дип аталган хезмәтләре үзе эшләгән Башкорт дәүләт университеты нәшриятында дөнья күрә. Алар бүген дә студентлар, халык авыз иҗаты белән кызыксынучылар өчен әһәмиятле чыганаклар булып кала. Шуны истә тотып, быел әлеге хезмәтләр һәм галимнең «Казан утлары» журналында басылып чыккан фәнни-популяр мәкаләләре, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Башкорт дәүләт университеты галимнәре тарафыннан бергә тупланып, «Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты» [Мөхәммәтҗанов: 2021] дигән исем астында аерым китап итеп бастырып чыгарылды.

Галим Р.М. Мөхәммәтҗановның 1996 елдагы вакытсыз вафатыннан соң, ул башлаган эш укучысы И.К. Фазлетдинов тарафыннан дәвам иттерелә. 2005 елда ул филология фәннәре, профессор Ә.М. Сөләйманов җитәкчелегендә «Башкортстан татарларының топонимик риваятьләре һәм легендалары: тарихи нигезләре һәм идея-эстетик функцияләре» [Фазлутдинов: 2005] темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Әкияти характерда булмаган халык прозасы жанрларын тикшерүгә багышланган берничә күләмле фәнни хезмәт бастырып чыгара [Фазлетдинов: 2003; 2007; Башкортстан: 2018].

Шуларның «Башкортстан татарлары фольклоры: риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр» дип аталганы аерым әһәмияткә ия. Биредә татарлар күпчелекне тәшкил иткән яисә укмашып яшәгән районнардан җыеп алынган 702 фольклор әсәре – 630 риваять, 23 легенда, 33 мифологик хикәят, 16 сөйләк тексты урнаштырыла. Шуларның 600дән артыгы фәнни әйләнешкә беренче тапкыр кертелә. Томның нигезен шулай ук автор-төзүче укыткан Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы каршындагы фольклор фондында соңгы елларда тупланган материаллар тәшкил итә.

Күзәтүдән күренгәнчә, Башкортостан татарларының фольклор мирасын системалы рәвештә җыю һәм өйрәнү юнәлешендә соңгы 50 елда шактый зур эшләр башкарылды. Йола иҗатына, әкияти характерда булмаган халык прозасы жанрларына махсус монографик тикшеренүләр багышланды, риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр тупланмасы аерым китап булып дөнья күрде. Башкортостан Республикасы территориясендә яшәүче татарларның халык авыз иҗаты әсәрләрен җыеп бастыру, өйрәнү бүген дә көн кадагындагы мәсьәлә булып саналырга хаклы.

Аерым алганда, Татарстаннан читтә яшәүче татарларның эпик, лирик һәм лиро-эпик фольклор төрләргә караган жанрларның күпчелеге (мәсәлән, әкиятләр, мәзәкләр, афористик иҗат жанрлары, бәетләр,

мөнәҗәтләр, халык җырлары, балалар иҗаты) аларның төбәк үзенчәлекләре, үзәк мотивлары, персонажлары, бер үк географик һәм рухи мохиттә яшәүче төрле халыкларның эпик традицияләренең бер-берсенә йогынтысы әлегә кадәр тикшерелмәгән өлкәләр булып кала. Быел нәшер ителә башлаган «Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенә караган өч китап шушы мәсьәләләрне тикшерү өчен кыйммәтле гыйльми чыганак булып хезмәт итәр, дип уйлыйбыз [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш: 2021; Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк: 2021; Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк: 2021].

* * *

Татар фольклорын бербөтен система буларак күзаллап, «Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенә кергән китапларны басмага әзерләгәндә, беренче чиратта, тикшеренүчеләр өчен милли фольклорыбызның локаль үзенчәлекләрен чагыштырма планда анализлау мөмкинлеген тудыру максатын куйдык. Шул ук вакытта хезмәт бүгенге катлаулы иҗтимагый-сәяси вазгыятьтә татар халкының бөтенлеген саклау, аны төрле тарафларга тарткалауга-бүлгәләүгә юл куймау өчен дә хезмәт итәчәк.

Китапларны төзегәндә, Башкортостан татарлары арасында таралган барлык фольклор төрләрен һәм жанрларын да колачлау максат итеп куелды. Чыганакларның күпчелеге Башкорт дәүләт университеты татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасының фольклор фондыннан алынды. Биредә әлеге уку йортының филология факультеты татар-рус бүлеге студентлары тарафыннан 1962 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр үткәрелгән җәйге фольклор экспедицияләре вакытында тупланган материаллар саклана. Сериянең китапларына кергән төньяк һәм төньяк-көнчыгыш, үзәк һәм төньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнарның һәммәсенә дә шундый фәнни экспедицияләр оештырылган, аларда җыелган үрнәкләр системалаштырылган. Китапларны төзегәндә, «Татар халык иҗаты» академик басмасында, тел белгечләренең хезмәтләрендә, вакытлы матбугатта дөнья күргән фольклор үрнәкләре дә файдаланылды.

«Башкортстан татарлары фольклоры» сериясенә кергән китапларның төзелеш структурасы уртак. Һәр китап биредәге татар авылларының тарихларын тасвирлаган риваятьләр белән ачыла. Бу – бик үзенчәлекле төркем. Чөнки алар «гадәттә, теге яки бу авылның кайдан, кайчан, нинди сәбәпләр аркасында күчеп килүе турында сөйли. Авыл тарихларында төбәккә беренче килеп утырган кешеләр, аерым нәселләр тормышындагы мөһим вакыйгалар турында төрле мәгълүматлар бирелә. Бу ягы белән алар тарихи риваятьләргә якын торалар. Күп әсәрләрдә авыл исеменең килеп чыгышы да аңлатыла. Монысы исә топонимик риваятьләргә хас күренеш» [Гыйләҗетдинов: 1987. 13 б.]. Безнең карашка, авыл тарихла-

рының шушы үзенчәлеге – бер үк вакытта топонимик та, тарихи да характерга ия булуы – аларны риваятьләр составындагы аерым төркем итеп карарга мөмкинлек бирә. Шуңа да алар һәр китапта башка төр риваятьләрдән аерым, районнар буенча урнаштырылып, тикшерелгән географик ареалда яшәүче татарларның тарихы, тормыш үзенчәлекләре белән укучыны алдан ук таныштыра.

Һәр китапта шуннан соң риваять, легенда, мифологик хикәят, сөйләк, әкият кебек эпик фольклор жанрлары урын ала. Алардан соң лиро-эпик фольклор үрнәкләре – бәетләр һәм мөнәҗәтләр урнаштырыла. Соңыннан бер-бер артлы халык җырлары, афористик жанрлар – мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, сынамышлар, ышанулар, юраулар тезелеп китә. Аннан инде тикшерелгән районнардагы йола иҗатының төрле жанрлары бирелә. Һәр җыентык балалар фольклорына караган әсәрләр белән тәмамлана. Бу Башкортостанның төрле район һәм шәһәрләрендә яшәгән татарларның рухи мирасын тулы һәм системалы итеп күзалларга мөмкинлек бирә.

Хезмәтнең күләме чикләнгәнлектән, бүгенге көндә инде югалган яисә югалып баручы фольклор төрләренә һәм жанрларына – теге яки бу төбәктә яшәүче татарларның йола иҗатына, риваятьләргә, легендаларга, мифологик хикәятләргә, әкиятләргә, им-томнарга, ышануларга, халык җырларының аерым жанр төрләренә, мәсәлән, шәкерт, рекрут һәм солдат җырларына төзүче тарафыннан аеруча игътибар ителде. Аларның барча текстларын да вариантлары белән бергә китапларга урнаштырырга тырыштык. Мәсәлән, борынгы йола фольклоры әсәрләре тулысы белән сакланмаган очракларда аларның аерым элементларын булса да бастырып чыгаруны максатка ярашлы дип таптык.

Шул ук вакытта бүген дә күпләп иҗат ителгән һәм таралган бәет, мөнәҗәт, мәзәк, сөйләк, лирик җыр, мәкаль, әйтем, табышмак кебек фольклор жанрларының кулыбызда булган барлык үрнәкләре дә хезмәткә әле кертелмәде. Биредә без җирле халыкның тормыш тәҗрибәсен, тарихи асылын ачкан иң характерлы берничә әсәрне бирү белән генә чикләндек.

Һәр китапта теге яки бу жанр үрнәкләре күп урнаштырылган очракта, аларга эчке тематик классификация ясалды; фольклор үрнәкләре аз булса, мондый бүленеш-классификация эшләү кирәк дип табылмады. Жанрлар эчендә классификация үткәргәндә, төзүче күренекле татар фольклорчылары М.Х. Бакиров һәм Ф.И. Урманче хезмәтләрендә [Бакиров: 2008; 2012; Урманче: 2005] китерелеп, бүгенге фольклористиканың үзәгендә торган фәнни принципларга һәм терминологиягә таянып эш итте.

Шунысын да искәртү мөһим: фольклор үрнәкләре халыкның җирле тел үзенчәлекләрен саклап тәкъдим ителде. Сериянең аерым китапла-

рын төзегәндә, географик принцип нигез итеп алынды. Мондый бүленеш шактый дәрәҗәдә шартлы булса да, гамәли күзлектән караганда һәм татарлар компактлы яши торган аерым бер территориядә таралган фольклор үрнәкләренә игътибарны юнәлтү җәһәтеннән дә иң уңышлысы дип табылды.

Шуны да әйтик, Уфа өязендә 1718–1727, 1761–1764, 1743–1747, 1781–1782 елларда узган I–IV халык исәбен алу – ревизия материалларында ук биредә татарларның күпләп яшәве күрсәтелә. Алар 5 юлга («дорога») сибелеп утыралар. *Уса юлына* хәзерге Башкортостанның Балтач, Борай, Тәтешле, Краснокама, Калтасы, Мишкә, Кырмыскалы, Яңавыл, өлешчә Бөре һәм Караидел районнарындагы татар авыллары карый; *Казан юлында* Бакалы, Бәләбәй, Благовар, Дүртөйле, Кушнаренко, Илеш, Уфа, өлешчә Бөре һәм Караидел районнарындагы татар авыллары теркәлә; *Ногай юлында* Авыргазы, Бишбүләк, Гафури, Иглин, Стәрлебаш, Стәрлетамак, өлешчә Кырмыскалы районнары, Уфа һәм Стәрлетамак шәһәрләре утыра; *Себер юлына* хәзерге Аскын, Кыйгы, Салават, Учалы, өлешчә Караидел районнары урнаша; *Яңа Мәскәү юлына* Бакалы һәм Бишбүләк районнарының бер өлеше керә [Татары: 2020. С. 19]. Атап үтелгән хезмәттә татар авылларының тулы исемлеге дә, аларда яшәүче милләттәшләребезнең төгәл саны да китерелә. Кулыбыздагы фольклор материалларын аерым китапларга бүлгәндә, без әлеге тарихи-статистик материалларны да истә тотарга тырыштык.

«Башкортстан татарлары фольклоры» сериясендә әлегә өч китап дөнья күрде.

**Беренче китапка** Башкортостанның төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнарында яшәүче татарларның фольклор әсәрләре кертелде [Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк: 2021]. Аның нигезен Аскын, Караидел, Кыйгы, Краснокама, Мәчетле, Тәтешле, Яңавыл, өлешчә Нуриман, Учалы районнарында җыелган фольклор материаллары тәшкил итте. Биредә шуны истә тотарга кирәк: Аскын, Караидел, Кыйгы, Нуриман, Мәчетле, Учалы яклары – этник яктан катнаш төбәкләр. Шуның өчен дә, «биредә төрле этник традицияләрнең тарихи закончалыкка нигезләнеп, берегеп килүе һәм бер-берсенә йогынты ясавы» ачык сизелә [Ахметшин: 2001. С. 5]. Китапка нигезен бары тик татарлар һәм татар телле халык тәшкил иткән яисә татарлар аеруча күпләп яшәгән авыллардан җыелган фольклор әсәрләре генә кертелде.

**Икенче китапка** Башкортостанның үзәк һәм төньяк-көнбатышына караган районнарда яшәүче татарларның фольклор әсәрләре керде [Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк: 2021]. Болар исәбенә Бакалы, Балтач, Борай, Дүртөйле, Илеш, Чакмагыш төбәкләре карый. Бу районнар,

тел ягыннан, нигездә, моноэтник – татар халкы күпчелекне тәшкил иткән районнар. Гади генә итеп әйтсәк, бу – татарның нигезе. Аларның этник бөтенлеген саклау, халык иҗаты әсәрләрен саклау һәм пропагандалау аша тарихка игътибарны көчәйтү безнең төп бурычыбыз булып тора.

**Өченче китапта** Башкортостанның көнбатышында һәм көньяк-көнбатышындагы Авыргазы, Әлшәй, Бишбүләк, Миякә, Бүздәк, Туймазы, Шаран, Ярмәкәй районнарында яшәүче татарларның фольклор әсәрләре урын алды [Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш: 2021]. Бу районнар һәммәсе дә борынгы Казан ханлыгы җирләрендә урнашкан [История: 2016: С. 225–250]. Тел җәһәтеннән караганда да, бу як татарларының сөйләше татар әдәби теле нормаларыннан бөтенләй аерылмый, диярлек [Рамазанова: 1993. 66 б.]. Гомерен Башкортостан татарларының тарихын һәм тел үзенчәлекләрен тикшерүгә багышлаган галим Р.Г. Сибәгатов фикеренчә, гомумән, «Төньяк-Көнбатыш Башкортстан сөйләшләре йөз ел элек тә, ике йөз ел элек тә, өч йөз ел элек тә татарча яңгырашлы булган» [Сибәгатов: 2020. 62 б.].

Эш барышында барлыкка килгән кайбер күзәтүләребезне дә бәян итик. Беренчедән, Идел буе татарларындагы кебек үк, Башкортостанда яшәүче татарлар репертуарында соңгы елларда язып алынган архаик дастаннар очрамый диярлек. Моны, беренчедән, Ислам диненең халкыбызга иртә үтеп кереп, тәңречелеккә нигезләнгән мифологик традицияләрне кысрыклап чыгаруы белән аңлатырга мөмкин. Ә алар архаик дастаннарның нигезен тәшкил итә. Икенчедән, бу татар халкында борын-борыннан китап культурасының, язма әдәбиятның киң үсеш алуы белән дә бәйле. Нәтиҗәдә, фольклор халыкның эстетик, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерә торган бердәнбер чыганак булудан туктый, күләмле әсәрләр язма рәвештә, әдәби кануннар буенча иҗат ителә, төрле вариантларда язып тарала башлый. Архаик дастаннардан аермалы буларак, стадиаль яктан соңгырак чор эпосы булып санала торган мәхәббәт дастаннары, аларның билгеле сюжетка вариантлары, эпик җыр үрнәкләре һ.б. исә Башкортостан татарлары авызыннан шактый күп язып алынган. «Йосыф һәм Зөләйха», «Таһир һәм Зөһрә», «Ләйлә һәм Мәҗнүн» кебек фольклор һәм язма әдәбият арасында торучы китаби дастаннарның вариантлары тикшерелгән ареалда күпләп очраса да, алар, күләмнәре зурлыгы аркасында, әлегә китапларга кертелмәде. Киләчәктә мондый төр дастаннарга аерым китап багышлау күздә тотыла.

Мифологик кануннарга корылган архаик дастаннар табылмаса да, Башкортостан татарлары репертуарында иң борынгы чорларны чагылдырган, шул чорларда бабаларыбыз аңындагы дөнья моделен ачып салган сюжет-мотивлар шактый. Мәсәлән, Аскын, Караидел, Нуриман, Илеш

якларында алыплар – гадәти кешеләрдән алда яшәгән зур гәүдәле адәми затлар турындагы риваятьләр гаять күп таралган.

Башкортостанда яшәүче милләттәшләребез репертуарында, Казан татарлары фольклорыннан аермалы буларак, күршеләренең малын, җирен тартып алу өчен күчмә кабиләләр арасында барган феодаль сугышлар – карымта-барымта яулары турындагы риваятьләр дә зур урын тота. Моңа кадәр әлеге төр әсәрләр мөстәкыйль тематик төркем буларак бары тик башкорт риваятьләре составында гына аерымлана иде. Соңгы еллардагы тикшеренүләребез карымта-барымта яулары белән бәйле мотивларның башкорт фольклорында гына түгел, Башкортостан татарларының риваятьләрендә дә мөһим урын тотуын ачыклады һәм аларны мөстәкыйль тематик цикл итеп карарга мөмкинлек бирде [Фазлетдинов: 2007. 8–15 бб.; Фазлутдинов: 2005. С. 20]. Безнең фикеребезчә, биредә «татар халкының бер өлешенең хәзерге Башкортстан җирләрендә борын-борыннан яшәп, бу сугышларда турыдан-туры катнашкан булуы турында фикер йөртергә дә урын бар» [Башкортстан: 2018. 31 б.]. Архаик мотивларның күп очравы үзе үк татарларның бу җирләрдә гасырлар дәвамында яшәвен исбатлый.

Янә шуңа да игътибар итү кирәк: китапларга кергән материалларның зур өлеше 1962–1991 елларда, ягъни совет идеологиясе хакимлек иткән чорда язып алынган. Шуңа күрә аерым үрнәкләрдә коммунистик идеология, сыйнфый караш шаукымы, дингә һәм муллаларга карата ифрат тискәре караш та сизелеп кала. Моны аңлап кабул итү сорала. Чөнки фольклор әсәре үзен тудырган, үзе яшәгән чор чынбарлыгын чагылдырмыйча яши алмый. Шуңа күрә дә Совет чорында язып алынган әсәрләрдә мондый, бүген инде бик иске булып тоелган карашларның саклануы – табигый күренеш.

Хәзерге Башкортостан территорияләрендә борын-борыннан, әле Алтын Урда чорыннан ук һәм аннан да иртәрәк, яшәп көн күрүче татарлардан язып алынган авыз иҗатында бердәм татар милләтенә хас яшәү рәвешен, холкын, сөйләмнәрендәге саф татарча үзенчәлекле аһәңне, гомумән, милләтебез кичергән әрнү-борчуларны, шатлык-куанычларны төсмерләү кыен түгел. Татар халкын милли асылына кайтаруда һичшиксез мөһим кыйммәтләрдән булган рухи энҗе-мәрҗәннәр алар.

## Әдәбият

1. Ахмаров Г.Н. Тептяри и их происхождение. Казань: Типолит. Казанского ун-та, 1907. – 27 с. [Отдельный отт. из «Известия общества истории, археологии, этнографии». Т. XXIII. Вып. 5].

2. Ахметшин Б.Г. Горнозаводской фольклор Башкортостана и Южного Урала / Б.Г. Ахметшин; науч. ред. Р.Г. Кузеев. Уфа: «Китап», 2001. – 288 с.
3. Ахметшин Б.Г. Предания Мечетлинского и Янаульского районов Башкирии // Фольклор народов РСФСР: межвузовский научный сборник / ответ. ред. Т.М. Акимова, Л. Г. Бараг. Уфа, 1977. С. 111–120.
4. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I том (А–Л). / Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты; җаваплы редакторы А.Ә. Тимерханов. Казан: «Мәгариф-Вакыт», 2015. – 543 б.
5. Бакиров М.Х. Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: «Мәгариф», 2008. – 359 б.
6. Бакиров М.Х. Татарский фольклор: монография. Казань: «Ихлас», 2012. – 399 с.
7. Башкортстан татарлары фольклоры. Риваятьләр, легендалар, мифологик хикәятләр, сөйләкләр / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: «Китап», 2018. – 344 б.
8. Башкортстан татарлары фольклоры. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘҺСИ, 2021. – 312 б.
9. Башкортстан татарлары фольклоры. Төньяк һәм төньяк-көнчыгыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘҺСИ, 2021. – 296 б.
10. Башкортстан татарлары фольклоры. Үзәк һәм төньяк-көнбатыш районнар / төзүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы И.К. Фазлетдинов; фәнни редакторы К.М. Миңнуллин. Казан: ТӘҺСИ, 2021. – 304 б.
11. Булатова М.Р. Татарские говоры Башкортостана: ареальный аспект / научный ред. Д.Б. Рамазанова. Казань: ИЯЛИ, 2021. – 136 с.
12. Васильев М.А. Памятники татарской народной словесности: сказки и легенды. Казань: Комбинат издательства и печати ТССР, 1924. – 182 с.
13. Вәлиди Гарифҗан. Актүбә буйлары // Шура. 1913. № 4. 109–113 бб.
14. Гыйләҗетдинов С.М. Риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр турында // Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1987. 5–18 бб.

15. Давлетшина З.М. Татарское население Башкортостана: этнодемографическое исследование / ответ. ред. Р.М. Юсупов. Уфа: «Гилем», 2001. – 201 с.
16. Дәүлиханов Мөхәммәтҗан. Бабалардан ишетелгән хәбәрләр // Шура. 1915. № 14. 153–159 бб.
17. Ибраһимов Г.Г. Әсәрләр: 15 томда. Т. 8: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1918–1933) / төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче Г.А. Хөснетдинова; кереш сүз авторы Д.Ф. Заһидуллина. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2019. – 431 б.
18. История татар Западного Приуралья. Т. I. Кочевники Великой степи в Приуралье. Татарские средневековые государства: коллективная монография. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2016. – 464 с.
19. Исхаков Д.М. Историческая демография татарского народа (XVII – начало XX в.). Казань: «Печатный двор», 1993. – 143 с.
20. Катанов Н.Ф. Отчет о поездке, совершенной с 1 июня 1897 г. по 20 августа того же года в Белебеевский и Мензелинский уезды Уфимской губернии // Ученые записки Казанского университета. Казань, 1898. Кн. 11. С. 1–37.
21. Катанов Н.Ф. Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 года в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Ученые записки Казанского университета. Казань, 1900. Кн. 7 и 8. С. 1–30.
22. Катанов Н.Ф. Отчет о поездке, совершенной с 20 мая по 20 августа 1898 года в Белебеевский уезд Уфимской губернии // Ученые записки Казанского университета. Казань, 1901. Кн. 3. С. 1–76.
23. Кузеев Р.Г. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала: этногенетический взгляд на историю. М.: «Наука», 1992. – 344 с.
24. Лепехин И.И. Дневные записки путешествия доктора и академии наук адъюнкта Ивана Лепехина по разным провинциям Российского государства, 1768 и 1769 гг. Ч. 1. СПб: При Императорской Академии наук, 1771. – 537 с.
25. Лепехин И.И. Дневные записки путешествия доктора и академии наук адъюнкта Ивана Лепехина по разным провинциям Российского государства, 1768 и 1769 гг. Ч. 2. СПб: При Императорской Академии наук, 1772. – 338 с.
26. Материалы по татарской диалектологии: Вып. 4. Казань: ИЯЛИ, 1978. – 131 с.
27. Материалы по татарской диалектологии. Образцы текстов. Вып. 5. Казань: ИЯЛИ, 1983. – 169 с.

28. Мөхәммәтҗанов Р.М. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты / төзүчеләр: И.И. Ямалтдинов, И.К. Фазлетдинов. Казан: ТӘҺСИ, 2021. – 228 б.
29. Мөхәммәтҗанов Р.М. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Туй поэзиясе: «Татар халык иҗаты» курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы / фәнни редакторы Т.Н. Галиуллин. Уфа, 1977. – 70 б.
30. Мөхәммәтҗанов Р.М. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты. Календарь поэзия: «Татар халык иҗаты» курсы буенча уку әсбабы. Уфа, 1982. – 72 б.
31. Мухаметзянов Р.М. Обрядовая поэзия приикских татар Башкирии: дисс. ...канд. филол. наук: 10.01.09. Уфа, 1973. – 228 с. https://search.rsl.ru/ru/record/01009856164.
32. Мухаметзянов Р.М. Специфика татарских фольклорных жанров: учебное пособие по спецкурсу. Уфа, 1989. – 84 с.
33. Национально-культурные проблемы татар Башкортостана: тезисы республиканской научной конференции. Казань: «Магариф», 2003. – 176 с.
34. Паллас П.С. Путешествие по разным местам Российского государства по велению Императорской академии наук / Перевод с немецкого. В 3-х частях. Ч. 2. Кн. 1. СПб: При Императорской Академии наук, 1786. – 476 с.
35. Рамазанова Д.Б. Формирование татарских говоров Юго-Западной Башкирии. Казань: Татарское книжное издательство, 1984. – 191 с.
36. Рамазанова Д.Б. Ык ага чик сызыгы булып... // Идел. 1993. № 9. 58–71 бб.
37. Рахматуллин У.Х. Население Башкирии в XVII–XVIII веках: вопросы формирования небашкирского населения / ответ. ред. Н.И. Павленко. М.: «Наука», 1988. – 186 с.
38. Рыбаков С.Г. О поэтическом творчестве Уральских мусульман (татар, башкир, тептярей). СПб.: Типография С.Н. Худекова, 1895. – 40 с.
39. Рыбаков С.Г. Музыка и песни уральских мусульман с очерком их быта. СПб., 1897. – 330 с.
40. Сибәгатов Р.Г. Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре. 2-нче басма. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2020. – 190 б.
41. Татар диалектологиясеннән практик занятиеләр үткәрү өчен материаллар: Өченче чыгарылыш / Төзүчесе Г.Х. Әхәтов. Уфа: БДУ нәшрияты, 1980. – 64 б.

42. Татары Уфимского уезда (материалы переписей населения 1722–1782 гг.): справочное издание / отв. ред. Р.Р. Исхаков. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2020. – 192 с.
43. Тәфтиләү // Шура. 1915. № 4. 97–99 бб.
44. Тимергалин Адлер. Миллият сүзлеге: аңлатмалы сүзлек. Өч томда. 2 т: Й-Р хәрефләре. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2017. – 684 б.
45. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: 2 томда. Т. II: Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / төзүчеләре: Э. Галимҗанова, З. Шәйхелисламов, З. Рәмиев. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2006. – 383 б.
46. Урманче Ф.И. Проблемы национальной истории / редакторы-составители Ф.И. Урманче, Х.Ш. Махмутов // Академик Мирфатых Закиев. К семидесятилетию. М.: «Инсан», 1998. С. 85–131.
47. Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты / фәнни мөхәррире Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: «Мәгариф», 2005. – 383 б.
48. Фазлетдинов И.К. Риваятьтә халык тарихы. Авыл тарихларын тасвирлаган риваятьләрдә XVI–XIX гасырлардагы миграция процессларының чагылышы: уку кулланмасы / фәнни редактор Ә.М. Сөләйманов. Уфа: БДУ нәшрияты, 2003. – 201 б.
49. Фазлетдинов И.К. Тарих кайтавазы – риваять. XVI–XIX гасырлардагы зур тарихи вакыйгаларның Башкортстан татарлары риваятьләрендә чагылышы: уку кулланмасы / җаваплы мөхәррире Ә.М. Сөләйманов. Уфа: БДУ нәшрияты, 2007. – 111 б.
50. Фазлетдинов И.К. Фольклорчы галим Риф Мөхәммәтҗановның фәнни һәм педагогик эшчәнлеге // Фәнни Татарстан. 2019. 94–99 бб.
51. Фазлетдинов И. Юксыну // Тулпар. 2009. № 4. 30–31 бб.
52. Фазлутдинов И.К. Топонимические предания и легенды татар Башкортостана: исторические основы и идейно-эстетические функции: автореф. дис. ...канд. филол. наук / ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2005. – 26 с.
53. Хәмид Р. Яшьти абый // Тулпар. 2014. № 3. 22–27 бб.
54. Энциклопедия. Ермекеевский район. Республика Башкортостан: А–Я / Т.И. Аминев (рук.) и др.; редкол.: Т.И. Аминев (отв. ред.) и др. Уфа: Уфимский полиграфкомбинат, 2010. – 199 с.
55. Юлдашбаев Б.Х. История формирования башкирской нации (дооктябрьский период). Уфа: Башкирское книжное издательство, 1972. – 336 с.

*И.И. Ямалтдинов*

## БАШКОРТОСТАННЫҢ СТӘРЛЕБАШ РАЙОНЫ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ЗАМАН ФОЛЬКЛОРЫ [1]

Башкортостан территориясе татарларның традицион яшәү урыны булып тора. Республиканың төньяк-көнбатыш өлеше тарихи рәвештә Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгының йогынтысы астында, Казан өязе составында булган. 1708–1728 һәм 1731–1734 елларда республика территориясе (Уфа провинциясе) административ рәвештә Казан губернасына буйсынган. Идел һәм Урал буе территориясендә күп гасырлар дәвамында татарларның даими эчке миграциясе барган. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татар халкының шактый өлеше үз яшәү урыннарыннан чыгып китәргә һәм дәүләтнең үзәк районнарыннан Урал алдына күченергә мәҗбүр булган. Татарлар үз авылларын булдырудан тыш, башкорт вотчинниклары авылларында да төпләнәләр. XVI-нчы йөзнең икенче яртысыннан соң, бигрәк тә 1670-нче елдан Башкортостан территориясенә крепость һәм чик буе сызыкларында хезмәт итү өчен, Түбән Новгород һәм Касыйм районнарыннан йомышлы татарлар күчерелә. 1740–1750 елларда дәүләт салымы һәм христианлаштыру сәясәте көчәю сәбәпле, XVIII йөзнең икенче яртысында Урта Идел буендагы татарларның Урал алдына миграциясе яңадан көчәя [Республика Башкортостан: 2016. С. 137–140].

Башкортостан төбәгендә яшәүче татарларның фольклоры белән кызыксыну ике йөз елдан артык элек башлана, дияргә мөмкин.

Россия Фәннәр академиясе ачылганнан соң (1725), аның эшчәнлегенең аерылгысыз бер юнәлеше буларак, күпмилләтле илдә яшәүче халыкларның тарихын, этнографиясен өйрәнү максатыннан экспедияләр оештырыла. XIX гасырның беренче яртысында Казан университеты галимнәренең хезмәтләрендә дә татар халкының тарихына, рухи мирасына һәм фольклорына караган кыр тикшеренүләре нәтиҗәләре яисә башка чыганаклардан алынган материаллар бар [Ямалтдинов: 2016. С. 35–36].

Аннан соң да Башкортостан җирлегендә яшәүче милләттәшләребезнең авыз иҗатын өйрәнү эше татар галимнәре һәм әдипләре тарафыннан дәвам иттерелә.

XX гасыр уртасыннан Башкортостан татарларының сөйләшләрен өйрәнү өчен, телче-диалектологлар әлеге төбәкнең Яңавыл, Тәтешле, Аскын, Мәчетле, Бакалы, Балтач, Калтасы, Борай, Краснокама, Мишкә, Илеш, Дүртөйле, Бөре, Чакмагыш, Кушнарен, Караидел, Дуван, Салават,

[1] Текстта авторның экспедиция материаллары үзгәртелмичә бирелә.

Кыйгы, Туймазы, Бәләбәй, Шаран, Благовар, Бүздәк, Уфа, Чишмә, Кырмыскалы, Дәүләкән, Аургазы, Әлшәй, Бишбүләк, Миякә, Стәрлетамак, Стәрлебаш, Федоровка, Күмертау, Мәләүз һ.б. районнарына берничә тапкыр (1954–1957, 1965–1966, 1968–1975, 1977–1979, 1983–1984) экспедициягә чыга [Атлас татарских народных говоров: 2015. С. 28–36]. Галимнәр Ә. Әфләтунов, Җ. Алмаз, Л. Мәхмүтова, З. Садыйкова, Д. Рамазанова, Т. Хәйретдинова, Ф. Баязитова тел материалы буларак, халык иҗаты үрнәкләрен дә туплыйлар.

Башкортостан татарларыннан халык авыз иҗатын системалы рәвештә җыю, туплау һәм аны фәнни өйрәнү өлкәсендә бәһасез эшне күренекле фольклорчы-галим, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Риф Мирхәбибулла улы Мөхәммәтҗанов башкара. 1967 елдан алып ул республиканың татарлар күпләп яшәгән районнарына утызга якын фольклор экспедициясе оештыра, йөзләгән авылны өйрәнә. 1973 елда Стәрлебаш районында Башкорт дәүләт университетының татар бүлеге доценты Риф Мөхәммәтҗанов тарафыннан да халык җәүһәрләре үрнәкләре язып алына. Риф ага Мөхәммәтҗановның иң зур казанышларының берсе – БДУның татар филологиясе кафедрасы каршында фольклор фонды оештыру. Соңрак фондта тупланган материалларның икенче нөсхәсе хәзерге Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фольклор фондына тапшырыла.

Башкортостан Республикасының Стәрлебаш районында яшәүче татарларның халык авыз иҗат үрнәкләрен туплау максаты белән 1971 елда галим Фәрит Миргалим улы Хатипов җитәкчелегендә фәнни экспедиция оештырыла. Башкорт дәүләт университетының татар бүлегенең беренче курс студентлары Стәрлебаш, Яңгырчы, Хәлекәй, Бузат, Тәтер-Арслан, Кызыл-Яр, Айтуган, Өч-Әсән, Карамалы-Бузат, Гали-Бузат авылларында кыска һәм озын җырлар, такмаклар, мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар, мәзәкләр, юрамышлар, арбаулар, сыктаулар, легендалар, сынамышлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, әкиятләр һ.б. фән өчен бик кыйммәтле халык иҗаты материалларын бөртекләп җыеп алып кайталар. Экспедициядә катнашкан студентлар өчен бу, беренче чиратта, һичнәрсә белән алыштыргысыз аралашу мәктәбе була.

Стәрлебаш районында яшәүче милләттәшләребез дә күңелләрендә сакланган халык иҗаты үрнәкләрен Казанга – Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына язып җибәрәләр.

Әлеге материалларның бер өлеше Институт әзерләгән «Татар халык иҗаты»ның уникe томлыгында (1976–1988) һәм соңрак нәшер ителгән «Балалар фольклоры» китабында (1993) басылган яисә искәрмәләрдә вариант буларак күрсәтелгән.

Алга таба да Башкорт дәүләт университетының, Башкорт дәүләт педагогия университетының татар бүлеге студентлары төрле елларда Башкортостан төбәгендә, шул исәптән Стәрлебаш районында да фольклор экспедицияләрендә була. Мәсәлән, 2010 елда Башкорт дәүләт педагогия университеты студенты Гөлнара Яхшисарова Стәрлебаш, Карагош, Яңгырчы һ.б. татар авылларында җырлар, такмаклар, мәкаль һәм әйтемнәр, бәетләр, мөнәҗәтләр һ.б. жанрларга караган халык иҗаты үрнәкләрен язып ала.

Һәм, ниһаять, 2017 елда Стәрлебаш районына Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының комплекслы фәнни экспедициясе оештырылды. Ул берничә өлкәгә кагылышлы тикшеренүләр үткәрүне максат итте. Фольклорчылардан Ильмир Ямалтдинов (экспедиция җитәкчесе) һәм фәнни хезмәткәр Гөлнара Яхшисарова катнашты. Башкортостанның Стәрлебаш районына кергән 15 татар авылында (Айдарәле, Әмир, Бакча, Бакый, Бузат, Гөлем, Карагош, Куганакбаш, Стәрлебаш, Турмай, Тәтер-Арслан, Өч-Әсән, Хәлекәй, Янгырчы, Яшерган) булып, барлыгы 700 берәмлеккә якын халык авыз иҗаты үрнәкләре һәм татар халкының традицион мәдәниятенә караган материаллар язып алынды.

Стәрлебаш районында яшәүче татарлар арасында аеруча иң киң таралган авыз иҗаты жанрларыннан җырларны аерып чыгарырга була. Өч йөздән артык җыр язып алынды. Аларның күбесе – кыска җырлар һәм такмаклар. Алар арасында лирик, йола һәм уен-бию, бишек җырлары да бар. Информантларыбыз хәтта авылдашлары җырлаган җырларны күңелендә яңартап кайберләрен җырлап та күрсәттеләр.

Стәрлебаш районында гомер итүче татарларда озын көйләр сакланган. «Олы юлның тузаны», «Рәйхан», «Сарман буйларында» һ.б. җырларны һәрбер авылда очратырга була. Шулай ук «Йокла, балам, йом күзең», «Әлли-бәлли бәү итә» һәм «Аллаһу-Аллаһу» кебек бишек җырлары киң таралган. Аларның берничә вариантын теркәдек. Автор җырлары да халык тарафыннан бик яратылып башкарыла. Алар арасында халыклашкан җырлар да бар. Тарихи җырлар, кызганыч ки, очрамады.

Ияләр, җеннәр турындагы мифологик сөйләкләр, хикәятләр һәм әкиятләр халыкта борынгыдан сөйләнеп килгән, кешеләр аларга ышанганнар, буыннан-буынга тапшырганнар. Татар халкында аеруча киң таралганнары – атның ялын үрә торган яисә яратмаганга шабыр тиргә батыручы абзар иясе; төрле кыяфәткә (песи, эт, бабай, матур кыз һ.б.) керә ала торган, яисә бала елаган тавышка иярттеп адаштыручы, яисә өсте капланмаган сусөт белән баласын коендыручы, яисә ялгыз әбиләргә ияләшүче җен-пәри-шайтан; атны тугарып, дугасын (сбруен) кире якка җиккән очракта гына котылып була торган адаштыручы җенле урыннар; яратмаганга күрә кү-

зенә күренүче яисә табак-савыт шалтыратучы, яисә сыер (ат) бозаулаганда (колынлаганда) тәрәзә шакып уятучы өй иясе (йорт анасы), адашкан кешегә юл күрсәтүче Хозур Ильяс, кызыл ут булып тәгәрәп йөрүче Убыр, озын бармаклары белән кытыклап үтерүче Шүрәле, чәчен тарап утыручы Су анасы; Стәрлебаш төбәгендә генә була торган, аерым алганда, иртәгә гает дигән көнне бер җиргә дә чыгарга ярамаган килеш Гарәфә көнне игеннәрне карарга чыккан Ситдыйка картәнисеннән нишләп йөрүен сораучы Хозур бабай, матур кыз кыяфәтендә кич белән килеп, «минем өстемнән кәләш алсаң, мин сине үтерәм», дигән җен кызы; Нәгыймә әбиләр йортында Морзаян бабай булып мал карап йөрүче Йорт иясе, бәхетле, бай булу өчен, җен күреп алганчы төнге уникедә аяк табаны астына салып алып кайтырга кирәк булган чикләвек чәчәге; ягылган мунчага бикләп кенә котылып була торган матур кыз кыяфәтендә килгән Юха һ.б.

Болардан тыш тарихи һәм топонимик риваятьләр язып алынды, аларның авыл тарихларына (Турмай, Гөлем, Бузат, Өч-Әсән, Яңгырчы, Яшерган, Стәрлебаш, Ибрай, Карагош һ.б.) бәйлеләре – шул авылларда яшәүче милләттәшләребезнең үз тарихларына битараф булмаганлыкларының ачык мисалы. Стәрлебаш авылында Гыйзетдинова Зөлфия Зиннәт кызы (1961 елгы) беренче булып комсомолга кергән Әхсән исемле егетне һәм аның Гайфулла исемле дустын бертөркем ирләрнең килүе һәм алып чыгып кыйнаулары, аннары Әхсәнне, ат койрыгына тагып, Ибракай тауларына алып барулары, ике дистәгә якын хәнҗәр белән кадап аны үтерүләре һәм соңыннан халыкның Стәрлебашның бер урамына Әхсән исемен кушуы турында риваять сөйләде.

Стәрлебаш төбәгендә, нигездә, барлык татар халкы өчен хас уеннарның тасвирламасы сакланган. «Түгәрәк» уеннан башлап, «Лапта», «Ак кирәк, күк кирәк» белән беррәттән, аулак өйләрдә, кичке уеннарда (Стәрлебаш районы татарлары кичке уеннарны вечер дип тә сөйли – И.Я.) традицион уйналып килгән «Наза», «Йөзек салыш» («Тычкан салыш»), «Йолдыз санашлар» да бар. Кышкы кич утыруларда, яз башында кич табигатькә чыгуларда, соңрак мәдәният йортларында «Чүпләм», «Читән үрү», «Кыз урлаш», «Тату», «Сукыр тәкә» һ.б. уеннар булган, ә балалар тарафыннан «Черталы» «Бастырышлы», «Чүрәкә», «Пограничник», «Триножка», «Чируклы», «Гузна» уеннары аеруча яратып уйналган.

Әкиятләргә килгәндә, Стәрлебаш районында Г. Тукай әкиятләре һәм берничә татар халык әкияте, яисә әкиятнең кыскача эчтәлеге, шул исәптән әкият-мәзәк язып алынды. Кайбер әкиятләрнең эчтәлеге яисә сюжеты халык әкиятләренә тәңгәл килә, яисә берничә әкият сюжеты кушылып бер әкият итеп сөйләнә. Әкиятләргә ислам дине белән бәйле мотивлар килеп керү дә күзәтелә.

Бу төбәктә мөнәҗәт һәм бәет жанрларына караган үрнәкләр дә теркәлде. Стәрлебаш татарларында иң киң таралган халык иҗаты жанрларының икенчесе – мөнәҗәтләр. Алар һәр авылда очрый. Аллаһы Тәгаләгә, Пәйгамбәрләргә, Ислам диненә, Коръәнгә мәдхияләр, шигъри нәсыйхәтләр, бәйрәм, мәҗлес мөнәҗәтләре, яшәү һәм үлем фәлсәфәсе, ата-ана һәм бала турында мөнәҗәтләр киң таралган. Бу аңлашыла да, чөнки Стәрлебаш татарларында дин көчле. Бузат авылында Фәттахов Илдар Хәйдәр улыннан (1985 елгы) мөнәҗәт жанрына якын торган «Салаватулла» һәм «Ассубәһибәдә» әсәрләре икесе дә гарәп телендә язып алынды.

Сирәк булса да, бәетләр дә очрады. Куганакбаш авылында Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы), Бакый авылында Вилданова Ямал Газиз кызыннан (1921 елгы) һ.б. информантлардан татар халкында киң таралган «Сак-Сок» бәетләре язып алынды. Куганакбаш авылында Байморатова Рәшидәдән Әфганстан сугышында һәлак булган улы Азамат Байморатовка багышланган «Ана сагышы», Бөхәрмәтова Миңсылудан язып алынган «Мидхәт бәете», Вилданова Розалиядән бер-бер артлы фаҗигале рәвештә һәлак булган уллары Флорит һәм Спартак истәлегенә чыгарылган «Минем газиз улларым», Яңгырчы авылында язып алынган «Рәшит бәете», Стәрлебаш авылында Кәримова Фәрзәнә оныгына багышлаган «Рим бәете» –бу төбәктә бәет чыгару традициясенең дәвам итүен күрсәтә. Әлеге жанрларга караган үрнәкләр халыктан сирәк язылып алына. Алар, нигездә, кәгазьгә төшерелә. Шулай да, бу төбәктә халык мөнәҗәтләрне күңеленнән әйтә.

Балалар фольклорының «Багу поэзиясе» әсәрләреннән берничә бишек җыры, әйтеш, юаткыч, мавыктыргыч, сөйләм такмагы, шулай ук «Күңел ачу» һәм «Уен фольклоры» үрнәкләре язып алынды.

Табышмаклар һәм башка паремияләр дә өлкән буын вәкилләренең күңелендә генә саклана. Хәзерге вакытта дастаннар очрамаса да, «Сәйфелмөлек» әсәренең эчтәлеге Өч-Әсән авылында Гафиятуллина Мөбарәк Муллагали кызыннан (1930 елгы) язып алынды.

Йола фольклорына килгәндә, йолалар, гореф-гадәтләр турындагы мәгълүматларны җырлары, уеннары, махсус әйтелә торган сүзләре белән бергә мөмкин кадәр бер күренеш буларак язып алырга тырыштык. Алар арасында: Өшкерү; 41 «Ясин» чыгу; яңгыр яумаса – «Ат башы салу», «Яңгыр теләү» яки «Яңгыр боткасы»; мал зыянлаган җиргә «Пычак белән сызу»; «Таң суы алу»; күз тимәскә артыш агачы кую; бала тугач, башлыгына миләш агачын тегү; «Бәби котлау (үстерү)»; бала йөрмәсә – май үләне, 41 аксыргак салу яки «Тышау кисү», тозлы суга утырту; бала курыкса, егылса, күз тисә – «Җиргә салу»; бала еласа ботак тишеге, тары белән имләү; курыккан кешегә «Кот салмасы» ашату; куркудан кургаш белән

«Кот салу»; «Күк кабагы (капусы) ачылу»; «Тимрәү имләү»; кабергә су салу; «Сугым сую»; сыерның җилене шешсә – ботак тишегеннән саву; кабердәге убылган урыннарга – чокырга, Салават әйтеп, 41 кашык су салу; «Җир тарту»; «Туй»; 1928–1930 елларда «Кәләш әйттерү», «Килен төшерү», «Тула өмәсе», «Каз өмәсе» кебек мәҗүсилек һәм борынгы чорлардан калган сүз үрнәкләре, ырымнар, келәүләр, имләүләр, ышанулар, йолалар, халык медицинасы һәм дини йолалар язып алынды.

Стәрлебаш районының татар авылларында гомер итүче милләттәшләребездән язып алынган, халкыбызның буыннан-буынга, телдән-телгә күчеп килгән кайбер фольклор үрнәкләрен тәкъдим итәбез.

## *МИФОЛОГИК СӨЙЛӘКЛӘР, ХИКӘЯТЛӘР ҺӘМ ӘКИЯТЛӘР*[1]

### *(иләр, җеннәр турында)*

### Чикләвек чәчкәсе

Сәгать 12дә чикләвек чәчкә ата. Шунда барып, чәчкә атканны көтеп утырасың. Шул чәчкәне өзеп аласың да артыңа карамыйсың, сәгать 12дә курыкмыйча шуны тотып апкайтасың. Әгәр дә артыңа карасаң, теге чәчкә югала. Төннә ата сәгать 12дә. Шул чәчкәне алсаң, әй бәхетле буласың. Аның чәчкәсен яшен ала. Чикләвеге шуңа күрә аз була. 12дә ата, аны җен урлый, җен күргәләгәнче чәчкәне алсаң, бай буласың. Аны табан астына, аяк киеменә куясың. *Куганакбаш авылында Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936 елгы) язып алынды.*

### Урман хуҗасымы, җенме

Урманга барган әни, әти өйдә юк вакытта. Шул коры-сарылар бит инде, агач кисәргә ярамый бит инде ул вакытта. Коры-сарылар гына төягән бит инде. Хәтсез агач салган. Хәзер кайтырга чыктык, ат туктады кинәт, ди, тартмай, ди. Шуннан хәзер, әни дә безнең укыйдырые ул. Нәрсә эшләргә дә белмим. Ташладым бер агач, ди, ташладым 2 агач, һаман тартмый, ди. Шуннан хәзер 1–2 агач калды арбада, ди. Шуннан ат тартып алып китте, ди. Теге утырган төшми, ди, бушаткач төшеп калган. Ул бит күренми – урман хуҗасымы, җенме. *Яңгырчы авылында Абайдуллина Тәгъзимә Әфтәх кызыннан (1943 елгы) язып алынды.*

### Йорт иясе

Йорт иясе бардыр ул, балам. Бер елны берәү китереп сукты монау кәзәнкә ягыннан, берничә ел, 6–7 ел бар. Коридорга сукты, дөберт итеп калды. Шуннан, бабай тор әле, мин әйтәм, атыңны ябарга кирәк, япмадыңмыни әле. Әллә капка ачылды, чык, димен. Чыгып, атын гына ябып

---

[1] Бу бүлектәге материалларны И. Ямалтдинов язып алды.

керде дә бу, бүтән йерне карамады. Хәзер сыерны да кара, дидем. Сыер басып тора, ди. Бозаулаган да бозавы үлгән, кыстырып үтергән бозауны. Хәзер бит инде сыерны басып тора, дигәннән соң кереп барабыз икәү, монау коридордан бәрәкәтәй чоштырт-чоштырт хәзер өй башына менеп бара, ачуланды безгә бу. Действительно, менә йорт иясе, менеп бара. Чыксак, бозау үлгән. Әйтәм бит, безгә аңнаткан бу. Китереп сукты коридорга, анда әллә кем уяныр. Бар ул, белгертә ул, йөри барыбер. Куркырга түгел, абзар башына тоз белән әпәй куерга кирәк. Тегендә-монда еракка киткәндә: «Лә иләһе иллә Аллаһы», – дип бүрәнә ярыгына язу язып кыстырасың, кайткачтын: «Мөхәммәд рәсулуллаһ», – дип язасың, шуны кыстырасың, өй тынычлыгы өчен. Әйтеп китәсең: «Без ерак юлга чыгабыз, тыныч кына тор», – дип. Бар ул бар, анысы бар. Йорт иясе аламалык китерсә, бик алама була бит. Тозны күмәч өстенә сибәбез дә полителенга төреп кыстырасың. Абзарда һәрвакыт торырга тиеш, ди ул.

### Намаз укучы фәрештәләр

Картәни пич ягырга иртә бара бит инде. Шул клуб дип йөртәләрие. Артислар киләйе, рус артистлар да киләйе, бүтән артислар да. Мәчеткә килеп, ишекне ачтым, ди. Ябып өлгермәгән, ишекне ачкан көе генә күргән дә, ишекне әкрен генә ябып кайтты. Керсә, алама да булырые, йә егылырые, кермәгән. Намаз укыйлар ие, ди. Муллалар, туп-тулы мәчет эче, ди. Анда бит гомер буена мәчет булган. Манарасын кисеп төшергән кешене дә каргыйларые. Барыбер игелек күрмәде. Әбинәгыйм дигән кеше кисте, ди. Нишләптер, үтергәннәр инде аны, ул бабайны. Әйбәт үлем белә(н) үлмәгән. Чалмалы намаз укып утырган кешеләр болар фириштәләр булган. Ул мәчет урыны булгач, шулай булган. *Хәлекәй авылында Шәрипова Гәдәния Низаметдин кызыннан (1937 елгы) язып алынды.*

### Миңсылуның баласын алган мәлгуньнәр

Безнең апа 23, ул бала 22 елгы булган инде ул. Егерме бердә ачлык булган бик яман. Егерме икедә иген бик уңган. Хәзер безнең әткәй белән әңкәй, әңкәй йөкле булган, шул авылга (Стәрлетамак районында Кушкүл белән Түрешле дигән авыл бар) барганнар урак урырга. Әткәйнең апасы да булган, күрше апа булган безгә. Урганнар да, әңкәйнең вакыты да йетә башлаган инде. Күчтәнәчләр алган шунда, әпәйләр күтәргән, 25 км ара бит инде чак торган кешегә, кайтканнар. Кайтканнар да күрше апаның әнисе Гөлҗан дигән әби: «Балам, үзегезгә кереп кун инде», – дигән. Рәдем торалар, мин булсам, өең ашалмас, дияр идем. Әңкәй үзенә кереп кунган, анда 21 елда үлекләр дә яткан булган, күмелмичә. Шуннан әйтә әңкәй хәзер, ди, арып кайткан бит инде, 25 км, авырлы кеше. Хәзер яттым. Өч әби, ди, ап-ак күлмәк кигәннәр, юан 3 әби, ди, гел эчемне аска

сыпыралар. Җәйге төн бит инде, урак өсте кыска. Шуннан уянып китсәм, ди, эчемдә бернәрсә дә юк, ди. Тордым, карадым, хәзер якты бит инде, кан да юк, сүл дә юк, бернәрсә дә юк, корсак та юк. Шуңардан соң тордым да хәзер, шушы авылга килгән бертуган абыйлары, апасы бар инде: «И, Сылу гынам, әңкәйнең исеме Миңсылу, нәрсәң бар», – дигән. Бернәрсәм дә юк, балам югалды, дигән әңкәй. Әйдә, мин сине алып барам. Әллә кем карый да менә шушы югары очтамы. Шуннан кулымнан гына тотып карады теге бабай: «И, балам, йетлеккән балаңны теге мәлгуньнәр алган бит», – дип әйтте, ди. Шулай итеп, минем җен абзыем да бар, ди. Абзыйдыр инде ул. Хатын-кызны җен алмас. Хатын-кыз болай да җен бит инде ул. Минем бертуган җен туганым да бар. Шулай итеп, безнең әңкәйнең бер баласын җен алган корсагыннан. Әңкәй шуның өчен көндез дә мунча кермәде, әңкәй курка иде. Балта белә(н) пычак куйсаң, бусага буш өйне саклый, диләр инде. Без шушылай итеп ышанабыз инде. *Әмир авылында Мөрәсова Зөбәрҗәт Хөббрахман кызыннан (1934 елгы) язып алынды.*

## *ЫШАНУЛАР, ЫРЫМНАР, ЙОЛАЛАР, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР*

### Ат башы салу

Анарга кеше ияртеп барырга түгел. Үзең генә, аяк тынган вакытта гына барырга кирәк салырга. Су буена төшәргә кирәк. Су буенда тәһарәт алып, җуынып, әйбәтләп намаз укып, башны салырга кирәк, ат башын. Башны әйбәтләп тазартып, юып баш сөяген салырга кирәк. Аны суга саласың да бәйләп куясың. Суга салганда: «Аллаһы Тәгалә, хәерле яңгырлар бир, шәфкатең белән бир, бәрәкәтең белән бир. Аллаһы Тәгаләкәем, безне ташлама, берүк яңгырларны бир», дисең. Башка бау тагасың да тал ботагына бәйләп куясың. Аны кузгатып торырга кирәк, әзрәк яумыйча торса. Яңгыр күп яуса, ат башын алып торасың. Аны апкайтып куясың. Кайда торса да ярый, ташларга ярамый. Ул әгәр агып китсә, әнә шул урында ява да ява, безгә булмый. Берәү гомер буе йетә, югалмаса. Алай-болай агып китмәсә. *Куганакбаш авылында Ягафарова Рәхилә Низаметдин кызыннан (1936) И. Ямалтдинов язып алды.*

### Баланы мунча керткәндә

Бала үссен өчен, кендек әбисе баланы икенче көнне үк мунча кертә башлыйдыр иде. Ул аны юындырып, эчләрен сыйпап, кадерләп, тәрбияләп. Шуннан соң бала савыгып үсә. Мунча чапканда: «Әтәң төсле утын түгел, Әниең яккан мунча түгел, Шаканай бул, шаканай бул, Ят та йокла, тор да уйна, Аю баласы, бүре баласы, Берне генә биреп аласы», – дип баланы мунчада чапкан. *Яңгырчы авылында Абайдуллина Тәкъзимә Әфтәх кызыннан (1943 елгы) Г. Яхшисарова язып алды.*

### Сыерның җилене шешсә

Сыерның эмие шешсә, җилене, шушылай итеп ботак тишегеннән савырга кушалар инде. Эмиен кысып, сөт шушы тишектән агып төшсен. Шуннан сыртына сөртергә кушалар ие сыерның (шул сауган сөтне). Дүрт эмиеннән дә, башыннан алып, сыртына (койрыгына кадәр) сөртеп чыгарга кушалар ие, 3 мәртәбә бисмилла итеп. «Минем сыерымда калмасын, тигән күз очсын, китсен, минем сыерым аруланcын». Үзенчә укып шулай итәләр ие. Аннан ул ботак тишеген кадакка элеп куя идек, абзарда (онытмаска, үзеңә). Ботаклы агачны юынасың, тишегеннән үсеп чыкканы ботакның, төшә дә инде, коробкасы гына кала, шуны элеп куясың. Ат дагасын да. *Әмир авылында Мөрәсова Мәрхәбә Гыйззәтулла кызыннан (1937 елгы) И.Ямалтдинов язып алды.*

### Бәби котлау (үстерү)

Кеше бәби алып кайткач та, күрше-тирә яклар, туганнар, әле мин әниләрнекен әйтәм әле, әниләрнең шулай үстергәнен. Күрше әбиләр бергә, алдан сөйләшеп, аш әзерлиләр, чәй әзерлиләр, кулдан килгәнчә, умач уып апкиләме, нәрсә апкилә – бернинди дә гаеп юк, ул хөрмәт йөзеннән санала. Көянтәләп бөтенесе җыелып, көянтәнең ике башына 2 бидра элеп, алар бит 4–5 кеше, табын ясап, бәби котлап китәләрие. Үзебезнең бәби туганнан соң, хәл белергә киләләр инде, аннан соң үзебез бәби үстерергә чакыраек бит инде, туганнарны. Шул бәби үстереп аладырыек инде. *Бакый авылында Байтимерова Нажция Шаһиәхмәт кызыннан (1937 елгы) И.Ямалтдинов язып алды.*

## *РИВАЯТЬЛӘР-ЛЕГЕНДАЛАР, АВЫЛ ТАРИХЛАРЫ, СӨЙЛӘКЛӘР*

### Турмай (Кайраклы)

Элек авыл Кайраклы булган. Менә Миякә ягына барсаң, Тормай дигәнне белмиләр.

– Кайда ул Тормай?

– Менә, менә шул авылны үткәч...

– Ул бит Кайраклы авылы, диләр. Кайраклы елгасы буенда утыра. Корманай авылы дип аталган. Корманайдан Тормайга әйләнгән. Союз чыккач. Авылның утырышы 1740 елларда. Бер 16 йорт Куганактан төшеп утырган, ди, Әсфәндияров та. Кайсыбер нидә Ашкадар авылыннан килеп утырган, ди. Стәрлетамак юлында Ашкадар авылы бар. Аннан да булгандыр, моннан да булгандыр. Күпчелек Абдуллиннар, Курманаевлар. Иң тәү Абдуллиннар килеп утырган инде. *Турмай авылында Курманаев Динияр (Минияр) Биктимер улыннан (1931 елгы) И.Ямалтдинов язып алды.*

## Гөлем авылының тарихы

Гөлем исеме чит бабабызның исеменә бирелгән. Муллагөлем исемле булган төп бабабыз. Шуның дүрт улы булган. Шуның дүрт улыннан берсе безнең буын булган. Беренчесе Динмөхәммәт булган, аннан Шәймәрдан, аның улы Шәйморат булган, Шәйморатның улы – Хәйбрахман, аның улы мин – Риф. Алар сүләү буенча, Муллагөлем бабабыз үсеп килгән вакытта Морза авылына килеп йөргән булганнар, Исмәгыйль исемле кеше. Морза авылы Морзагыл исемле кешенеке булган. Ул бик хәлле кеше булган. Шушы Муллагөлем исемле бабайны сорап алган. Синең улларың тагын бар. Монысын миңа бир. Үзем кеше итәрмен, үстерермен, җир бирермен, урын бирермен. Шуннан шушы җирне бүлеп биргән дә монда яшәгәннәр инде. Шуннан Гөлем исеме авылда таралган. Бу авыл 788 елгы. *Гөлем авылында Шәймәрданов Риф Хәйбрахман улыннан (1935 елгы) Г. Яхшисарова язып алды.*

## Бузат авылы

Безнең Бузат авылы халкы яшәгән ерләрдә элек, борын заманнарда урманнар каплаган булган инде. Халыклар яшәмәгән. Болгар халкын, татарларны, болгарларны урыс патшалары чукындыра башлагач, бу якларга килеп чыккан да, иң беренче урынлышкан, дип әйтәргә була, уйларга була. Чөнки архив материаллары буенча, 1765 елда бу урында бәләкәй генә авыл булган, владения были дигән сүзләр бар, архивный материал Оренбург областной архивтан алынган инде. Архив материалларыннан башка да, Каюмов Мостафа абый сөйләве буенча, ул риваять итеп сөйләде. Үзенең әтиләреннән ишеткән риваять: XVII гасырда Пенза губернасында урыс патшасында хезмәт иткән Маминов фамилияле генерал-морза яшәгән. Хөкүмәткә яхшы хезмәт иткән өчен, патша аңа җир бүләк иткән. Әмма җирне Оренбург губернасыннан, буш яткан җирләрдән биргән. Мамин морза килеп җирне караган, ләкин бик еракта, төпкелдә булуын ошатмаган. Шуңа күрә генерал морза Мамин Пенза губернасында яшәгән үзенең крестьян-мишәрләре белән җирләрен алышырга уйлаган. Башта 3 кеше килеп җирләрне караганнар, күргәннәр урман арасында, чишмәләр буенда җәйрәп яткан акланнар булган. Бу җирләрне танышып йөреп ошатканнар инде. Җирләрне танышып йөрегендә боларның атлары чирләй, бер аты чирләй. Шуннан урман арасындагы акланда шул бер чишмә янында калдырып китәләр. Бу кешеләр яңадан Пенза ягына кайтып, генерал морзага үзләренең җирне ошатканын, яшәргә барырга ризалыкларын белдерәләр. Бер ел узгач, 7 гаилә бу якларга күченеп килә. Аларның килеп төпләнгән җирләре шул чирле атны калдырып киткән урман эчендә алан булган. Бервакыт

алан янындагы чишмәгә хатын-кыз суга бара һәм чишмә янында бер ат очрата. Кайткач, ирләргә сөйлиләр. Барып карасалар, үткән җәй калдырып киткән теге чирле ат булып чыга. Ләкин ат исән-сау, терелгән, ул ат Акбүз була. Атның терелүенә, исән-сау кышлаганына куанган кешеләр авылларына Бузат дип кушалар. Авылга беренче булып нигез салучыларга яшәп китүе бик авыр була. Аларга урман кисеп өй салырга, агачларны төпләп иген үстерү өчен җир эшкәртергә, өр-яңадан дөнья корырга кирәк булган. Урман эчендәге башта бәләкәй авылга, көн күрер өчен, төрле һөнәр ияләре кирәк. Шуңа күрә төрле авылдан тагы да берничә гаилә килеп кушылып яши башлыйлар. Авыл зураеп, үсеп ятканда урыслар да күченеп был якларга нигез сала башлыйлар. Оренбург өлкәсенә караган Зобово, Нистеп дип тә атыйлар, шул авыл урыслары монда килеп мишәрләрне кыерсытканнар. Мал-мөлкәтләрен алып киткәннәр. Җир эшкәртеп чәчкән игенлекләрен таптатканнар, малларын кертеп. Авыл картлары, киңәшләшеп, тагы теге генерал Маминга прошение белән кеше җибәрәләр. Маминга чит якларда үзләренең кыерсытылуларын һәм биләмәләренең (бу яшәгән җирләре законлаштырылмаган бит инде) (үзләренеке) түгеллеген сөйләп аңлатканнар. Мамин морза берничә гвардеецын авылны сакларга (җибәргән), гаиләләре белән, семьялары белән алар бит инде мишәрләр, патшага хезмәт иткәннәр, алар үзләре бер урам булып утыралар. Әлеге вакытта да Морза урамы дип атала ул. Мамин җибәргән (кешеләр) үзләре дә Мамин морза нәселеннән. Шулай итеп, Мамин авылга землимерлар да чакыртып китереп, җирләрен межалап законлаштырып бирә. Авылга землемер белән бергә генерал Мамин да килә. Бузатлылар генерал белән землемерны яхшы итеп каршы алалар, мул итеп сыйлыйлар. Җирне күбрәк бүлсеннәр өчен, бричкага җигелгән пар акбүз ат бүләк итәләр землемерга. Чыннан да землемер җирне бузатлыларга мул итеп бүлә. Оренбург өлкәсенең границасына кадәрлек Тәтер суына төшеп, суының бу як ярын кертеп, җирләрне бүләләр. Бу легенданы Бузат авылында яшәүче хезмәт һәм сугыш ветераны Каюмов Мостафа Әхмәтша улы сөйләгән иде, сугышта катнашкан 23ме, 25ме, шул тирәйе. *Бузат авылында Гыйниятуллина Карлыгач Рәшит кызыннан (1959 елгы) И. Ямалтдинов язып алды*.

## Бузат авылының чишмәләре

***Шифалы чишмә.*** Актау урманы астындагы тау башыннан кыйблага карап ага. Борынгы вакытларда моннан ниндидер үткенчеләр үтеп барганда, бер мосафир ишан үлгән. Бу мәрхүм булган ишанны иптәшләре шул үзләре туктаган чишмә кырына җирләп киткәннәр. Хәзер бу урынны Шифалы чишмә дип йөретәләр. Кәрим кизләве чишмәсенең исеме-

нең тарихы болай. Кәрим исемле бер кеше күрше хохол авылыннан нәрсәдер урлап кайтып килгәндә, артыннан хохоллар куып җитеп үтереп киткәннәр.

***Кәрим кизләве*** яланының ас ягында, беренче бригада җирендә, Арбихан урманы астыннан чыккан бу чишмә суы, зур җырын булып, Көчегән елгасына агып төшә.

***Коры күл*** исеменең тарихы болай. Ырымбур өлкәсенә кергән Кузылы авылының бай мукшылары Көчегән авылының ярлылары, куштаннарын алдап, юк кына хакка күп кенә җирләрен алганнар. Шулар арасында Сафрон исемле бай да булган. Шулай итеп, күп кенә көтүлекләр, сабанлыклар буш кына хакка сатыла. Шуңа күрә исеме дә Каракүл – буш, калдык дигәнне аңлата. Ул инеш хәзер чынлап та сусыз, корыган чокыр, «Каракүл»гә әйләнгән.

Сафрон байның утарын (Синатурдан аста) халык ***Нахаловка*** дип атый, әрсезләнеп, оятсызланып кешеләрнең җирен алган өчен. Аның янындагы чишмәне Сафрон чишмәсе дип йөртәләр.

Каракүлгә агып төшүче чишмәләр: Каракүл, Золып, Синатур, Сафрон.

***Синатур*** электән үк Аксён ягында кымыз белән давалый торган санаторий булган. Санаторийның кымыз бияләрен бу җирдә көтеп йөргәннәр. Санаторийдан Синатурга әйләнгән сүз ул. Ә аңа кадәр Каракүл тамагы дип тә йөрткәннәр.

***Золып чишмәсе*** – өзелеп дигән сүздән кыскарып калган.

Көчегән урманының артында ***Зөләйха*** чишмәсе бар. Урман кырындагы аланда Зөләйха исемле әби җиләк җыеп йөргәндә, сусап, сазлыкта чишмә казый, ургылып шул җирдә су чыга.

Кече Бузат авылы халык телендә ***Бишкуян*** исемендә йөри. Бу авыл бик матур кечкенә инеш буенда урынлашкан. Кече Бузат инеше чишмә суларыннан хасил. Сәүбән, Гата, Кәкән һәм башка исемсез чишмәләр инешкә кушыла. Карталарда бу инешне Бузочка дип язалар. Бу инеш тә Бузат елгасына ага.

***Карамалы инеше*** тугаенда урынлашкан Карамалы-Бузат авылы 1925 елда барлыкка килгән. Шул ук вакытта Гали-Бузат авылы да Бузат елгасы буенда төзелә. Бу авылларга Бузат авылы кешеләре нигез сала. Моның сәбәбе – Бузат җирләрен Ырымбур урысларыннан саклау булган. Тәтер буенда Зобово (Нестер) авылы барлыкка килү белән Бузат җирләрен үзләштерү башланган. Тәтер аша чыгып, печәнлекләрен чапканнар, иген чәчкәннәр, малларын йөреткәннәр. Бузатлыларның урманнарын, чишмәләрен, матур тугайларын үзләренеке ясыйсы килгән. Озак елларга сузыла бу җир өчен бәхәс. Гали-Бузат белән Карамалы-Бузат авылларына нигез салгач кына туктый бу җир өчен бәхәс.

Карамалы-Бузат авылын үтеп, ***Черекәй урманы***, ***Черекәй өсте яланнарыннан*** соң ***Пятка тавы*** башлана. Тәтер буенда Пятка тугае ята, Пятка чишмәсе дә бар. Пятка исемле борынгыдан калган. Землемер Бузат җирен бүлгәндә була ул. Көчегән елгасы буйлап межа бүлгәндә, бер бүз атлы яңгылыш землемерның бавына баса. Межаны бау тартып, бүлеп – билдәләп, артыннан сабан белән сөреп барганнар. Землемерның ачуы килеп, җирне кисә, ягъни киметә башлый. Пьяный хутор дигән җирдә бузатлылар землемерны туктатып эшеннән, аны көйли, сыйлый башлаганнар. Шунда ук землемерга бричкага җигелгән пар бүз ат бүләк иткәннәр. Шуңа күрә дә землемер бузатлыларга, Тәтер елгасының ярты суын кертеп, җирне мул итеп бүлә. Бу киңәеп киткән җирләр: Пятка тау өсте, Пятка тау бите, Пятка тугае исеме белән йөртеләләр. Татарча пятка үкчә дигәнне аңлата, чынлап та бу җирләр картага карагач, үкчәгә охшап тора.

Бузат урманнарының исемнәре: Баймый, Сулы чокыр, Тирән чокыр, Комтау, Иске посадка, Сирәк имәнлек, Серекәй, Алексей, Мәчет, Кәкән (Сатра), Әрбихан, Аргы Бишкуян, Бирге Бишкуян, Актау, Чытыр һәм бәләкәй урманнар: Алаша киләге, Шалкан киләк, Озын киләк, Бурлык киләге, Мукшы чокыры, Кынак.

Киләк сүзе вак агачлык, куаклык мәгънәсендә.

Кынак – элек кәзәгә охшаган «кулан» дигән хайван бу урманда бик күп булган.

Әрбихан – армия һәм хан дигән сүзләрдән ясалган. Моннан күп еллар элек, ханнар белән урыслар сугышкан вакытта, ханның армиясе бу җирдә туктап торган.

Бузат авылына карт бабайларыбыз нигез салганда, тирә-як куе урман булган. Иң беренче Актүбә чишмәсе аланында нигез корганнар. Бу алан урман эчендә булган. Карт бабайларыбыз урман кисеп, агач төпләп, йорт салганнар, бакча ясаганнар, иген чәчкәннәр. Еллар үтү белән авыл зурайган, мал артып үрчегән. Урманнарны кешеләр кисеп, маллар таптап бетергән. Күп урман юкка чыккан. *Бузат авылында Гыйниятуллина Карлыгач Рәшит кызыннан (1959 елгы) Г. Яхшисарова язып алды.*

## Уч-Әсән

Исемен бозып беткәннәр язуда. Учуган дип язганнар. Бу авылның исеме Уч-Асанова. Монда, балам, кара урманнар булган элек. Дикий янлекләр яшәгән. Бер Әсән дигән бабай килә Стәрлетамак ягыннанмы, юк, бу яктан килә, без – Казан нәселе. Бузатлар безгә бер родня да түгел. Ялгыз каен дигән авылдан килгән аларның беренче кешесе. Безгә якын килгән кешеләр түгел, телләре дә бүтән аларның. Шуннан бу бабай килә дә, Әсән дигән бабай, агач төпли дә өй сала. Кайтып, 2 малаен

алып килә, кешеләр җыела, шуннан яшәп киткәннәр инде. Бу үзе олы, күптәнге авыл, карт авыл. Уч кебек кенә урынга килеп урнашкан. Әсән (бабай) исемле кеше. Монда беләкәй генә алан булган, уч кебек кенә, шунда урнашкан. Шуңа күрә Уч-Әсән. Бузат безнеке түгел. Бузатка ул Ялгыз каен авылыннан килгәннәр. Акбүзатка менеп бер бабай килгән. Бузат берәү калды инде ул. Таралып бетте алар. Алары Бузатның үзеннән аерылып чыкканнар, алары килмәгән. Шуннан курыкмыйча берүзе урнашып, шуннан авыл булып яшәп киткәннәр. Бүтәннәре аның биш йортлы. Ерүзәнгә киттеләр. Мәктәпләре дә юк, бетте, таралды бит инде. *Өч-Әсән авылында Галәветдинова Бәлхия Гыйззәтулла кызыннан (1931 елгы) И. Ямалтдинов язып алды.*

## Өч-Әсән авылы

Өч-Әсән авылы Башкортстанның иң матур табигать кочагында урнашкан. Каен урманнары, чәчкәле үзәнлекләр, биек булмаган калкулыклар арасында утыра ул. Безнең Әсән авылы турында шушындый риваять яши. Зур авыл Алагуаттан берәү аугa чыга. Киек кошлар эзләп, ул озак йөри. Ниһаять, бик матур урынга килеп чыга: куе урманнар эчендә зур гына аланлык ачыла. Янәшәдә генә кечкенә елга агып ята. Аңарда балыклар йөзеп йөри. Елга аръягында ябалдашлы агачлар белән капланган калкулык була. Әсән, әсәрләнгәндәй, шушы аланда тукталып, тирә-яктагы хозурлыкка сокланып тора. Бу урын аңа шулкадәрле ошый, ул шушында төпләнергә карар итә. Тиздән туганнарының ярдәме белән өй сала, гаиләсен күчереп алып килә. Соңрак аның биредә ике улы дөньяга килә. Әсән артыннан аларның туганнары, якыннары, дуслары күченеп килә башлый. Әлеге авылга нигез салучы Әсән һәм аның ике улы хөрмәтенә Үч-Әсән яки Өч-Әсән дип йөртә башлаганнар. Авылның икенче исеме Көчегән – кече авыл мәгънәсендә алынган. *Өч-Әсән авылында Нәҗметдинова Әлфиядән (1998 елгы) Г. Яхшисарова язып алды.*

## Яшерган (Исмәгыйль)

Яшерган авылы 1706–1710 елларда җыела башлаган. Монда әле кара урман булган. Түбәдә алан булган. Түбә дигән авылда. Тәүге йортлар салынып, авыл шуннан үсә башлаган инде. 1751 елны Елизавета императрица, татар халкының Урта Азияне яулап алудагы керткән хезмәтләре өчен, татар зыялыларына (служилый татарлар) Оренбург крепостеннән Уфа крепостенә хәтле юл буйларына татар авыллары төзергә рөхсәт иткән. Шул вакытта Татар Каргалысы, Юзеево, Мостафа (М. Җәлилнең туган авылы), Шарлык, Сарманай, Нәүрез Ибрай, Яшерган, Айдарәле һ.б. татар авыллары тезелеп киткән. Авыллар үскән.

Авылның исеме килеп чыккан шуннан: 1773–1775 елларны була Пугачёв восстаниясы. Каранай авылыннан Каранай Моратов, Салават Юлаевлар катышкан булган. Александр Суворов – безнең генералиссимус килеп бастыра восстанияны. Шул вакытта участникларны эзерлекләү башлана бит инде, шулар качып килеп, Тишекле тау дигән тауга чокып кереп, землянка ясап, шунда качып яткannар инде (Пугачёв явында катнашканнар). Шул качакларны яшереп яткан өчен, халык арасында качакларны яшергән авыл дип йөрткәннәр. Шул яшергән дигән сүз, качакларны яшергән авылга шул яшергән дигән сүз ябешеп калган. Аңа хәтле 1770 елны Каргалы авылыннан чыккан Нократ утарыннан Исмәгыйль дигән старшина килеп, бу җирләрне Дистән карттан сатып ала, үзенең кешеләре белән килеп урнаша. Монда Ибрайга Ибрай дигән кеше, Яшерганга – шул Исмәгыйль, Арсланга – Арыслан, Айдарәлегә – Айдаргали дигән кеше.

Авыл башта Исмәгыйль исемен йөртә, качаклардан соң Яшерганга әйләнә. Авыл шулай үсә, халыклар яши. Шөгыльләре – җәнлекләр аулау, елгадан балык тоталар бит инде, кем умарта, сыер, кәҗә, сарык асраганнар, кайсылары каен тузыннан дегет кайнатканнар – арбаны майлау өчен, күчәр майлаганнар, күмер иләгәннәр, арба ясаганнар, чана ясаганнар һ.б. эшләгәннәр. Әйберләрен Оренбур базарына алып барып тозга икмәккә алмаштырып кайтып көн күргәннәр. Яшерган авылының ташы авылның тарихында зур урын алып тора. Яшерган авылының ташы единственный бер урында чыга ул. Оренбур ягыннан Стәрлетамакка хәтле бөтен мөселман зияратларының кабер ташлары күбесе Яшерган ташыннан эшләнгән. Пычкы белә(н) кисеп, балта белән(н) юынып, ышкы белә(н) ышкып. Әле дә чыга, ясаган кеше бар. Хәзер бит инде мәрмәр-гранит эшләгәч, шуңа күрә спрос әзәйде инде. Элек бит инде специально ташчылар барые. Элек мәчетләрнең ихаталары да, стеналары, фундаментлары да вич шул таш белән уратып алынган иде.

Моңардан тыш халык сарык йонынnan киез басканнар, тула, пима басканнар, свитерлар бәйләгәннәр. Моңардан тыш кәҗә мамыгыннан бәйләгәннәр мамык шәл, шарыф, мамык пирчәтке – кияүгә бирә торган кызның бирнәсенә обязательно атрибут иде инде ул вакытта. Әл(е) дә бирәләр, элекке кебек биргәннәр. Мамык шәлне кем кайда сата, күбрәк Ташкент базарына китеп, шунда сатып кайталар. Шуның белә(н) халык яшәде, шәлләр белән, төп кәсеп булды. Оренбур пуховый платок дип ерласалар да, төп кайнады инде мында. Укучы балалар(ның) күтенә утырганы тотына иде бәйләргә. Әл(е) дә бәйлиләр, менә иптәшем дә бәйли. Бер 10лап шәл бар әле. Киленнәргә әзерләп салып куя. Шунсыз, шуның белә күңелемне тынычландырам, ди, алар бит шуңа өйрәнгән. 1861 елгы

крепостной праваны отменять итү авыл халкына бернинди үзгәреш тә кертмәде. 1909 елгы Столыпин реформасы авылга үзгәреш кертте, чөнки Айтуган авылыннан Кызыл юл авылы чыкты, Ибрай авылыннан чыкты Кызылъяр, бездән Акчишмә авылы чыкты. 12 семья башта. Хрущев перспективные деревни, дигәннән соң таралдылар инде. Кызылъяр бар әле.

Революция, Гражданнар сугышы, аклар белән кызыллар үткән. Әни сөйлидерие әле. Килеп үтәләр, туплар такканнар. Аклар килеп керде, алар алама гына киенгән. Ашык-пошык кына мунча керәләр дә, тегеннән кызыллар килә башлагач, чыгып чабалар качып. Кызыллар әйбәт кожанный курткалар кигәннәр ие. 1921 елны авыл советы оешкан, 1931 елны, берләшеп, колхозларга кергәннәр, колхозлар оештырганнар. Сугыш чорында безнең авыл советыннан 550 кеше яу кырына китә, шуның 347се яу кырында ятып калалар инде. Бу бик зур, күп югалту инде. Аннан соң инде сугыш чорындагы өзеклекне, җимерекне тергезү башлана бит инде. Авылга 1961 елны башлап свет керде. Радио тыңный башладык. 1982 елны авылга су керде. Чишмәдән китердек самотек белән таудан. 1997 елга авылга газ керде. Менә 20 ел булды инде авылга газ кергәнгә. Болай авыллар яшәргә тиеш иде. Авылларның иң үсешкән вакыты 1960–1990 елларга хәтле булды. Ул вакытта 747 йорт барые, 3500 артык кеше барые. Монда мәктәптә генә 1200 бала укыйдырые. Елына 180–200 бала туадырые. Районда сыйдыралмагач, үзебезнең авылда роддом ачылды. Дәүләт думасы депутаты Стәрлебашныкы, Мөхәммәтшакир Тукаев бит инде. Аның малае Габделхәй белән бергә хезмәт иттек без. Энесе Марс главный редактор газеты булды. Алар мәрхүм булды инде икесе дә. Данлыклы мәдрәсә. Чокрыйлар, Мифтахетдин Акмуллалар – бөтенесе күренекле, элек(ке) Стәрлебаш мәдрәсәсе бик данлыклы. Элек авылда 3 мәчет булган. Закон булган халыклар өчен. Бөтен нәрсәне алар хәл иткән. Совет власте чорында да Башкортстанда 3 указной мәчет кала, берсе – Яшерганда, бервакытта да ябылмады. Әле 2 мәчет бар. 25 кеше булырга тиеш иде. Списокта торырга тиеш иде совет чорында. *Яшерган авылында Мухтаруллин Һидиятулла Ибәтулла улыннан (1942 елгы) И. Ямалтдинов язып алды.*

### Яшерган

Яшерган авылы башланганчы – монда башта чувашлар яшәгән. Мин(нем) ишетүем буенча, Нукрат исемле карт килгән беренче. Утырган монда. Чуваш авылы булган. Шуннан соң чувашлар күчеп киткән. Чувашлар чыгып киткәч, татарлар килеп утырган. Каргалы дигән авылдан казак булып хезмәттә йөргәч, аңа җир биргәннәр. Ул туганнарын вич ияртеп апкилгән шул Каргалы дигән Оренбургский областьның авылыннан. Монда Яшерганга килеп утырганнар. Монда куе урман булгач, эзләп табучылар

чак тапканнан соң: «Ну яшеренгәнсең»,–дигәннәр. Шуңардан Яшерган авылы булып киткән.

* * *

Икенче версиясе: Монда Салават Юлаев гаскәре белән үткәндә, кешеләр җыйнаганнар авылга кергән саен. Бу авылга килеп керсәләр, авыл буп-буш. Болар яшеренгәннәр, дип киткәннәр. Шуннан:

Кайсы авылдан син?

– Әнә шул тирәдәге,–дисәләр...

– Ә, Яшеренгән авылыннанмени. Шуңа күрә Яшерган булып киткән.

*Яшерган авылында Хәсәнов Илдус Галинур улыннан (1980 елгы) И. Ямалтдинов язып алды.*

## Ибрай авылының килеп чыгышы һәм тарихы

Авылыбызның исеме дә вакытлар үтү белән бераз үзгәрә торган. Таш асты Ибрай, Ибрай, Түбән Ибрай. Башкортстандагы татар авылларының күп өлеше кебек үк, Стәрлебаш районы Түбән Ибрай авылының тарихы да XVIII гасыр уртасына килеп тоташа.

Явыз Иван Казанны тар-мар итеп, әлеге халыкны яңадан беркайчан да аягына баса алмаслык итеп тулысынча хәлсезлеккә китерергә карар итә. Ул авыл һәм шәһәрләрне яндыра, ир-егетләрне үтерә, татарларны коллыкка сата һәм аларны көчләп чукындыра. Шуңа күрә татарлар күпләп Себергә, Урта Азиягә китә башлый, ә 800 меңе хәзерге Башкортстан җирендә төпләнеп кала.

1745 елда Вятка (борынгы исеме Нохрат) елгасы буендагы Саба авылыннан 200 гаиләдән торган татарлар төркеме, Сәет исемле кеше җитәкчелегендә, Оренбург губернасының Каргалы авылына күченеп утыра. Җайлап, алар аннан бәләкәй төркемнәргә бүленеп күченә башлыйлар. Шул рәвешле 1751 елда Тәтер елгасы буенда да татарлар пәйда була. Аларның агымы аеруча Пугачев восстаниясен бастырганнан соң көчәя.

1751 елны Оренбург шәһәре янындагы Каргалы авылыннан (Сәет бистәсеннән) килгән татар сәүдәгәрләре мең башкортлары белән килешү төзиләр һәм җир сатып алалар.

Башта ташлы тау турындагы Тәтер елгасы буена Каргалыдан Рәхмәтулла дигән кеше җитәкчелегендә 7 гаилә килеп урнашкан. Рәхмәтулла җир хуҗасы була. Алар, арасында аларның малларын куып килүче 1 казах егете һәм 1 казах кызы була. Алар өйләнешеп, бер гаилә булып яшәп китә. Рәхмәтулланың 4 улы була: Шәрип, Кәшәп-Кәшиповлар нәселе (Муллабай абый), Әхмәтвәли-Рәхимовлар (Нәүрүз абыйлар нәселе), Зариф-Саббах бабай или Зарипов Сабитлар нәселе.

Бераздан, таудан ташлар тәгәрәп төшә башлагач, авыл хәзерге урынына күченә – Тасай һәм Пешкәрдәк сулары кушылган җиргә. Тасай һәм Пешкәрдәк исемле кешеләр авылга күченер өчен урын эзләгәннәр. Суларга аларның исеме бирелгән. Чияле тау ягыннан килгән инешкә Тасай диелә. Бүгенге бәйрәм дә Тасай буенда үтә. Елга башыннан килгән елгага Пешкәрдәк дип исем кушыла. Рәсми документларда авыл 1781 елда барлыкка килә, дип язылa. Шулай булса, быел авылга 235 ел була, ә Таштауга килеп утыруларына, чыннан да, 1751 ел булса, 265 ел була.

Биләмәләре Зирекле, Кызылъяр, Ибрай, Гали-Бузат, Старое Любино, Новое Любино, «Әгелчән утары», Спасск авылларының җирләре һәм Изәк-Никитина, Кәлдәй, Айтуган сыртларыннан Тәтер-Арслан межасына, аннан Яшерган каенлыгына кадәрге җирләр була.

Авыл яңа урында төзелә башлый. Аларга Казан һәм Стәрлетамак шәһәрләреннән мещаннар килеп кушыла. Тимерчеләр, буяучылар, тегүчеләр (бертуган Халиковлар) булалар. Припущенниклар урындагы халыктан рөхсәт алып, батрак булып эшлиләр. Авыл дүрткә бүленеп йөргән: «хәҗәен», «ясаклы», «мещан» һәм «припущенник»ларга.

«Хәҗәен»нәр җир хуҗалары булган. Мещаннар Түбән Очта яшәгәннәр. Җирсез, урмансыз, читән өйле булганнар. «Ясаклы»лар, җир хуҗаларына хак түләп, җирне файдаланучылар. Припущенниклар Югары очта яшәгәннәр. Күбрәк солдат хезмәтендә булган кешеләр. Алар урман, җирләрне саклаганнар. Угрылык һәм авылдагы тәртипсезлек белән көрәшкәннәр. Халык мал-туар асраган, игенчелек, урманчылык белән шөгыльләнгән, сәүдә белән көн иткән. Сөренте җирләр аз булу сәбәпле, өстәмә хәзерләү, күмер яндыру, курыс кисү һәм башка эшләр булган. Урманны Айтуган сыртыннан һәм Стрельцовка урманнарыннан алганнар, чөнки аннан Шарлык базары якын була. Урман әзерләүчеләр кыш буе землянкаларда яшәгәннәр. Ул вакытта чәй кайнатырга самавырга салырга, үтүк кыздырырга һәм тимерчеләргә күмер кирәк булган.

Авылда ике мәхәллә булган (мәхәлләне кеше саны буенча ачарга рөхсәт иткәннәр).

Кызлар да надан булмаган. Гарәпчә укырга өйрәнгәннәр. Авылдашлар тырышып дөнья көткән. Илдә булган хәлләрнең берсе дә авылыбызны читләп үтми. Бик күп авылдашларыбыз Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша. Аннары Гражданнар сугышы башлана. Аклар һәм кызылларның бәрелешләре авылдан читтә, Ташлы тау янында була. Авыл халкына зыяннары тими, бары тик ике як та күченү өчен олаулар гына алганнар. Бу хәлләр 1919 елны була.

1921 ел җитә. Бу елны тоташ ил буенча корылык була. Авыл яна. Янгыннан соң авылда унлап кына йорт калган. Шушы сәбәпләр аркасында

бик күп кешеләр читкә китә. Оренбург, Урта Азия, Казахстан һәм башка якларга.

Авылның (беразы, 7 гаилә халкы) әлеге Кызылъяр авылы урынына күчә. Калган халкы Елга башы янында землянкаларда яши башлаган. Бердән авылга кайтырга кирәк, дигән фикергә киләләр. Кайтып йорт урыннарын көлдән тазарталар. Авыл халкы бик авырлык белән йорт-илне аякка бастыра башлый. Әлбәттә, 1921 елга (кадәрге) кебек төзелгән карагай йортлар аз була. Мәчет урыны – Исмәгыйлев Шамил абыйның бәрәңге бакчасы урыны. Авылда төзелеш эшләре барганда, халыкның канау төзергә вакыты да булмый, 1928 елларда канау төзү эше башлана. Канау башында һәм Мунчала күле чокырында 2 зур буа төзелә.

1970–1971 елларда авылга суүткәргеч сузалар. Халык тырышып эшли, тормыш матурая бара. Ләкин шул вакытта, 1941 елны сугыш башлана. Безнең Ибрай авылыннан 149 кеше сугышка китә. Ләкин кире әйләнеп кайту барысына да насыйп булмый. Авылыбызның 80 ир-егете яу кырында башын сала. *Яшерган авылында Локманова Рәйсә Равил кызыннан (1955 елгы) Г.Яхшисарова язып алды.*

### Айдарәле

***Урта тау.*** Бу якта торган тау Айгыр тавы дип атала, урталыгында ***Чишмәле тау***, бу яктагысы ***Мәчет тавы*** – шуннан кисеп мәчет салганнар. Аска төшкәндә мәчет урыны бар иде, шуннан мәктәп булды. Усаклык, шуннан китә ***Зират тавы*** – авылның башында. Анда Айдар бабайның зираты бар, аны уратып алынган. Шушы очтан башланган авыл. Бабайның исеме Айдаргали булган. Авылның исеме Айдарәле булып киткән. Бабайның ташы шул үлгәч куелган таштыр инде ул. Соңгы председателебез куйдырткан таш. *Айдарәле авылында Мишарова Нурия Зариф кызыннан (1950 елгы) И.Ямалтдинов язып алды.*

### Әхсән

Аклар-кызыллар сугышы вакытында. Шушы Стәрлебаш авылында, революция елларында, Гражданнар сугышы башлана башлагачтын. Комсомоллар оешмасы төзиләр бит инде. Балаларны, яшьләрне яшүсмерләрне җыйнап утырталар да бинага: «Егетләр-кызлар, кайсыгыз(ның) комсомолга керәсе килә?» Берсе дә эндәшми, куркалар. Дини яктан көчле булган чак була бит инде. Беренче комсомолец булып Әхсән исемле егет кул күтәрә. Комсомол булып кереп китә бит. Шуннан соң аклар-кызыллар сугышы китте. Безнең мәчетебезнең бер бинасын клуб ясыйлар. Хәзер шунда Бизгин дигән авыл бар, шунда алпавытның фортепианосын алып төшәләр. Анысы рус авылы. Теге баланың музыкальный сәләте булды микән инде. Гайфулла исемле дусты белән чыңгырдатып утырганда,

бертөркем ирләр килеп керә, атларга атланган, киемнәре буенча билдәле булмый, аклар микән, кызыллар микән?

– Егетләр, сез кемнәр?

– Без комсомоллар, абый.

– Комсомоллар булгач, әйдәгез, чыгыгыз әле. Апчыгалар да, чыгу белән бәреп егалар балаларны, икесен дә. Ат койрыгына тагалар. Шуннан бөтен Стәрлебаш буйлап йөртеп, күрше генә бер авыл бар безнең – Ибракай, шул Ибракай тауларына алып баралар. Ике дистәгә якын хәнҗәр белән казап, теге баланы үтерәләр. Гайфулласы беренче сугу белән ук егыла, үлгәнгә салышып ята. Ансы исән кала азакта, көч хәлләр белән. Монысы бит инде үлә бу бала. Хәзер моны берсе бер кулы белән сугып очыралар, аннан икенче кул. Әхсән исемле. Апкайталар, әтисе-әнисе булмый бу баланың, картәтисе үстергән була. Картәтисе кич көне кояш төшә бит инде. «Улым, Әхсән», ди. Күз күрми. Таяк белән ихатага суга-суга эзләп йөри. Юк. Капчыкларга тутырып апкайталар бу баланың гәүдәсен. Халык шул тиклем яраткан була бу баланы. Һәм безнең Стәрлебашыбызның бер урамына Әхсән исеме кушалар бит инде. *Стәрлебаш авылында Гыйзетдинова Зөлфия Зиннәт кызыннан (1961 елгы) И. Ямалтдинов язып алды.*

### Стәрлебаш авылының тарихы

Стәрлебашны элек-электән элеке Бохара дип йөреткәннәр. Мәдрәсәләре белән бик данлыклы булган. Төрле регионнардан, төрле җирләрдән килеп укыганнар. Бу мәдрәсәдә дини белем генә бирмәгәннәр, ә точный наукаларны өйрәткәннәр (математика, география, естествознание, астрономия). Мәдрәсәне укып чыккан кешеләр мөгаллим, мөгаллимә булганнар. Мәдрәсәдә яшәгәннәр, столовые булган. Бөтен расходларын Тукаевлар каплаган. Ә менә Мифтахетдин Акмулланың әнисе татар хатыны булган. Өммегөлсем исемле. Ә этисе казакъ булган. Өммегөлсем апа Тукаевларда яшәгән булган. Акмуллага 5 яшь тулгач, Өммегөлсем апаның ире үлгән. Шуннан Өммегөлсем апаны Миякә районы Туксанбай авылына бер башкорт иренә кияүгә биргәннәр. Үзе белән Акмулланы да алып киткән. Ана шунда ничәдер яшькә кадәр тәрбияләнгән. Шуннан кимсетүләргә түзәлмичә, Акмулла өеннән чыгып киткән.

Мин белгән чакта 3 фонтан бар иде, аны фантал дип йөртә иделәр. Аларның башы куполообразный тимер белән ябылган иде. Тимер ручка буладыр иде. Без элек гел шунда су алырга килә идек. Ул суның чисталыгы. Шуннан әби-бабалар әйтә торган иделәр: «Стәрлебашның суын эчкән кеше, обязательно икенчегә әйләнеп кайта». Тау янында чишмә бар. Аны чишмә башы дип йөртәләр. Минем бабай әйтә торган иде: «Шушы фонтаннарга агач трубалар эшләп үткәргәннәр. Бер грамм

черемичә ул трубалар җир астыннан чыкмый». Менә нинди агачтан эшләткәннәр аны, ничек эшләгәннәр? Менә шушы Тукаевлар заманында әтием сөйлидер иде.

Минем әнием сөйли иде. Граждан(нар) сугышлары вакытын сөйли иде. То килеп керәләр иде аклар, то кызыллар. Аклар килеп керсәләр, кыз балаларны базга яшерәләр иде, ди. Утыра идек базда, күренмичә, куркып. Стәрлебаштан чыгып китсәләр, баздан чыгадыр идек, ди. Бигрәк тә комсомолец исемен йөреткәннәрне эзәрлекләгәннәр. Блюхер отрядлары да моннан үткән, тау башларыннан үткән. Окоплары әле дә сакланып калган. Өй нигезләре ясаганда, шуннан ком алырга йөрегәннәр. Кайбер вакыт аннан оружиялар да чыккан, ди. *Стәрлебаш авылында Галиева Зәйтүнә Рәхмәтулла кызыннан (1945 елгы) Г. Яхшисарова язып алды*.

### Кулланылган әдәбият


1. Атлас татарских народных говоров / отв. ред.: Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хайрутдинова. Изд. 2-е, доп. и перераб. Казань: ИЯЛИ, 2015. С. 28–36.
2. Республика Башкортостан // Регионы компактного проживания татар в Российской Федерации: справочник. АН РТ, Ин-т тат. энцикл. и регионоведения. Казань, 2016. С. 137–140.
3. Ямалтдинов И.И. Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX в. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 35–36.

*И.З. Гарифуллин*

# ОСОБЕННОСТИ ВОЗНИКНОВЕНИЯ ТАТАРСКОГО ТЕАТРАЛЬНОГО ИСКУССТВА В БАШКОРТОСТАНЕ

Одной из главных проблем в области этнокультурного развития татар республики в конце 1980-х гг. было полное отсутствие в Башкортостане татарских профессиональных театров. В резолюции учредительной конференции ТОЦ БАССР от 14 января 1989 г. отражено требование «Возродить в Уфе татарский драматический театр, который существовал с 1912 по 1922 гг. Необходимо также открыть татарские театры в Туймазах, Нефтекамске и Дюртюлях» [Резолюция: 1989]. Как видим, татарское национальное движение стремилось сформировать широкую сеть татарских театров в республике. При этом специально отмечалось, что в Уфе в свое время уже существовал татарский театр, то есть указывалась преемственность, и, самое главное, обосновывалось историческое притязание на Уфу как на центр татарской культуры. Именно в этой связи вкратце рассмотрим короткую, но яркую предысторию рождения татарского театра в этом городе в начале XX в.

Впервые занавес татарского театра открылся в Уфе в 1912 г. Организатором татарской труппы с поэтичным названием «Нур» (в переводе означает «луч») была 19-летняя Сахибжамал Гиззатуллина-Волжская. Являясь воспитанницей труппы «Сайяр», она стала первой актрисой не только татарской сцены, но являлась таковой и среди других тюркоязычных народов. Сама Сахибжамал стала и режиссером, и первой профессиональной артисткой. Репертуар театра состоял как из произведений татарских драматургов (М. Файзи, Г. Камала, Ф. Амирхана, С. Рамиева, Г. Колахметова), так и русских и зарубежных классиков (А. Островский, Ж.Б. Мольер, Г. Гете, Ф. Шиллер, О. Деннери). С 1912 по 1918 гг. молодая театральная труппа активно работает, гастролируя по всему Уралу и Поволжью, Средней Азии и Северному Кавказу, Крыму и Западной Сибири [https://teatrnur.ru]. Из-за сложной политической обстановки в годы Гражданской войны труппа распалась. Тем не менее, театр официально просуществовал вплоть до 1922 г., когда в период образования Большой Башкирии окончательно прекратил свое существование. Причем часть актеров театра «Нур» была вынуждена уехать в Казань (Нури Сакаев и др.), а часть влилась в состав труппы башкирского драмтеатра, переехавшего в 1922 г. из Стерлитамака в Уфу. Актер Валиулла Муртазин-Иманский (Мортазин), когда-то участвовавший в работе труппы «Нур», стал основателем башкирского драматического театра, ныне носящего имя

Мажита Гафури. Основательница театра «Нур» Сахибжамал Гиззатуллина-Волжская в 1923 г. также перешла в труппу Башдрамтеатра, но в конечном итоге уехала в ТАССР.

В советское время предпринимались попытки возродить татарский театр в Уфе. В частности, Ахат Арсланов, бывший руководителем Аургазинского татарского колхозно-совхозного (передвижного) театра, после его закрытия в 1954 г. (театр перенесли в г. Салават и сделали его башкирским) предпринимал усилия в этом направлении. Учитывая большую долю татарского населения в Уфе, он просил у властей города хотя бы открытия татарского народного театра. Народный театр при ДК им. Орджоникидзе в конечном итоге был открыт, только не татарский, а башкирский. Не согласный с такой ситуацией А. Арсланов отказался его возглавить.

Полное отсутствие в Башкортостане татарских профессиональных театров стало одной из проблем, поднятых татарским национальным движением в конце 1980-х гг. В резолюции Учредительной конференции ТОЦ БАССР от 14 января 1989 г., как было указано, впервые публично прозвучало требование восстановления театра «Нур», а также необходимость открытия татарских театров в Туймазах, Нефтекамске и Дюртюлях [Резолюция: 1989] – в городах со значительным татарским населением.

В итоге в 1989 г. решением Исполкома Уфимского городского Совета была открыта театр-студия «Нур».

2 августа 1989 г. в Башкирском Обкоме КПСС состоялось совещание между представителями татарской общественности республики и представителями властей. На этом совете обсуждался вопрос об открытии в республике татарского театра. Со стороны татарских объединений участвовали: поэт, член правления ТОЦ Ф. Габдрахимов, председатель ТОЦ М. Рамазанов, ответственный секретарь ТОЦ К. Яушев, председатель татарского клуба Н. Бадретдинов, член правления ТОЦ Р. Хакимов, заместитель председателя ТОЦ А. Халим. Со стороны властей: инструктор ЦК КПСС А. Солодовников, заведующий отделом культуры Башкирского Обкома Т. Сагитов, заведующий сектором межнациональных отношений и зарубежных связей Башкирского обкома КПСС А. Аринин (позднее председатель движения «Русь», депутат Госдумы двух созывов, ярый критик политики М.Г. Рахимова) [Халим: 1996. С. 86].

Представители властей в лице Солодовникова, Сагитова и Аринина настаивали на том, чтобы татарский государственный театр, открытие которого требовала татарская общественность республики, был построен в г. Туймазы. При этом они исходили из следующих соображений: 1. В Туймазах проживает 30 тыс. татар; 2. Вокруг города расположено множество татарских районов; 3. Вопрос с кадрами в этих условиях легче все-

го решить. Проблему жилья для сотрудников и здания для театра также легко решаема. Представители татарских объединений, в свою очередь, настаивали на строительстве театра в столице республики Уфе. Их контраргументами в свою очередь послужили: 1. В Уфе проживает 350–400 тыс. татар (учитывая кроме собственно татар – около 285 тыс. чел., еще многочисленных татароязычных башкир – И.Г.). Вокруг Уфы 30 районов с компактным проживанием татарского населения; 2. В городе Туймазы никогда не было профессионального театра, поэтому там не может быть и хороших кадров; 3. В Уфе около дюжины дворцов культуры стоят полупустыми. Кроме того, в городе-миллионнике проблему с жильем для работников театра решить также намного проще; 4. Организация театра в Туймазах создаст форпост на границе Татарстана и Башкортостана, затрудняющий культурный обмен между республиками, возникнут препятствия для гастролей татарских театров Татарстана, к тому же наличие татарского театра в столице будет способствовать ее здоровой конкуренции с Башкирским академическим театром. Указывалось, что нежелание строительства татарского театра в Уфе вызвано также и боязнью перехода талантливых кадров татарского происхождения из Башдрамтеатра в новоявленный театр «Нур»… [Халим: 1996. С. 86].

Таким образом, татарское национальное движение выступало за татарский театр в Уфе, считая, что это будет еще одним положительным фактором в деле этнической консолидации татар республики, так как роль Уфы, как центра принятия решений, касающихся судьбы республики, несомненно выше любого другого города Башкортостана. В данном случае, как мы видим, вопрос стоял таким образом – татарский театр нужен республике, этого никто не оспаривал. Вопрос был лишь в том, где его открыть. Причем речь в этом случае шла только об одном театре, несмотря на желание татарской общественности открыть театры в ряде городов республики. То есть, если театр открывался, как того хотели татарские объединения, все-таки в Уфе, то в этом случае вопрос о театре в Туймазах или в любом другом городе республики закрывался автоматически. При этом, несомненно, в интересах татар Башкортостана было наличие в республике не одного, а по возможности, нескольких учреждений подобного рода.

В итоге Туймазинский государственный татарский театр был учрежден Постановлением №78 Совета Министров Башкирской АССР от 6 апреля 1990 г. [https://kulturarb.ru]. Тем не менее приказом того же Совмина Башкирской ССР №205 от 29 августа 1991 г. было постановлено открыть в Уфе государственный татарский театр «Нур» [Халим: 1996. С. 221].

После официального приказа об открытии в Уфе татарского театра, остро встала проблема его размещения. Одним из наиболее вероятных проектов было перепрофилирование нового кинотеатра на проспекте С. Юлаева. Активное участие в разработке будущего проекта театра принял участие и Уфимский татарский культурный центр. Проектировщиком выступил институт «Башкиргражданпроект» [http:tatarfact.ru/?p=1072]. В 1999 г. состоялся переезд в новое здание.

Тем не менее, работа по возрождению татарского театра продолжалось еще несколько лет, так как, несмотря на переезд театра в новое здание, строительство еще не было завершено. В итоге артисты были вынуждены ставить спектакли на малой сцене театра. Необходимость завершения строительства неоднократно поднималась на Первом и Втором съездах татар Башкортостана в 1997 [Резолюция: 1997] и 2003 гг. [Резолюция: 2002] соответственно. Наконец в июле 2003 г. вышел Указ Президента РБ «О дополнительных мерах по удовлетворению национально-культурных потребностей татарского населения Башкортостана» [http:zakon-region3ru/1/32855]. В одном из 4 пунктов этого Указа значилось завершение строительства театра «Нур». Согласно этому документу реализация всех ее пунктов предполагалась уже к концу 2003 г., тем не менее здание татарского театра было полностью сдано к эксплуатации только к концу 2007 г., и на этом долгая эпопея с возрождением театра «Нур» закончилась.

Таким образом, татарский театр «Нур», насчитывающий более чем столетнюю историю, несомненно является национальным достоянием не только татар Башкортостана, но и российской культуры в целом, поэтому вопрос о его возрождении, остро стоявший в конце 1980-х гг. являлся знаковым для эпохи демократических преобразований в нашей стране.

Деятельность татарских национальных объединений по развитию в республике татарского театрального искусства можно считать успешной. Когда в 1989 г. начались переговоры между представителями татарского национального движения и официальными властями, вопрос стоял об открытии только одного театра. Однако татарский театр в итоге был открыт и в Туймазах, на чем изначально настаивали официальные власти, и в Уфе, чего усиленно добивались татарские общественные организации. Настойчивость и принципиальность сторон в данном случае сыграла свою положительную роль. Восстановление театра «Нур» стало большой победой всей татарской этнонации, так как этот театр был одним из родоначальников татарского профессионального театрального искусства. К тому же «Нур», наряду с группой «Сайяр», был в свое время первым театром среди всех тюркских народов России. Можно с уверенностью

сказать, если бы не усилия татарских национальных объединений в данном вопросе, у татарского театра изначально было мало шансов на появление в столице Башкортостана.

**Источники и литература:**


1. Резолюция собрания представителей татарской общественности Уфы по обсуждению тезисов платформы татарского общественного центра (ТОЦ). 14 января, 1989 г. // Из личного архива Р. Яруллина.
2. Резолюция собрания представителей татарской общественности Уфы по обсуждению тезисов платформы татарского общественного центра (ТОЦ). 14 января, 1989 г. // Из личного архива Р. Яруллина.
3. Резолюция I съезда татар Башкортостана 1997 г. // Из архива Конгресса татар Башкортостана.
4. Резолюция II съезда татар Башкортостана 2002 г. // Из архива СООТ РБ.
5. Халим А. Гомеремнең ун көне. (на тат яз.). Тольятти, 1996. – 563 с.
6. Указ Президента РБ «О дополнительных мерах по удовлетворению национально-культурных потребностей татарского населения Башкортостана от 4 июля 2003 г. // http:zakon-region3ru/1/32855/. Электронный ресурс (дата обращения 17.05.2021).
7. Дореволюционная история / Сайт Уфимского государственного татарского театра «Нур». Электронный ресурс URL:teatrnur/%D0%B4%D0%BE%D1%80%D%B5%D0%B2%D0%BE%D0%BB%D1%8E%D1%86%D0%B8%D0%BE%D0%BD%D0%BD%D0%B0%D1%8F-%
8. D0%B8%D1%81%D1%82%D0%BE%D1%80%D0%B8%D1%8F/ (дата обращения 17.05.2021).
9. Туймазинский татарский государственный драматический театр // Сайт Министерства культуры Республики Башкортостан. Электронный ресурс URL://kulturarb.ru/ru/teatry/tujmazinskij-tatarskij-gosudarstvennyj-dramaticheskij-teatr (дата обращения 17.05.2021).
10. Элект. издание Татарфакт // http:tatarfact.ru/?p=1072 (дата обращения 25.05.2016).

**Фәнни-популяр язмаларда төбәк тарихы**

**Краеведение в научно-популярных публикациях**

***И.Р. Котдусов***

## ТАТАРМЫ БЕЗ, БАШКОРТМЫ?

«Яңа көн» район газетасында 2020 елның 18 декабрендә чыккан бер мәкалә кулыма каләм алырга мәҗбүр итте. Ул – «Кушнарен районы җанисәп мәгълүматларында» дип атала. Бу мәкаләдә XVIII–XIX гасырларда үткән җанисәп (перепись, ревизия) буенча «Кушнарен районының милли составы» бирелә. Авторлары – профессорлар Н. Мәҗитов, Н. Кульбахтин.

Бу таблица үз эченә 1795–1989 еллардагы үткән жанисәп вакытларын ала. Таблица 1795 елдан башлана һәм монда авылларның милли составы күрсәтелә. Барысы да әйбәт, барысы да яхшы кебек! Әмма, сорау туа: 1795 елгы җанисәп ничәнче? Беренчеме? Бәлки, икенчедер? Юк, урыс әйтмешли, не угадали! 1795 елгы жанисәп – бишенче, ә 1859 елгысы – унынчы! Кая соң 1, 2, 3, 4 жанисәп нәтиҗәләре? Чыннан да, андагы яшәгән халыкның милли составы нинди булган? Ни өчен 1–4 җанисәпкә хөрмәтле тарихчылар күз йомган?

***1 җанисәп*** (ревизия, перепись) – 1718–1727 елларда үтә (Казан губернасы, Уфа провинциясе, Казан даругасы).

***2 ревизия*** – 1743–1747 елларда үтә (Оренбург губернасы, Уфа өязе, Казан даругасы).

***3 ревизия*** – 1761–1764 еллар (Оренбург губернасы, Уфа өязе, Казан даругасы).

***4 ревизия*** – 1781–1782 еллар (Оренбург губернасы, Уфа өязе, Казан даругасы).

Башкорт тарихчы коллегалар шушы 1–4 ревизия материалларын һәрвакыт «күрми» үтәләр. 2020 елның ахырында Татарстанның Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты, Башкортостан тарихчылары һәм краеведлары белән тыгыз хезмәттәшлектә, ниһаять, Мәскәү дәүләт тарих архивында (РГАДА) берничә ел эшләп, 1–4 ревизия материалларына нигезләнеп, «Татары Уфимского уезда» дигән белешмә чыгарды. Хәзер һәрбер кеше бу белешмәне интернетта укый ала [http://админ.та-

таровед.рф]. Менә мин дә шул белешмәгә нигезләнеп, бүгенге Кушнарен районына караган авыллар буенча мәгълүмат бирәм. Шушы авылларга кемнәр нигез салган, кемнәр яшәгән? Авыл исемнәрен шул вакытта ничек язылган булса, шулай күрсәтәм. Һәрбер материал астында архив фонды, исемлеге (опись), башкару эше (дело), бите (лист) күрсәтелә (мисал өчен: Ф. 350. Оп. 2. Д. 326. Л. 290). Кем киләчәктә ныклап үзенең нәсел җепләрен табарга уйлый икән, рәхим итеп карагыз!

***1 ревизия, 1722 ел (РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 178):***

«Рысмекеево, что на речке Чермасане служилые мещерики» (Л. 51);

«Наврузово, что на речке Ботарле служилые мещерики» (Л. 53);

«Рысмекеево, что на речке Чермасане ясашные татары» (Л. Д. 3790. Л. 290–291).

Беренче ревизия (1722 ел) буенча Рәсмәкәй авылында йомышлы («служилые») мишәрләр һәм ясак түләүче («ясашные») татарлар (иген игүче, мал асраучы крестьяннар) яшәгән. Татар-мишәрләр авылда иген иккән, мал асраган һәм хәрби гәскәрдә хезмәт иткән. Шул ук вакытта «служилые» (йомышлы) татарлар белән «служилые» (йомышлы) мишәрләр Урал (Җаек) елгасыннан башлап Урал тауларына кадәр Рәсәй чиген кайсак-кыргызлардан (казакъ), калмыклардан саклаганнар. (Әйтергә кирәк, чикне татар-мишәрләрдән тыш башка халыклар да саклаган: казаклар, башкортлар, йомышлы татарлар, нагайбәкләр һ. б.).

Навруз авылы (ниһаять, табылды бит!). Мин бу авыл турында Байталлы авылының 210 еллыгында әйтеп үткән идем. Тик ул вакытта минем кулда шул вакытлардагы карта гына бар иде. Ә хәзер ныклап әйтә алабыз: моннан 314 ел элек «служилые» мишәрләр килеп утырган авылны Навруз дип атаганнар! Ә Байталлы авылы исемен, аннан соң, ясаклы татарлар алып килә (2 ревизияне кара). Авыл картлары әйткән сүзләренә карасак, авылда ике мәчет булган. Димәк, авыл зур булган. Менә каян ул бер урында ике авыл – Навруз һәм Байталлы!

«Калтаево служилые мещеряки» (Л. 46–48).

«Бакаево, что на речке Чермасане служилые мещеряки» (Л. 48 об.).

«Токмаклы, что на речке Керекейке служилые мещеряки» (Л. 49–49 об.)

«Курмашево, что на речке Кудюшле служилые мещеряки» (Л. 52–53).

«Досметово, что на речке Кудюшле служилые мещеряки» (Л. 54).

«Ураза, что на озере Куляше служилые мещеряки» (Л. 69–69 об.).

Калтай, Бакай, Тукмаклы авыллары монда аңлашыла. Ә менә «Досметово» авылы кайда ул? Досмәт авылы хәзерге Благовар районында бар, әмма 1722 елгы җанисәптә ул «Досмет на речке Черемасане» дип язылган. Кѳдешле елгасы буенда Досмәт авылы – ул, шул ук, Иске Кѳдешле яисә Иске Кормаш авылының бер очы булырга мөмкин. Мисал өчен:

Навруз – Байталлы, Тукмаклы – Печмән Муса – Хан-морза авыллары. Шундый ук хәл Ураза авылы белән, кайда ул? Куляше күле кырында икәне билгеле... (оз. Куляшка?). Район тарихын өйрәнүчеләргә эш бар әле...

«Камышенки на речке Камышенке ясашные татары» (Д. 3790. Л. 280).

«Ильмурзины, что на озере Чортанле ясашные татары» (Л. 282–282 об.). Осн.1691 г. ясачными татарами, перешедшими в кон. XVIII века в сословие тептярей, и мишарями. Первопереселенец Ильмурза Янбахтин [Башкирская энциклопедия: 2005].

«Тоганаевой, что на озере Тоганаеве ясашные татары» (Л. 283 об.).

«Григорьевой, что на речке Мишеде ясашные татары» (Л. 288–289). (Гөргөри авылы – автор.).

«Токмаклы что на речке Керекейке ясашные татары» (Л. 289–290).

«Досметова, что на речке Кудюшле ясашные татары» (Л. 291–291 об.).

Тагын да бер билгесез авыл – Сюндюково! «Книги переписной Уфимского уезда иноверцам, служилым мещерякам и горным татарам ...по Казанской дороге с 1722 по 1723 годах» [РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 178. Л. 148]. Бу авыл күрсәтелгән: «Сюндюково, что на речке Чермасане служилые мещеряки». Бу авылның исеме морза Сюндюковлар белән бәйләнгән булырга тиеш. Байталлы авылының шәҗәрәләрендә шундый факт бар: шушы вакытта Бакайдан Сөендек морза нәселенең бер өлеше Байталлыга (Навруз) күчә. Икенче бер факт: Бакай кырындагы Чатра авылында морзалар яшәгән (Моратов, Мамлиев). Әлеге фактларга таянып, Сөендек авылын Бакай тирәсеннән эзләргә кирәк.

«Татары Уфимского уезда» белешмәсенең 1 ревизия материалларында Карача-Елга авылы күренми. Без Карача-Елга авылын Башкортостан энциклопедиясеннән таба алабыз. «Карача-Елга основано 1739 году мишарями д. Аминово (ныне Чишминский район). В 1754 году здесь поселились мишаре из д. Иштиряково Сибирской дороги (ныне Балтачевский район)» [Башкирская энциклопедия: 2005].

Тагын да бер авыл – Солтанай. Башкорт энциклопедиясендә ул бар: «Султанаево основан в кон. XVII в. Предположительно В 1714 или 1720 гг. здесь поселились мишяре и тептяре» [Башкирская энциклопедия: 2005].

Шулай ук, Башкорт энциклопедиясендә Талбазы авылында 1717 елда типтәрләр яшәгәне әйтелә, XVIII гасырның азакларында – мишәрләр [Башкирская энциклопедия: 2005]. Минем уйлавымча, монда бераз гына хата киткәндер: башта авылга мишәрләр нигез сала, типтәрләр түгел. Чөнки 1734 елдан соң гына типтәрләрнең рәсми рәвештә социаль статусы билгеләнә.

Чирша-Тартыш. «По договору 1713, 1779 и 1802 гг. о припуске здесь поселились ясачные татары, перешедшие в последствии в сословие тептярей» [Башкирская энциклопедия: 2005].

Шарипово «...известно с 1688 года. С начало XVIII века (деревня – прим. автора) фиксировалось как Мряково (по имени волостной старшины Шерипа Мряково. В конце XVIII века по договору о припуске здесь поселились мишари и тептяри» [Башкирская энциклопедия: 2005].

Шәрип авылы тарихы турындагы төрле уй-фикерләр бар. Башкорт тарихчылары Шәрип авылын башкорт авылы дип санап килделәр. 2002 елга җанисәп алу алдыннан, Бөтендөнья башкортлары корылтае һәрбер район өчен махсус методик кулланмалар чыгарды. Бу кулланмада Кушнарен районындагы авыллар – башкорт авыллары дип санап кителгән иде. Хәтердә калганы: башкорт старшинасы Шәрип Мряков турында күп язылган иде. Шәрип Мряков – башкорт, Шәрип авылына нигез салучы, җирләр сатучы һ. б., кыскасы – шәп кеше! Мин ул вакытта әлеге кулланманың соңгы җөмләсенә игътибар иттем, анда болай дип язылган: «Шарип Мряков был активным участником подавления башкирских восстаний». Мин уйга калдым: «Шәрип Мряков үзе башкорт, ә үзе башкорт восстаниеләрен актив бастыручы?! Ничек була инде ул?!» Озак та үтмәде, миңа Башкорт дәүләт университетында тарих кафедрасы житәкчесе, минем фәнни җитәкче, безнең якташ, Каратәкә егете, Риф Салихович Аюпов янына керергә туры килде (авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең, бик яхшы кеше иде). Риф Салиховичка бу мәсьәләне сөйләп биргәч, ул миңа: «Син Диас Хатыпович Яндуринга әйт, ул бу тема буенча белгеч!» – диде. Диас Хатыпович, профессор, тарих фәннәре докторы, Риф Салиховичның урынбасары. Мин дә Диас Хатыповичны беләм. «Диас Хатыпович, ни өчен башкорт Шәрип Мряков башкорт восстаниеләрен актив бастыручыларның берсе булган?» – димен. Диас Хатыпович мина кычкырып җибәрмәсенме: «Шәрип Мрясов нинди башкорт булсын ул? Мишәр ул! Безнең Салават районындагы минем олы атайларны бастырган кеше ул! Шуның өчен аңа безнең җирләрне биргәннәр!» Мин Шәрип Мрясовның хәзерге Салават районында да җирләре барын белми идем әле...

Якуп авылы. «Основано в I пол. XVIII в. Первопереселенец – Ишали Якупов. В 1734 г. здесь поселились мишари, в конце XVIII в. – тептяри» [Башкирская энциклопедия: 2005].

***2 ревизия, 1743–1747 еллар (РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 3792. Ч. 2):***

«Рысмекеево, что на речке Черемшане ясачные татары» (Л. 37);

«Рысмекеевой, что на речке Чермасане служилые мещеряки» (Д. 3793. Л. 148–150);

«Емурановой, что на речке Чермасане служилые мещеряки» (Д. 3793. Л. 150–151);

«Байталы, Наврузово тож, что на речке Байтале служилые мещеряки» (Л. 143–146);

«Наурузовой ясашные татары» (Л. 252);

«Копаевой, что на речке Чермасане служилые мещеряки» (Л. 146–148). (*Купай авылы – автор*).

Беренче мәртәбә Купай авылы телгә алына. Купай авылы картлары әйтеп калдырган сүзләре дөрескә килә. Купайлылар рәсмәкәйләрдән соң килгән. Ә соңрак килгән халык елганың башына түгел, ә төп авылның артында калган елга буена утырган. Ә менә купайлыларның «без бу җирне сугышып, рөхсәтсез алдык!», дигән сүзләре дөрескә килә. Алар Чәрмәсәннең башына утыралар.

«Ильмурзино, что на озере Чертанлекуле ясашные татары» (Л. 28–29 об.).

«Григорьевой, что на речке Мишаде ясашные татары» (Л. 28–29 об.).

«Токмаклы, что на речке Кереке ясашные татары» (Л. 35–36 об.).

«Кулсеитовой, что на проточном ключе ясашные татары» (Л. 32–34 об.). Бу авыл бүген кайда? Югары Сәет булса, ул «на Чермасане» дип язылыр иде. Ә Гомәр Сәете 1924 елда гына барлыкка килә. Бу эш район тарихын өйрәнүчеләргә кала.

***«Книга переписной 1747 г. – ясачных татар, служилых татар и мещеряков Казанской дороги Уфимского уезда». (РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 3793):***

«Калтаевой, что на речке Мешеде служилые мещеряки» (Л. 103–110 об.).

«Акметевой, что на озере Менези служилые мещеряки» (Л. 110–112). (*Әхмәт авылы – автор*).

«Тярибердиной, что на речке Зерыклы служилые мещеряки» (Л. 115–116 об.).

1790 елда Степановка авылына (Кушнарен) капитан С.Е. Топорнин нигез сала һәм крепостной крестьяннар алып килә. 1795 елда Степановкада 111 ир-ат крестьяннар яши [Притяжение земли: 2000. С. 8–9]. Шунысы кызыклы: мин Тәрбирдене (Тарабердино) урыс авылы дип белә идем, аңа «служилые мещеряки» нигез салганын белми идем. Шундый ук хәл Баскак авылы белән: 1791 елгы Федор Черныйның картасында Баскак авылы мөселман авылы итеп күрсәтелгән [Генеральная карта: 2006].

«Досметовой, что на речке Кудушле служилые мещеряки» (Л. 117–126).

«Муначевой, что на речке Кудешле служилые мещеряки» (Л. 126–128).

«Курмашевой, что на речке Кудюшле служилые мещеряки» (Л. 128 об–134).

Тагын бер таныш булмаган авыл – «Муначевой»! Игътибар итегез: җанисәп язуларында Досмәт – 117–126, Муначево – 126–128, Курмашево – 128–134 битләрендә! Бу өч авыл бер-бер артлы язылган, бер елга буенда. Димәк, бу авыллар бер-берсенә якын урнашкан булган! Иске Кор-

маш авыл советы башлыгы Флорид әфәнде Гыйрфанов үз авылларының тарихы белән кызыксына, афәрин. Һәм аңа менә тагы бер эш – бу авылларны табарга кирәк. Ышанам, таба да ул.

«Акбашевой служилые мещеряки» (Л. 134–135 об.) .

«Якуповой служилые мещеряки» (Л. 135–140).

«Старой Кудошли, что на речке Кудяшле служилые мещеряки» (Л. 140–143).

«Бакаево служилые мещеряки» (Л. 143–146 об.).

«Ерекшан, Исланово тож, что на речке Чермасане служилые мещеряки» (Л. 152–153 об.).

«Саитовой, что на речке Караче служилые мещеряки» (Л.152–153 об.).

«Каратеки, что на речке Кареке служилые мищеряки» (Л. 230–231 об).

(д. Каратяки. По договору 1719 г. поселились служилые татары, перешедшие впоследствии в сословие тептярей [Башкирская энциклопедия: 2005]).

«Токмаклы служилые мещеряки» (Л. 232–236).

«Акмушевой, что на речке Кармасане служилые мещеряки» (Л. 236–237 об.) (*Иске Гомәр Акбашы – автор*).

«Ильмурзиной, что на речке Чертане служилые мещеряки» (Л. 240 об. – 241).

***3 ревизия, 1761–1764 еллар.***

***«Сказки перешедшим из разных уездов в Уфимский уезд и живущих на всех дорогах... татарам... за 1762 года». (РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 3795):***

«Бакаево новокрещены из татар 2 души мужского пола». (Л. 547–547 об.).

Бакай авылы халкының милли составы турында язганда, төбәкне өйрәнүчеләр берничә урыс булганын күрсәтәләр. Мин шулвакытта уйлый идем: «Бакай саф татар авылы, ә каян урыслар монда килеп чыккан икән?» – дип. Петр I заманында ук (1682–1725 еллар) татарга авылларда тимерлек тотарга рөхсәт булмаган. Тимерлек тотарга урыс милләтеннән булган кешеләргә генә рөхсәт булган. Шуның өчен мин ул урыслар шул ук тимерчеләр булгандыр, дип уйлый идем. Менә бу 3 ревизия Бакай авылындагы «урысларны», ниһаять, күрсәтә дә инде. Бернинди урыс түгел болар –керәшеннәр!

***«Сказки Уфимского уезда Казанской дороги о тептярах и бобылях за 1762 год» (РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 3801).***

*Команда Старшины Ижбулды Ишкинина:*

«Сеитово, что на речке Чермасане татары» (Л. 85–87) (*Хәзер Югары Сәет – автор*).

«Бакаево, что на речке Чермасане татары» (Л. 87–88).

«Токмаклы, что на речке Кереке ясашные татары» (Л. 88–90).

«Кульсаитовой, что на проточном ключе татары» (Л. 95–98)?

«Григорьевой, что на речке Мишаде ясашные татары» (Л. 98–102).

«Тярбердиной, что на речке Сарыязы татары» (Л. 103) (Тәрбирде авылы икәү күренә. Район тарихын өйрәнүчеләре дә Тәрбирде авылында ике авыл булган, диләр. Берсендә – крепостной урыслар, икенчесендә ясаклылар яшәгән).

*Команда Абдрахмана Сейфина:*

«Емраново» (Л. 131–132); «Купаево» (л. 1320); «Байталлино» (Л. 168); «Сеитово» (Л. 155). Монда милли состав күрсәтелмәгән.

*Команда старшины Ибраша Уразбахтина:*

«Камышлы ясашные татары» (Л. 811–817).

«Такмаклы ясашные татары» (Л. 837–838).

«Акбашево ясашные татары» (Л. 843–844).

«Салтанаево ясашные татары» (Л. 844–847).

*Команда старшины Галкея Муслюмова:*

«Калтаево ясашные татары» (Л. 1171).

«Байталлино, что на речке Байталы ясашные татары» (Л. 1172).

«Тукмаклы Улы на речке Каряке ясашные татары» (Л. 1172).

«Кудешлиновой, на речке Кудешли ясашные татары» (Л. 1172–1175).

«Тукмаклино на речке Каряке ясашные татары» (Л. 1174–1175).

«Акбашево ясашные татары» (Л. 1175).

«Калтаево ясашные татары» (Л. 1178).

«Григорьево ясашные татары» (Л. 1178).

Менә 3 ревизиядә «команда старшины» дигән сүзләр күренә. Бу нәрсәне аңлата? 1734 елдан типтәрләрнең рәсми рәвештә социаль статусы билгеләнә. Типтәрләрне командаларга язалар. Команда белән старшиналар идарә итә. «Служилые татары» һәм «служилые мещеряки»ларга 30 дисәтинә җир бүленсә, типтәрләргә бары тик 15 дисәтинә. Типтәрләрнең социаль статусы менә шунда күренә дә инде. Безнең авылларда типтәрләр 3 ревизиядә күренә башлый. Типтәрләрнең милли составы, күпчелеге белән, ясаклы татарлардан чыккан. Без моны әлеге архив материалларыннан ачык күрәбез. 1790 елдан алып 1865 елга кадәр типтәрләр бераз үзләренең социаль статусын күтәрәләр: алар мишәрләр кебек «служилые» сословиесенә күчәләр.

Тагын да бер сословие бар – бобыльләр. Бобыльләр – җирсез көн күрүчеләр, һөнәрчеләр, батраклар.

Башкорт энциклопедиясенә күз салыйк.

Үгез авылына 1761 елны мишәрләр нигез сала. Типтәрләр XVIII гасыр ахырында килеп утыралар [Башкирская энциклопедия: 2005].

***4 ревизия, 1781–1782 еллар (РГИА. Ф. 558. Оп. 2. Д. 293. Л. 1–12):***

***«О числе разного звания по 4 ревизии людей и о заборе с них государственного дохода» (РГИА. Ф. 558. Оп. 2. Д. 293. Л. 1–102. Уфимский округи (Л. 1–12):***

«Мамяковой ясашные татары».

«Окладная ведомость учинена Уфимского наместничества в казенной палате... о состоящих в округе г. Бирск по нынешней 4 ревизии платящих податей душах...» (Л. 23–25 об).

«Рысмекеевой служилые татары и мурзы 12 душ мужского пола»; «Юмурановой служилые татары и мурзы 1 душ мужского пола».

Без монда Рәсмәкәй белән Йомран авылларында морзалар яшәгәнен күрәбез. Кемнәр соң ул «служилые татары и мурзы»? Бу төркем – татарның элеккеге феодаллары, аксөякләре. 1552 елны Казан ханлыгы тар-мар ителгәннән соң, бер өлеше бүгенге Башкортостан җиренә качып китсә, икенчеләре Московия дәүләтенә хезмәткә күчә. Алар хәрби хезмәттә, илче, тылмач, дәүләт чиновниклары булып хезмәт итә. Петр I вакытында татар морзаларына ультиматум куела: я христиан диненә күчеп дворян сословиесендә калырга, югыйсә барлык мөлкәтен югалтып, морза сословиесеннән мәхрүм ителеп, крестьян сословиесенә төшәргә. Яки, «чабаталы морзалар» булырга (служилые, ясачные татары). Шуның өчен дә бит күп кенә морзалар байлыгын югалтса да динен, телен, нәселен саклап калу өчен Уфа губернасына күчеп китәләр. Әйтергә кирәк, Тукмаклыда хәтсез генә морзалар яшәгән Хан-морза авылы булган. Аннан морзаларның кайберләре тирә-яктагы авылларга таралган: Суховлар, Булгаковлар... Рәсмәкәйгә Тукмаклыдан Булгаковлар күчкән дә инде...

***«Сверх того по оной округе оказалось прибылых после 3 ревизии душ…» (Л. 39 об., 40 об.):***

*Команда старшины Ишигула Ишметева:*

№ населенного пункта. Этносословные группы. ДМП (душ мужского пола – автор)

3. Илмурзиной тептяри и бобыли – 43.

11. Акбашевой тептяри и бобыли – 21.

15. Курмашевой тептяри и бобыли – 7.

16. Султанаевой тептяри и бобыли – 37.

*Команда старшины Адиля Игметева (Л. 15):*

№ населенного пункта. Этносословные группы. ДМП

1. Акметевой тептяри и бобыли – 14.

Токмаклиной тептяри и бобыли – 5.

Итого в команде А. Игметева – 19 душ.

*Команда старшины Мясягута Бикмаметева (Л. 15):*

№ населенного пункта. Этносословные группы. ДМП

6. Акметевой тептяри и бобыли – 2.

7. Тансеитовой тептяри и бобыли – 52.

8. Курмашевой тептяри и бобыли – 13.

9. Кудешли тептяри и бобыли – 15.

11. Байкеево тептяри и бобыли – 21.

(осн. 1762–1782 гг. тептярами. [Башкирская энциклопедия: 2005]).

12. Казармы тептяри и бобыли – 17.

(осн. I пол XVIII в. мишарями. С 1761 г. здесь поселились тептяре. [Башкирская энциклопедия: 2005]).

13. Токмаклы тептяри и бобыли – 33.

17. Бакеевой тептяри и бобыли – 1.

18. Сеитовой, Черемсан тож тептяри и бобыли – 48.

(Верхнесаитово. В 30–40 гг. XVIII в. здесь поселились ясачные татары из Пензенской и Тамбовской провинции, перешедшие в последствии в сословие тептярей. С образованием в сер. XVIII в. выселка Нижнесаитово получила современное название. В конце XVIII в. учтены также мишари. [Башкирская энциклопедия: 2005])

19. Султанаевой тептяри и бобыли.

22. Курмашевой тептяри и бобыли – 1.

*Команда старшины Абдулмяниана Муслюмова (Л. 15 об.):*

№ Населенного пункта. Этносословные группы. ДМП

1. Калтаевой тептяри и бобыли – 8.

3. Курмашевой тептяри и бобыли – 33.

4. Акметевой тептяри и бобыли – 3.

8. Байталиной тептяри и бобыли – 2.

*Команда старшины Адиля Игметева:*

№ населенного пункта. Этносословные группы. ДМП

1. Мамяковой тептяри и бобыли – 12.

*Команда старшины Абдулзямила Саитова:*

№ населенного пункта. Этносословные группы. ДМП

1. Солтанаевой тептяри и бобыли – 2.

***«Окладная ведомость … состоящих в округе г. Бирска по нынешней 4 ревизии платящих податей душах…» тептярей и бобылей.***

*Команда старшины Мусагита Мусекеева:*

17. Ислановой тептяри и бобыли – 6.

23. Иликовой тептяри и бобыли – 167.

(осн. во II половине XVIII в. тептярами [Башкирская энциклопедия: 2005]).

24. Талбазах тептяри и бобыли – 113 (осн.1704 г.).

*Команда Адиля Игимбетева (Л. 35 об.):*

№ населенного пункта. Этносословные группы. ДМП

26. Тартышевой тептяри и бобыли – 10.

28. Гумеровой тептяри и бобыли – 20 (Старогумерово, согласно договора в 1750 году здесь поселились мишяри, потом тептяре [Башкирская энциклопедия: 2005]).

1980-нче елларда Иске Гомәр мәктәбендә материалларга бик бай төбәкне өйрәнү музее бар иде. Ул вакытта мәктәпнең директоры, РСФСР-ның атказанган укытучысы Рәшит Гатаевич Галин иде. Рәшит Гатаевич (аны укытучылар үзара сөйләшкәндә «Батя» дип атыйлар иде) мәктәп һәм музей өчен бик күп көч салды. Мин ул музейны бик яхшы хәтерлим, миңа да 1982–83 елларда Рәшит Гатаевич кулы астында эшләү бәхете тиде. Андагы материалларга караганда, Иске Гомәр тарихы XVI гасырларга карый иде. Әле дә хәтеремдә, «без Кара диңгез буеннан килгән халык», дигәннәре... Бүген музей да юк, мәктәп тә юк инде...

*Команда старшины Мухаметамина Аитова:*

№ населенного пункта. Этносословные группы. ДМП

10. Бакаевой тептяри и бобыли – 2.

Менә хәзер Кушнарен районы газетасындагы таблицаны карасак та була. Мин аны Рәсмәкәй сельсоветындагы авыллар буенча гына алам. Сез үзегезнең авылларыгызны – үзегез чагыштырыгыз. 1795 елгы җанисәп буенча (5 ревизия):

«с. Байталлы – 8 башкорт, 192 мишәр, 8 типтәр»;

Купай авылында башкортлар беренче мәртәбә, Байталлыга караганда 100 ел үткәч барлыкка килә, 1895 елда күренә – «450 башкорт, мишәр, типтәр».

Иске Йомран авылында башкортлар беренче мәртәбә 1870 елда күренә – «174 башкорт».

Кем соң ул «башкорт»? Каян килгәннәр? Ни өчен башкортлар Байталлыда 1795 елда гына, Йомранда – 1870 елда, Купайда Байталлыдан соң, йөз елдан соң гына, 1895 елда күренә? Ә нигә 1, 2, 3, 4 ревизияләрдә башкортлар юк?

Бу мәсьәләдә бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк: «башкирец» сүзен милләт белән бутарга ярамый. 1917 елгы революциягә кадәр «башкорт, башкирец» сүзен сословие итеп тә карарга кирәк.

1744 елдан «башкирцы» Русиянең Ырымбур чиген кыргыз-кайсаклардан (казакъ) һәм калмыклардан саклыйлар. 1748 елда Ырымбур казак гаскәре төзелә. Бу гаскәргә казаклардан башка халыклар да керә: «башкирцы», «служилые мещеряки» һ.б. 1798 елдан башлап 1855 елга кадәр

бу гаскәр – «башкирско-мещерякское войско» дип атала. «Башкирец» сословиесендә булган ир кешегә 40 дисәтинә җир бирелә. Казакларга – 30, мишәрләргә – 30, ясаклы татарларга – 20, типтәрләргә 15 дисәтинә жир бирелгән. Шуның өчен, мишәр / татар / типтәр дә «башкирец» сословиесенә күчәргә тырышкан. Бу татарларга гына хас күренеш түгел, ә чирмеш (мари), вотяк (удмурт) һ.б. халыкларга да хас. Бер сословиедән икенче сословиегә күчеш – кешенең үз статусын күтәрү өчен кирәк булган, чөнки кешенең җире арткан, бүгенге сүз белән әйтсәк, льготалары арткан. Бу күчеш турында бик күп архивларда материаллар бар.

Байталлыда 1795 елда (5 ревизия) мишәрләр һәм ясаклы татарлардан 8 ир-ат үзенең статусын күтәргән, башкорт сословиесен алган. Исәпкә алырга кирәк: бары тик 8 ир-ат! Без аларны Байталлының «хәрби» кешеләре дип әйтә алабыз. Әлбәттә, алар «хәлле» булган.

Йомранда 1870 елда 174 татар-мишәр-морза «башкортка» әйләнә. Бу авыл халкы да яхшырак яшәгәндер, дигән уй-фикер килә. 1930-нчы елларда, колхозлашу чорында, Йомран авылыннан бик күп кешене, «кулак» ясап, сөргенгә сөргәннәр бит.

Купайда 1895 елда 450 кешенең күпмеседер «башкорт сословиесенә» күчә. Әмма монда мишәрләр һәм типтәрләр кала әле. Кыскасы, Байталлы, Рәсмәкәй, Купай, Йомран, Урал авылларына нигез салган (Урал авылы 1928–1930 елларда Рәсмәкәйдән күчкән халык) һәм бүген дә шунда яшәгән татар халкының уллары һәм кызлары – уңган халык, булган халык...

Безнең Кушнарен районында күпчелек авыллар – саф татар авыллары. Районда урыс авыллары да бар: Ямская, Матвеево (осн. 1791), Кувыково (осн. 1754), Медведерово (осн. 1776), Ахлыстино (осн. 1788), Бардовка (осн. 1742, прапорщик Бардовский А.И.), Баскаково (осн. 1715, по другим данным – 1753), Первушино (осн. 1786), Петропавлово, Киренево, Воецкое, Гуровка (осн. 1865 г. удельными крестьянами Рязанской губернии [Башкирская энциклопедия: 2005]. Хәзер инде бу урыс авылларында татарлар да яши.

Бер удмурт авылы – Канлы (осн. 1769 ясашными удмуртами [Башкирская энциклопедия: 2005]).

Әлеге вакытта башкорт милләтеннән булган кешеләр дә яши районда, алар инде районга я киленнәр, яисә кияүләр булып килгәннәр! Бүгенге көндә кушнареннар барлык милләтне дә тигез күреп, тату-дус мөгаләмәдә булып, көн күрә.

Аңлау кирәк:

5-нче ревизиядә күпчелек авылларның халкы башлыча «башкирец» дип аталуга күченүенең бөтен сере шунда: бу ревизия алдыннан моңарчы «башкирско-мещерякское» булып аталган иррегуляр гаскәр «башкирское

войско»га әйләнә һәм гаскәриләрнең иң зур күпчелеге гаскәри «башкир» сословиесенә күчә. Билгеле – биредә, империянең Ырымбур линиясен саклаучы, хәзергечә әйтсәк – «хәрби округта», иң мөһим катлам – шушы гаскәриләр була инде: аларга шуңа күрә иң зур привилегияләр бирелә…

## Әдәбият


1. Башкирская энциклопедия. Уфа. 2005 г.
2. Генеральная карта Уфимского наместничества. 1791 г. Атлас Тартарии. Казань–Москва, 2006.
3. Притяжение земли. Уфа. 2000 г. С. 8–9.
4. Татары Уфимского уезда. (http://админ.татаровед.рф/uploads/libraries/original/7b7cfc37c2320315b925c3c62407dcd4d01f4c87.pdf?1608761159).

*Ф.Ә. Хәбибуллин*

# ХАЛЫККА ХЕЗМӘТТӘ ЙӨЗМӘКТӘ...

*(Уфадагы 3-нче җәмигъ мәчет, «Хәсәния» мәдрәсәсе һәм аны оештыручы Мөхәммәтсабир хәзрәт Хәсәни хакында)*

Мәдрәсә – мөселманнарда урта һәм югары класслары булган дини уку йорты. Идел буе Болгарстанында беренче мәдрәсәләр X гасырларда барлыкка килә. Уку, сабак бирү, әңгәмә, монзара (диспут), Коръән һәм башка дини китапларны өйрәнү һәм ятлау рәвешендә алып барыла. Мөселман хокук фәне (фикъһ), Ислам дине фәлсәфәсе нигезләре, мантыйк (логика), хәдисләр, каллиграфия, гарәп, фарсы телләре һәм башка фәннәр укытыла.

XVIII–XIX гасырларда күп мәчетләр янында мәктәпләр һәм мәдрәсәләр ачыла. Аларда гарәп алфавиты нигезендә татар телендә укырга һәм язарга өйрәтәләр. Шуңа күрә татарлар арасында укый-яза белүче кешеләр саны башка халыкларга караганда күбрәк була.

XIX гасырның азагында яңа ысул белән укыта торган җәдитчә мәдрәсәләр барлыкка килә. Аерым җәдит мәдрәсәләрендә дин белән бергә дөньяви фәннәр: математика, физика, астрономия, гигиена (медицина элементлары белән), этика һәм психология, география, тарих һәм башка фәннәр, кайбер Шәрык һәм Көнбатыш Европа телләре укытыла. Укыту, кагыйдә буларак, 4 баскычка бүленә: башлангыч (ибтидаия), урта (рөшди), уртадан югары (игдадия), югары (галия). Мәдрәсәләр җәмәгать хисабына яки байлар иганәсенә яши. Зур мәдрәсәләр өчен («Буби», «Галия», «Хәсәния», «Гобәйдия», «Госмания», «Касыймия», «Мәрҗания», «Мөхәммәдия», «Хөсәения») уку-яшәү биналары төзелә. Мәдрәсәләрдә бирелгән белем гимназиядәге белем дәрәҗәсенә тиңләшә. Кайберләрендә ул югарырак та була. Күп кенә билгеле әдипләребез һәм галимнәребез шушы мәдрәсәләрдә белем алган.

***Мөхәммәтсабир Хәсәни***

Түбәндә сүзебез Уфадагы 3-нче җәмигъ мәчет, мәгърифәт учагы «Хәсәния» мәдрәсәсе һәм аны оештыручы дин һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог Мөхәммәтсабир хәзрәт Хәсәни хакында.

Ул 1865-нче елның 15 февралендә Самара губернасы Богырыслан өязе Надир-Бакый авылында дөньяга килгән. Мөхәммәтсабир Хәсәнинең ата-бабалары кем булуы турында Ризаэддин Фәхреддин болай дип язган иде: «*...Хәсән бине Мортаза Казан әтрафында Байрәкәгә күчеп килгән Мортазаның угылы булып, Бәйрәкәдә дөньяга килгән. Андан Богырыслан мозафәте (өяз, төбәк) Надир-Бакый авылына килеп, балалар*

*укытып торган. 1223/1808-нче елларда вафат иткән, диләр. Хатыны Фатыйма бинте Мирсалим Бөгелмә мозафәте Ками-Исмаил авылындан төшкән. Угыллары: Хәбибулла, Фазлулла, Рәхмәтулла, Мөхәммәдҗандыр. Мөхәммәдҗан бине Хәсән Урманай авылында Габделгазиз бине Хәбибулла хозурында гыйлем тәхсыйль итеп (белем алып), Бакый авылында атасының мәктәбен ихйа кылды (терегезде, яңадан аякка бастырды) вә шәкерд укытты. Мәншүрле (таныклыгы булган) имамлар тарафыңдан җәберләр күрү сәбәбле, укытудан тукталып, сәүдә кәсебенә кереште вә 1312/1895 тарихы 25 рәҗәбтә (шәркый 11 гыйнвар) вафат булды. Бу урындагы Газизҗандан башка Мөхәммәдзакир, Мөхәммәдсабир исемендә угыллары бар. Монларның әүвәлгесе Бакый авылында вә соңгысы Уфа шәһәрендә өченче мәсҗед хозурында имамлар*».

Мөхәммәтсабир Хәсәни үсмер вакытында Троицкийга килеп, 4-нче мәчет каршындагы Җәмалетдин бине Сөбханкол әл-Казанлының мәдрәсәсенә укырга керә. Остазының вафатыннан соң ул Зәйнулла бине Хәбибулла Рәсүли әл-Нәкышбәнди (1833–1917) хәзрәтнең «Рәсүлия» мәдрәсәсенә күчә һәм бер үк вакытта урыс башлангыч мәктәбен дә тәмамлый. Шунда ук берничә ел мөдәррислек иткән. Ул Зәйнулла ишан Рәсүлинең мөриде була.

***Уфадагы 3-нче җәмигъ мәчет***

1889-нчы елның 29 гыйнварында Уфаның Нижегородка бистәсе мөселманнарыннан унбиш кеше Диния нәзарәтенә түбәндәге эчтәлекле мөрәҗәгать юллый:

«*В Оренбургское магометанское Духовное собрание.*

*Нижеподписавшиеся горожане города Уфы, Нижегородской слободы Прошение*

*По случаю отдаленности 1-й каменной и 2-й деревянной мечетей города Уфы и значительного увеличения мусульманского населения, с проведением железной дороги, крайне необходимо построить в Уфе третьей соборной мечети. Так как существующие мечети не вмещают всех молящихся.*

*В виду сего имеем честь покорнейше просить Магометанское духовное собрание исходатайствовать у города пустопорожнее дворовое место, находящееся в 4-й города Уфа, на углу по Большой Кузнецкой и спиной улиц, против кузницы, для постройки на нем 3-й каменной соборной мечети. При чем присовокупился сем, что означенную мечеть мы желаем построить на свои собственные средства, и о последующем распоряжении нам объявить.*

*Января 29 дня 1899 года*».

Мөселманнары тарафыннан сайлап куелган Гыйльман Габделкәримов һәм Исхак Бикбулатов губерна идарәсенә шәһәрдә 3-нче җәмигъ мә-

чете төзү турында рөхсәт сорап мөрәҗәгать итәләр. Мөрәҗәгатькә мәчетне төзү һәм анда дини хезмәт үтәячәк имамга яшәү шартлары тәэмин итү өчен чыгымнарны үз өсләренә алырга риза 215 кешенең култамгасы салынган була. Уфа губерна идарәсе 1900-нчы елның 23 ноябрендә Нижегородка бистәсендә җир бирү турында карар чыгара: «*...мерою по Воздвиженской улице 24 сажени, по Гурьевской и Кузнецкой улице 17 и 5 сажен, а всего в площади 420 сажен*».

Диния нәзарәте чакыруы буенча Мөхәммәтсабир Хәсәни Уфа шәһәренә күчеп килә. Нәзарәттә имтихан тапшырып, имам-хатыйп һәм мөдәррис булып тәгаенләнә. Түбәндәге документлар шул хакта сөйли:

«*Оренбургское магометанское Духовное собрание.*

*15 апреля 1903 года*

*В Троицкое Уездное полицейское управление*

*Магометанское Духовное Собрание просит Полицейское управление объявить крестьянину Самарской губернии, Бугурусланского уезда Сук-Карамалинской волости д. Надыровой Мухамадсабиру Мухаметзянову Хасянову, проживающему в медресе при 5-й соборной мечети города Троицка, чтобы он явился в присутствие Духовного собрания для испытания, предложив ему вместе с сим или лично представить удостоверения о поведении своем и прохождении наук от того мударриса или мугаллима, у которого он обучался и о последующем Собрание уведомить*».

«*...Слушали: Предложение Уфимскаго Губернскаго Правления от 22 марта 1903 года за № 1044, коим, с препровождением приговора прихожан третьей соборной мечети города Уфы об избрании в хатыпы к их мечети крестьянина деревни Надыровой, Бугурусланского уезда, Мухамедсабир Хасянов, предлагает Духовному Собранию подвергнуть испытанию в знании правил магометанской религии названного Хасянова и о результатах испытания донести сему правлению, вместе со своим заключением о том, встречается действительная надобность в определении хатыпа к означенной мечети и не имеется со стороны Духовного Собрания препятствий к назначению на эту должность. Мухамедсабир Хасянов 21 апреля 1903 года в Собрание явился и по испытанию оказался быть способным имамом-хатыпом и мударрисом.*

*Справка: Уфимская третья соборная мечеть разрешена постройка 23 ноября 1900 года.*

*Приказали: Оказавшимся по испытанию Мухамедсабира Хасянова, с возвращением присланного приговора и с представлением 60 коп., представленных Хасяновым на предмет написания ему на духовное звание указа, донести Уфимскому Губернскому Правлению, присовокупив, что в определении хатыпа в Уфимскую третью соборную мечеть встречается действитель-*

*ная необходимость и к назанчению на эту должность имам-хатыпом и мударрисом со стороны Духовного Собрания препятствия не имеется».*

*«МВД Уфимскаго Губернскаго Правления.*

*Оренбургскому магометанскому Духовному собранию.*

*Первое отделение Губернскаго Правления, с утверждения Г. Губернатора, дает знать Духовному собранию, к сведению, что к 3-й Уфимской соборной мечети, в городе Уфе утвержден хатыпом крест. д. Байкиевой Бугурусланского у. Самарской губ. Мухамедсабир Мухаметзянов Хасянов и муадзином Стерлитамакский ... Габдулла Нугуманов Габдулкаримов, в чем и выдан указ на духовное звание, от сентября 2 дня 1903 года, 1-му за № 5290, 2-му за № 3291».*

1903-нче елның көзендә, Нижегородка бистәсенең Воздвиженская урамында (әле Лесопильная урамы, 34, анда спорт мәктәбе һәм китапханә урнашкан) татар җәмәгатьчелегеннән җыелган акчага бер манаралы ике катлы таш мәчет салына.

Рәмзис Кадыйров һәм Раушания Акчуринаның 2015-нче елда Бөгелмәдә дөнья күргән «Игелекле бай» китабында бәян ителүенчә, хәйриячелек, милли мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш керткән атаклы татар байлары Хөсәеновлар, Апанаевлар, Акчуриннар, Рәмиевләр, Юнысовлар белән бергә Хәкимовларны да телгә алырга кирәк. Шәҗәрәсе данлыклы Түнтәр авылына (Татарстанның Балтач районы) нигез салучылар – Янгол бабаның алты баласының берсе Үкәчегә барып тоташкан Габделхәким Габделхалик улы нәселе вәкилләре татарның хәйриячелек тарихында тирән эз калдырган.

Даими рәвештә Уфада яшәп, сәүдә эше белән шөгыльләнсә дә, Габделлатыйф Хәкимов 1893-нче елга кадәр Түнтәр авылы крестьяны булып саналган, 1893-1904-нче елларда – икенче гильдияле Малмыж сәүдәгәре, 1904-нче елдан соң гына ул гаиләсе белән тулысынча Уфага күченгән һәм беренче гильдияле Уфа сәүдәгәренә әверелгән. Габделлатыйф Хәкимов Түнтәрдә, Малмыжда, Бөгелмәдә, Уфада, Ырынбурда кибетләр тоткан, Петербург белән дә элемтәдә булган.

Габделлатыйф Хәкимов, аның гаиләсе хәйриячелектә актив катнашуы белән данлыклы. Ул 1906-07-нче елларда Уфа шәһәрендә «Әл галәми әл ислами» («Ислам дөньясы») дигән гәзитне чыгаруны финанслый. Уфаның 3-нче мәчетен төзү эшенә үзеннән акчалата зур ярдәм күрсәтә. Уфа имамы Мөхәммәтсабир Хәсәновның «Вакыт» гәзитендәге мәкаләсендә (1906 ел, 7 октябрь) шул чорның атаклы сәүдәгәрләре һәм гади кешеләрнең мәчет төзелешенә матди ярдәм итүләре сурәтләнә. Мәкаләдә китерелгән саннардан күренүенчә, бу мәчет төзелешенә иң зур иганә керткән кеше сәүдәгәр Габделлатыйф Хәкимов булган: «*Уфа шәһәрендә булган өченче мәчетнең планы вилаят мәхкамәсеннән 1901 ел 30 апрель 532 но-*

*мерда тасдыйк ителмеш вә 1903 ел тәмам булып, 24 ноябрь җомга намазы укылып, ачылмыштыр.*

*...Моның өстенә Уфаның сәүдәгәре Габделлатыйф Хәкимов 600 сум мәчет түбәсе ябар өчен һәм моңа кирәкле агачларны биргән. ...Уфаның үзеннән 1590 сум җыелган, шуның эченнән Габделлатыйф Хәкимов биргән 1000 сум. ...Хәкимовтан мич өчен алынган 100 сум*».

Гәзитнең шул ук санында Уфа шәһәрендә Хәкимов тарафыннан ният ителгән 4-нче мәчеткә нигез ташы салыну хакында язылган: «*Ошбу сентябрь 22-нче көн иртә сәгать 9да Хәкимов тарафыннан бинасы касд ителгән мәчет җәмигъ нигезе корылырга башланып, әүвәле ташны салдылар. Мөфти вә казыйлар, ахун вә мөдәррисләр вә башка мөгътәбәр затлар хозур булдылар. Бу мәчет өчен рөхсәт алмак күп мәшәкатьле булды. Имди гыйбадәт илә мәгъмүр булып, янында мәктәп вә мәдрәсәләр һәм булсын иде... Нигез салмак мөнәсәбәте илә Коръән Шәриф укылды*».

***Мәгърифәт үзәге***

1904-нче елда Воздвиженская һәм Большая Кузнецкая урамнары кисешкән урында (әле Уфаның Нуриманов урамы, 16) бер катлы мәдрәсә бинасы төзелә. Мөхәммәтсабир Хәсәни оештыручысы һәм башлап йөрүчесе булганлыктан, аңа «Хәсәния» атамасы бирелә. Мәдрәсә халыктан алынган керем исәбенә яши. Аерым химая итүчеләре – сәүдәгәрләр Фазлулла һәм Әхиярулла. Патша хөкүмәте татар мәдрәсәсенә бер тиен белән дә ярдәм күрсәтми.

Шәркыять вә исламият галиме Равил Үтәбәй-Кәрими «Казан утлары» журналында басылган (1985 ел, 5нче сан) мәкаләсендә язуынча, «*Мөхәммәтсабир әл-Хәсәни, бигрәк тә 1905 ел революциясеннән соң, үз мәдрәсәсендә укыту-оештыру тәртибе ягыннан берникадәр үзгәрешләр керткән: иҗекләп уку ысулы аваз белән алмаштырыла, уку башы һәм азагы билгеләнә, дәресләп уку, тәнәфесләр ясау, имтиханнар үткәрү гамәлгә ашырыла. Мәдрәсәнең аскы катында ике сыйныфтан торган 4 еллык башлангыч мәктәп була. Өске катта – өч сыйныфлы 3 еллык урта мәктәп. Шунда ук шәкертләр торагы һәм Мөхәммәтсабир хәзрәт үзе сабак бирә торган “дәресханә” бүлмәсе. Рөшди сыйныфларда әл-Хәсәни үзе укыта. Гарәп графикасында нәшер ителгән китаплардан тупланган бай китапханәсе була*».

1905–07-нче еллар революциясе вакытында «Хәсәния» мәдрәсәсе халык тарафыннан киң танылу ала. Белем бирү күләме буенча да «Хәсәния»дә берникадәр үзгәрешләр ясала, схоластика бераз йомшартыла, татар теле укытыла, дөньяви фәннәр (хисап, география, тарих, анатомия һәм башкалар) өйрәтелә башлый.

Столыпин реакциясе елларында (1906–10-нчы еллар) күп кенә мәктәпләр һәм мәдрәсәләр эше өстеннән күзәтү оештырыла, укытучыларны мәдрәсә

бинасыннан чыгармыйча тентүләр үткәрелә. Нәтиҗәдә, бик күп хатлар, китаплар һәм дәреслекләр җыеп алына, мәдрәсәләр ябыла, яңа җәдит ысулы белән укытучыларны җәберләү башлана. Милли мәктәп-мәдрәсәләрне чикләү, кысулар чорында да «Хәсәния» мөгаллимнәре туган телне, дингә бәйләнеше булмаган дөньяви фәннәр укытуны дәвам итәләр.

1909-нчы елда «Вакыт» болай дип яза: «*Уфада 15 февральдә якшәмбе көн мәдрәсәи "Галия"не көндез сәгать 10нан 2гәчә атлы казак илә әйләндереп бик күп полицейскийлар кереп тентегәннәр. Эчтән һичбер кем чыгарылмаган, фатирда торган шәкертләрнең һәм тыштан мәдрәсәгә килеп керүчеләрнең дә фатирларына барып тәфтиш иткәннәр. Мулла Сабир Хәсәнов, мулла хаҗи Әхмәд Вәлиев, гимназия шәкертләреннән Габделбари мәхдүм Госманов, присяжный поверенный Әхтәмовларда да тәфтиш булган. Нургали Хәсәнов квартирын 4 сәгать актарып 50ләп газета вә шулкадәр китапларны конфисковать иткәннәр. Ахыры ни илә бетәчәге мәгълүм түгел*».

### *Русия Дәүләт думасы депутаты*

Уфаның 3-нче мәчет имамы һәм «Хәсәния» мәдрәсәсе мөдәррисе Мөхәммәтсабир Хәсәни 1907-нче елның 6 февралендә Уфа губернасы җыелышының сайлаучылар гомум составыннан икенче чакырылыш Русия Дәүләт думасына депутат булып сайлана. Дәүләт думасының (1907-нче елның 20 феврале–3 июле) мөселман фракциясендә 36 мөселман депутат катнаша, алар арасында 15 татар булган. Шуларның алтысы март аенда мөстәкыйль мөселман хезмәт таифәсе оештыра. Дума составында Сафиулла Максүтов (Казан губернасыннан); Уфадан Мөхәммәтсабир Хәсәни, ахун һәм Стәрлебаш мәдрәсәсе мөдәррисе Мөхәммәтшакир Тукаев (Уфа губернасыннан); ахун һәм Каргалыда 1-нче мәчет имамы Хәйрулла Госманов (Ырынбур губернасыннан) булалар. Ахун Хәбибрахман Мәсәгутов (Нократ губернасы), мулла Һади Атласи (Самара губернасы) һәм Кызыл Утрау авылыннан килгән мулла Габдулла Нәҗметдинов (Сембер губернасы, хәзерге Түбән Новгород өлкәсе) мөселман хезмәт таифәсенә керәләр. Мөхәммәтсабир Хәсәни «Дин вә мәгыйшәт» журналына мөселман депутатларының һәм фракциянең эшчәнлеге турында даими мәкаләләр язып тора.

### *Журналист һәм мөхәррир*

Татар телендә гәзит чыгару өчен мөмкинлекләр 1905-нче елгы инкыйлабтан соң ачыла. Санкт-Петербург ахуны Гатаулла Баязитов татар телендә беренче гәзит чыгаруга ирешә. «Нур» гәзите 1905-нче елның 2 сентябрендә (иске стиль) чыга башлый. Гәзитнең абруен һәм популярлыгын еш кына очракларда аңа язышкан мәшһүр шәхесләр, аларның язмалары билгели. Аның битләрендә, бигрәк тә башлангыч чорында, Риза Фәхред-

дин, Һади Максуди, Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый, Камил Мотыйгый һәм башкаларның исемнәрен очратырга мөмкин. Биредә күренекле дин эшлеклеләре – ахун Әл-Мәсгуди, казыйлар Гыйниятулла Капкаев, Кәшшафетдин Тәрҗемани, Мотыйгулла хәзрәт, Мөхәммәдсабир әл-Хәсәни, Насретдин Әл-Хуҗами язышa.

1906-нчы елның маенда Уфада «Әл-галәме әл-Ислами» («Ислам дөньясы») дини-фәлсәфи һәм әдәби-иҗтимагый гәзите чыга башлый. 1907-нче елның гыйнварына кадәр сигез ай дәвам итә. Рәсми мөхәррире һәм нәшире Шәехгаттар Абызгилдин, асылда гәзитне алып баручылар Зыя Кәмали белән Мөхәммәтсабир Хәсәниләр була. Соңрак Баһаветдин Максуди белән Галләм Мостафин кулына күчә. Һәр саны дүрт битле булып чыга. Барысы 42 саны дөнья күрә.

Дин эшләре буенча төп оешма – мөселманнарның Диния нәзарәте төзелә, әлеге оешманың рәсми органы булып «Мәгълүмат» («Мәгълумате Мәхкәмәи шәргыяи Оренбургыя») журналы тора. Ул 1908-нче елның 21 гыйнварында Уфада чыга башлый. Журнал, мөфти күрсәтмәсе буенча, Мәхкәмәи шәргыягә караган 5500 мәхәллә өчен мәҗбүри була. Бәясе дә мәхәллә өчен күтәрә алмаслык түгел, елына өч сум. «Мәгълүмат» журналының беренче җаваплы мөхәррире Мөхәммәтсабир әл-Хәсәни була. Ул мөхәррирлек иткән чорда журналда татар мәгарифенә, тарихына, хатын-кыз хокукына караган, әхлак һәм тәрбия мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләр басылуы да шуның белән аңлатыла. Ләкин Мөхәммәтсабир әл-Хәсәнигә «Мәгълүмат» мөхәррире булып озак эшләргә туры килми. Ул 1908-нче елның ноябрендә Русия эчке эшләр министры Петр Столыпин «тәкъдиме» һәм Диния нәзарәте карары белән эшеннән алына. Аның урынына Мәхкәмәнең үз әгъзалары: казыйлар Гыйниятулла Капкаев, Нурмөхәммәт Мамлиев, Хәсәнгата Мөхәммәтов билгеләнә.

### *«Тройскидән шәһадәт бар кулымда... »*

Мөхәммәтсабир әл-Хәсәни билгеле шәхес булган. Ниндидер уртакул кеше булса, бөек татар шагыйре Габдулла Тукай аңа игътибар да итмәс иде. Алдынгы карашлы яшьләргә каршы чыгып, байларны, сәүдәгәрләрне яклап, гәзит-журналларга (бигрәк тә «Бәянелхак»та) усал-усал мәкаләләр язганы өчен, Габдулла Тукай бу хәзрәткә күп тапкырлар үткен сатирик укларын җибәрә. «Алай-болай» дигән фельетонында аңардан, Казан сәүдәгәре Әхмәтҗан Сәйдәшевнең «остабикәсе, кече хатыны» дип көлә; «Керешү хотбәсе» дигән памфлетында аны «...Такырҗан Хәсәни» дип атый.

«Ялт-йолт»ның 1910-нчы елның 5-нче санында (15 май) «Күрдем» имзасы белән «Җабир хәзрәт мактана» дигән түбәндәге эчтәлекле шигырь басыла:

«Утыз биштә мәхәллә башы булдым,
Кырык яшьтә Дума әгъзасы булдым;
Бу хәзрәттә дини хис бар, диделәр,
Думада динне саклар бу, диделәр.
Бу көндә мин ишанлыкның юлында,–
Тройскидән шәһадәт бар кулымда.
Бу көн мин–«Дин-мәгыйшәт»кә язучы
Вә яшьләр юлына чокыр казучы.
Вәгазь әйтәм халыкка җомгаларда,
Котыртам: каршы торсыннар аларга.
Симердем мин–сигез пот булдым инде:
Ашаганым мөселман ашы сеңде».

Галимнәр «Җабир хәзрәт мактана...» сатирасы үлчәме, теле-стиле белән генә түгел, темасы, эчтәлеге белән дә Габдулла Тукайныкы булуы ихтимал, дигән фикердә. «Җабир хәзрәт»–ул имам Сабир әл-Хәсәни.

Совет власте урнашкан чорда, 1920–30-нчы елларда, атестик-дәһрилек пропагандасы киң колач алганда, кайбер татар әдипләре партия һәм хөкүмәт куйган идеологик таләпләрне үтәп, яңа әсәрләрен иҗат итәләр. Кайчандыр үзе рухани булган яки мөселманнар тормышы белән якыннан таныш кешеләр китапларында үзенчәлекле мәгълүматлар китерәләр. Зариф Мозаффариның 1931 елда Казанда басылган «Ишаннар-дәрвишләр» китабы–шундыйларның берсе. Анда автор Мөхәммәтсабир Хәсәнигә түбәндәгечә характеристика бирә:

«*Сабирҗан ишан Хәсәни Троицкий Зәйнулла ишан Рәсүлинең шәкертләреннән булып, ишанлык кәгазен Зәйнулла ишаннан алды. Әмма мөрид тәрбияләмәде. Шулай да ул ишан иде. Сабирҗан ишан Уфа шәһәрендә 3-нче мәхәлләдә имам, соңгы елларда Үзәк диния нәзарәтендә казый булып торды.*

*Бу ишан бик тә интригачы булып, патша хөкүмәтенә хөфиә (яшерен агент) хезмәтен үтәде. Бер генә факт китерәм: 1909 елда Уфа шәһәрендә берничә тапкыр җыелыш булып, Сабирҗан мулла Хәсәни, татар мәктәпләренә театр, танса һәм башка шундый урыннардан килгән килерне шәригать дөресләми, дип фәтвә биргәч, каршы төшкән берничә укытучыларны сәяси яктан гаепләп сыскнойга күрсәтте. Аның бер бу вакыйгадан гына түгел, сыскнойга гелән хәбәр биреп торганын без шул вакыйгада тәмам инандык. Сабирҗан ишан патша чорында матбугатка язгалап буташып утырган муллалардан берседер. Аның бу донос чире шәкертләренә дә йоккан иде.*

*Сабирҗан мулла турында матбугатта аның начар якларын күрсәтеп язган байтак әсәрләрне очратабыз. Аның турында тәнкыйтьләр күп*

*булып, Габдулла Тукайның “Яшен ташлар”ында аның турында һөҗүме бер хитба дә кертелгән иде.*

*Сабирҗан ишан бик астыртын муллаларның берсе булып, ул бик күп әдипләр, шагыйрьләр, укытучыларның теңкәләренә тигән чаклары әз булмады.*

*Көлке журналларында аның исем-фамилиясе белән язарга куркалар иде. Аның турында бер-бер тәнкыйть була калса, ул йә судка бирә, яки сыскнойга тарттыра иде.*

*Казанда печән базары үзенең каралыгы, көфер почмагы булуы белән ничек әшәке булса, Сабирҗан ишан мәхәлләсе дә бик кара булып, байтак яшь-җилкенчәкләрне куркуга төшерәдер иде.*

*Рамазан уразасы чагында урамда тәмәке тарту... фәлән бик тә куркыныч иде. Андый берәр кешене очратсалар: «Әйдә, Сабирҗан хәзрәткә...»–дип тотып алалар да, канга манчып кыйныйлар иде. Бер вакыт рамазан аенда шагыйрь Мәҗит Гафурины да урамда тәмәке тарткан өчен кыйнарга азапланганнарын һәм аның извозчикка утырып качып котылганын сөйлиләр иде.*

*Сабирҗан ишанның астыртын, усал булуы да Зәйнулла ишаннан ким түгел иде. Интригалы булуы турында Сабирҗан ишанны Галимҗан ишан Баруди кебек дип, Галимҗан Барудига тиңләп сөйлиләр иде*».

Хәзер шушы ук шәхескә икенче караш белән танышып үтик. 2012-нче елда «Китап» нәшриятында басылган «Башкортстан–әүлиялар иле» китабында бәян ителүенчә, Зәйнулла ишан Рәсүлинең зур бәһагә лаек варисларының берсе–Сабирҗан Хәсәни. Дини фәннәрне югары дәрәҗәдә укыта алуы белән ул бөтен Русия мөселманнарының олы ихтирамын яулый. 1910-нчы елда Исмәгыйль бәй Гаспралыга Ислам диненә күчәргә теләк белдергән ниндидер бер Австрия баронессасы сорау белән мөрәҗәгать иткән. Баронесса мөселман хатын-кызларына йөзен һәм сынын каплау өчен тәгаенләнгән бөркәнчек ябынып йөрү мотлактыр, дип уйлап, үзенең икеләнүе турында яза. Исмәгыйль бәй Гаспралы шушы сорауга җавап язуны Сабирҗан Хәсәнигә йөкләтә. Ул гарәпчә һәм төрекчә яхшы белгән. Шәкерт вакытында ук казакълар арасында зур абруй казанган. Дөнья әдәбияты һәм Европа педагогикасы нигезләре белән җитди кызыксынган. Мөхәммәтсабир Хәсәни, хатын-кызның сынын тулысынча каплап торган һәм шушы аркада аңа бернинди дә иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләнү мөмкинлеге бирмәгән бөркәнчек ябынып йөрүнең шәригатьтә нигездә булмавын белдереп, хәтта бөркәнчекне Русия мөселман төбәкләренең күбесендә белмәүләре турында яза. Сабирҗан Хәсәни шулай ук Хиҗазда тимер юл төзү өчен акча җыю оештыра.

***«Хәсәния» шәкертләре***

Татар әдәбияты классигы, Татарстанның халык язучысы, драматург, шагыйрь, тел-әдәбият галиме, күренекле фольклорчы Нәкый Исәнбәт Уфа губернасының Златоуст өязе (хәзерге Башкортостанның Салават районы) Малаяз авылында Сираҗетдин мулла гаиләсендә дөньяга килә. Балалары арасында аеруча зиһенле булып үскән Әхмәтнәкыйне әтисе зур дин галиме яки, һичьюгы, үзе кебек абруйлы мулла итәсе килә. Шуның өчен өй шартларында ике ел укырга-язарга өйрәтеп, бер ел авылда үзе ачкан җәдит мәктәбендә ибтидаины (башлангычны) тәмамлаткач, 1909-нчы елда ул тугыз яшьлек малаен Уфа шәһәрендәге кайчандыр үзе белән бергә укыган Сабир хәзрәтнең «Хәсәния» мәдрәсәсенә илтеп куя. Кечкенәдән милли-мәдәни алгарыш рухын күңеленә сеңдерә барган Әхмәтнәкый «Хәсәния»дә укыган елларында дәртләнеп шигырь яза. Аның шагыйрьлек даны, үз мәдрәсәләре чигеннән чыгып, Уфадагы башка мәдрәсә шәкертләре арасында да тарала. «Галия» мәдрәсәсендә укып йөргән һәм, «Хәсәния» мәдрәсәсенә килеп, шәкертнең шигырьләр дәфтәре белән танышкан Шәехзадә Бабич соңыннан аңа багышлап шундый шигъри юллар да яза:

«*Мин сине тәбрик итәм шигырең белән, Әхмәтнәкый,*
*Бик шат улдым, мәмнүн улдым сиңа, рәхмәт, Нәкый!*»

1914-нче елда, «Хәсәния»дә рөшдине (урта белем алуны) тәмамлагач, Әхмәтнәкый Казанга китә һәм 1916-нчы елның көзенә кадәр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый.

«Хәсәния»дә шулай ук педагог-галим Мәгъдән Мәһди һәм башка шәхесләр белем ала.

***Мәдрәсә язмышы***

«Хәсәния» мәдрәсәсе 1920-нче елда Уфа шәһәре халык мәгарифе бүлеге карамагына тапшырыла. Монда берничә ел беренче баскыч (башлангыч) татар мәктәбе эшли. Ул 1923-нче елда ябылып, бинасында татар китапханәсе оештырыла. Шәһәр китапханәсе, бина авария хәлендә дип, дистә еллар элек ябыла, әле ул ташландык хәлдә. Мәдрәсәнең элекке бинасы 2014-нче елдан Русия мөселманнары Үзәк диния нәзарәте милке санала.

***Ахун***

1916-нчы елда Диния нәзарәте Мөхәммәтсабир Хәсәнигә ахун дәрәҗәсе бирүне юллау турында карар чыгара. Шушы карар һәм мөфтинең хаты Уфа губерна идарәсенә тапшырыла. Шул елның 18 августында Мөхәммәтсабир Хәсәнигә ахун дәрәҗәсе бирелә. Түбәндәге документлар шул хакта сөйли:

*«Оренбургское Магометанское Духовное Собрание.*

*25 июля 1916 года, №5165*

*В Уфимское Губернское Правление*

*Имам-хатыб 3-й соборной мечети города Уфы Мухамед-Сабир Хасанов, утвержденный в этой долности 16 сентября 1903 года за №3291, за все время тринадцатилетней службы, будучи нравственного и добраго поведения, всегда ревностно и усердно относился к своим духовным и приходским обязанностям. В своих проповедях призывает прихожан к нравственности, подчинению закону и уважению властей. В деле ведения метрических книг, доставки метрических справок в официальныя учреждения, отличался всегда аккуратностью и исполнительностью и ни в чем не провинился перед Духовным Собранием.*

*За время военных действий неоднократно отправлял духовныя требы для воинских чинов магометан гарнизона Уфы, да и вообще за время своей долголетней службы Хасанов обращал на себя внимание безукаризненным поведением и вполне аккуратным, добросовестным, умелым и толковым выполнением возложенных на него обязанностей и таким же исполнением порученных ему Собранием отдельных требований; кроме того Хасанов имеет образовательный ценз–свидетельство в знании русского языка на степень кандидата Члена Духовного Собрания, а поэтому руководствуясь 1416 ст. XI т. I ч. Изд 1869 г. Духовное Собрание просит Губернское Правление в поощрение отличной и усердной службы имам-хатыпа 3-й соборной мечети Уфы Мухамед-Сабира Хасанова, возвести его в почетное звание ахуна о чем и выдать ему установленное свидетельство, а Собрание о последующем, не отказать, уведомить».*

*«Оренбургский муфти*

*Его Превосходительству П.П. Башилову*

*№87, 28 июля 1916 года.*

*Ваше Превосходительство*

*Милостивый Государь*

*Петр Петрович.*

*Пользуясь любезным указанием Ваше Превосходительства, имею честь уведомить, что 25-го сего июля, за №5165, препровождено в Губернское Правление постановление Духовного Собрания о возведении в почетное звание «ахуна» имам-хатыпа 3-й соборной мечети Уфы Мухамед-Сабира Хасанова и покорнейше прошу Ваше Превосходительство не отказывать в утверждении этого постановления о Хасанове, который известен Собранию и мне с самой хорошей стороны и за свою тринадцатилетнюю службу в приходе он вполне заслуживает возведения в почетное звание «ахуна» своего 3-го прихода.*

*Пользуясь случаем, прошу Ваше Превосходительство принять уверение в глубочайшем моем к Вам уважении и искренней преданности.*

*Вашего Превосходительства покорный слуга*

*М.-Сафа Баязитов».*

*«Уфимское Губернское Правление,*

*Отделение 2, стол 4, 19 августа 1916 года.*

*Уфимскому Городскому Полицейскому Управлению.*

*Губернское Правление предлагает Полицейскому Управлению объявить прихожанам 3-й соборной мечети Уфы и хатыпу этой мечети Мухамет-Сабиру Мухаметзянову Хасянову, что последний во внимание его усердной и ревностной службы по постановлению, состоявшемуся 18 августа с. г., возведен в почетное звание ахуна, вследствие представления о том Оренбургского Магометанского Духовного Собрания от 25 июля с. г. за № 5165».*

*«1916 года августа 26 дня, я, ниже подписавшийся мулла 3-й соборной мечети города Уфа Мухаметсабир Мухаметзянович Хасанов, даю настоящую расписку в том, что Указ Уфимского Губернского Правления за № 3290, приложение к предписанию Уфимского Губернского Правления за № 200 сего числа получил и Гербный сбор в сумме одного рубля уплатил. В том и подтверждаю.*

*М.-С. Хасанов».*

### ***Мондый җеназа, бәлки, Уфа шәһәрендә ахыргысыдыр***

Мөхәммәтсабир Хәсәни 1917-нче елда Уфада мөселманнар арасында ватандарлык фикерләрен тарату комитеты әгъзасы була. Комитет 1917-нче елның 3 мартыннан 17 апрельгә кадәр эшләгән, ул Оештыру җыены, демократик республика төзүгә, төрки-татарларның берлеге, Русия мөселманнары өчен милли-мәдәни автономия сорап мөрәҗәгать иткән. Комитетның Уфада 15 кешедән торган идарәсе һәм Көньяк Урал өязләрендә вәкилләкләре булган.

Уфаның мәхәллә имам-хатыйбы, Үзәк диния нәзарәте әгъзасы Мөхәммәтсабир әл-Хәсәни 3-нче Бөтенбашкорт корылтаенда Башкортостан мөселманнары Диния нәзарәте составына сайлана, 1918-нче елның апрелендә аннан чыга. Ул 1924-нче елның 2 апрелендә вафат була, Уфаның мөселман зиратында җирләнгән.

Ризаэддин Фәхреддин «Асар» хезмәтендә болай дип яза: «*Мөхәммәдсабир бине Мөхәммәдҗан бине Хәсән бине Мортаза Уфа шәһәрендә өченче мәсҗед хозурында имам вә мөдәррис булып, өч йөз кырык икенче (1342/1924) ел, 27 шәгъбанда (2 апрель) Уфаның авырулар йортында вафат булды вә 29 шәгъбан җомга намазындан соң җәмгы газыйм берлә*

*үзенең мәсҗеде ихатасында җеназасын кычкырып укыдым. Мазарына барып дәфен соңында тәлкыйн итеп кайттым.*

*Дөньяга килүе Богырыслан тәвабигы Бакый авылында милади берлә 1865 ел февралендә иде. Үзенең туганы Газизҗан бине Мөхәммәдҗан мәдрәсәсендә укыган вә, Троицкий шәһәренә барып, дамелла Җәмаледдин бине Сөбханколый һәм дә шәех Зәйнулла Рәсули хозурларында тәкмил дәрес иткән иде. Уфада өченче мәсҗед бина ителгәндән соң, беренче имам булды.*

*19<...> елда әһале тарафыннан сайланып, Государственный Думага барып та беркадәр вакытлар Петербург шәһәрендә торды. Инкыйлаб соңында әһле ислам нәдвәсе тарафыннан интихаб ителеп, Диния Нәзарәтендә бер нәүбәт әгъзалык хезмәте дә итте...*

*Өендә вакытында да гыядәсенә барган идем. Авырулар йортына да бер мәртәбә бардым. Хәле авыр иде. Сөйләшә алмады. Тануында да шөбһәләндем. Миндән соң 12 сәгатьләр үткәч, вафат булган. Аллаһы Тәгалә гафу мәрхәмәт итсен иде.*

*Үзенең мәсҗеде алдында җеназасын үзем укыдым. Җәмәгать бик күп булды. Һәммә догаларны вә салаватларны җәһр берлә әда кылдым вә озатып мәкъбәрәсенә дә бардым, җәмәгатьдән аерылып калып талкыйн кылдым. Кайтуымда гаиләсенә кереп тәгъзия иттем вә сабырга дәгъвәт кылдым.*

*Тәҗһиз вә тәкфин вә күчерү бабында бу адәм бәхетле булды. Бу вакытта Уфада ислам кояшы баемаган, һиммәт вә гайрәт нуры сүнмәгән иде. Уфа мөселманлары иттифак берлә берләшеп озаттылар вә зорур йомышлар хакында йөгерешеп йөрделәр вә һәрбере атларын җигеп хазир тордылар. Бу рәвештә күңелле озатылган җеназаның, бәлки, Уфа шәһәрендә ахыргысы булгандыр. Инде ат та, арба да калмады, әһле ислам да таралды вә югалды. Суфый Аллаһиярның: «Аягымдан тотып сөдерәң ләхедкә» дигән сүзенә муафыйк, аягымдан сөрәп булса да ләхедкә илтеп куячакларын белсәң, җәмгы хәтер кылып йөрер идең. Этләргә ташлауларындан хәвеф зур, Инсанларның башларына килә торган фәлякәтләрнең вә хәсарәтләрнең дәһшәтлесе динсезлек икәнлекне күземез берлә күрдек, моның нәтиҗәсен һәр көн вә һәр сәгатьтә тәҗрибә итеп тордык. Мондан соң ниләр күрәчәкмез? Дөреслектә, кайгымны вә сагышымны бары тик Аллаһыга гына шикаять кыламын».*

***Мәчетнең ябылуы***

Шул 1924-нче елда мәгърифәтче, педагог, үзенчәлекле Исламият белгече, философ, күренекле дин вә җәмәгать эшлеклесе Зыяэтдин бине Җәмалетдин әл-Кәмали 3-нче җәмигъ мәчете имамы булып раслана. Ул вакытта мәхәлләдә 825 мөселман исәптә торган. Документлардан күренүенчә,

1926-нчы елның 16 ноябрендә 3-нче җәмигъ мәчеттә 51 яшьлек Зыя Кәмали – имам, 51 яшьлек Габдулла бине Ногман Кариев мәзин вазифасын башкарган (1930-нчы елның 7 мартында эшеннән киткән); 54 яшьлек Миңнекәрим Ильясов, 51 яшьлек Нургали Алмаев, 40 яшьлек Гәрәй Абзаев һәм 33 яшьлек Нигъмәтҗан Корманкаев өченче мәхәллә башкарма идарәсе әгъзалары булып торган. Шуны да әйтеп китү урынлы булыр, 1906-нчы елда Уфада югары уку йорты «Мәдрәсәи Галия Диния»не ачкан, бик күп дини әсәрләр авторы Зыяэтдин әл-Кәмали 1938-нче елның 22 апрелендә кулга алына, җиде елга төрмәгә утыртыла, 1942-нче елда Самара төрмәсендә корбан була. 1956-нчы елның 17 мартында аклана.

1930-нчы елларда мәчеттә имам һәм мәдрәсәдә мөдәррис булып Мөхетдин Сатаев та эшли башлый. Аның хатыны Нәгыймә Габдрахман кызы икмәк пешереп сата.

1920–1930-нчы елларда 3-нче җәмигъ мәчетне ябу мәсьәләсе берничә тапкыр күтәрелгән. Ул вакытта Уфа шәһәр советы мәчетнең манарасын янгын каланчасы итеп файдаланырга планлаштырган. Тарихчы Айсылу Юнысова фикеренчә, 3-нче мәчетнең Үзәк диния нәзарәтенән Башкортостан мөселманнары диния нәзарәте карамагына күчерелүе мәхәлләне саклап калырга ярдәм иткән, гыйбадәтханә 1940-нчы елга кадәр эшләгән.

1940-нчы елның 20 гыйнварында БАССР Югары Советы карары белән мәчет ябыла һәм бина Уфаның Ленин районы башкарма комитетына мәктәп итеп үзгәртеп кору өчен тапшырыла:

«*Выписка из протокола заседания Президиума Верховного Совета БАССР от 20.01.1940 г.*

*О закрытии мечети третьего прихода Ленинского района города Уфы.*

*Ходатайство граждан Ленинского района города Уфы и Президиума Ленинского райсовета города Уфы о закрытии мечети третьего прихода в Ленинском районе города Уфы – удовлетворить. Здание мечети передать Исполнительному Комитету Ленинского районного Совета депутатов трудящихся для переоборудования под среднюю школу взрослых.*

*Председатель Президиума Верховного Совета Башкирской АССР Ибрагимов*

*Секретарь Президиума Верховного Совета Башкирской АССР М. Вальшин*».

Әле биредә югары спорт осталыгы мәктәбе урнашкан.

***Хәсәновлар***

Сабирҗан хәзрәт Хәсәни җәмәгате Миңневафа Гатаулла кызы белән дүрт бала тәрбияләп үстергәннәр: Халисә (1914-нче елның 13 июнендә туган), Әнвәр (1918-нче елның 21 февралендә туган), Габделхәй һәм Әминә. Сабирҗан Хәсәнинең турыдан-туры нәселен дәвам итүчеләрнең

язмышлары билгесез. «Хәсәновлар гаиләсе элек яшәгән Уфаның Госпиталь урамы, 15 адресы буенча урнашкан йорт сатылган,– ди Юлия Хәсәнова, Сабирҗан Хәсәнинең энесе Газизҗанның нәселен дәвам итүче.– Газизҗанның улы Миргабидҗан Хәсәни авылда эчкән ир-егетләрне таягы белән тотып кыйнарга да күп сорамаган. Аның алты баласы булган: Нурлыхода, Мөзәки, Мөхәммәт, Мөҗәһит, Надия һәм Наилә.

Миргабидҗан Хәсәни 1929-нчы елның 18 ноябрендә икмәк тапшырмаган өчен 300 сум штрафка һәм 3 елга хөкем ителгән, Вишерь лагерена озатылган. 1932-нче елның 2 сентябрендә туган ягы Байтуган районы Камышлы авылына кайткан. Аның хатынын улы һәм кызы белән 1931-нче елда Казакъстанга сөргән булганнар. 1932-нче елның ноябрендә ул янә кулга алынып, 16 көн утырып чыга. 1933-нче елның 16 февралендә паспорт юллау өчен Уфага метиркә кәгазе алырга бара. Анда мөфти Ризаэддин Фәхреддин, Диния нәзарәтендә эшләүче Кашшафетдин Тәрҗемани, Зыя Кәмали, Мөхлисә Бубый һәм Зариф Исхаков белән очраша. Кашшафетдин Тәрҗемани аңа мәчетләр һәм дин әһелләре турында мәгълүмат тупларга куша.

1933-нче елның маенда Миргабидҗан Хәсәни Байтуган район башкарма комитетында теркәлеп, имам-мөхтәсиб булып эшли башлый. Шул ук елның 24 ноябрендә янә кулга алынып, 5 елга хөкем ителә, ул контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнә. Миргабидҗан Хәсәни советларга каршы лозунглар кычкырганы һәм НКВД бинасында намаз укыганы өчен 1937-нче елда атып үтерелә.

Миргабидҗанның улы Мөҗәһит әнисе белән Казакъстанга сөрелә, аңа атасы белән аралашырга рөхсәт ителми. Карагандада икмәк заводында эшли, шәһәр мөселманнары арасында абруйлы кеше булган. Җәмәгате Бибисара Зәкиҗан кызы белән ике ул: Габделмәҗит һәм Фаикны тәрбияләп үстергәннәр. Габделмәҗит җәмәгате Нажия Ильяс кызы белән Ринат, Радик һәм миңа гомер бүләк иткәннәр. Мин Казанда яшим, табиб-невролог булып эшлим. Тормыш иптәшем белән нәсел шәҗәрәсен өйрәнәбез, татар тарихы, мәдәнияте белән кызыксынабыз, иске китапларны өйрәнәбез».

***Сатаевлар***

Мөхетдин Сатаев Истанбул университетын тәмамлап, Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә логика һәм әдәбият фәннәрен укыткан. Мөхетдин Җәгъфәрсадыйк улы мәдрәсә шәкертләре, булачак күренекле шагыйрь Шәехзадә Бабич белән төшкән фотосурәт сакланган. Ул Уфада 1906–1907-нче елларда чыккан «Әл-галәме әл-Ислами» («Ислам дөньясы») татар дини-фәлсәфи һәм әдәби-иҗтимагый гәзитен чыгаруда катнаша. Мөхәммәтсабир Хәсәнинең вафатыннан соң, Зыя Камали 3-нче мәчеткә имам булып тәгаенләнә. Мөхетдин Сатаев биредә имам булып эшли. 1930-нчы елның 7 апрелендә Мөхетдин Җәгъфәрсадыйк улына 3-нче җәмигъ мәчет янында йорт салу өчен

җир бирелә. Имам Мөхетдин Сатаев (Нуриманов урамы, 14) һәм Сабирҗан Хәсәнинең (Госпиталь урамы, 15) йортлары ихатасы бер койма белән уратып алынган була. 1929-нчы елның 1 июлендә имам Сатаев Хәсәновларның нигезсез, агачтан төзелгән мунчасын сатып алу турында документ сакланган.

1932-нче елның августында Мөхетдин Сатаев вафат була, аның милке җәмәгате Нәгыймә Габдрахман кызына күчә, ул анда 1940-нчы елга кадәр яши. Нәгыймә Сатаева бик кунакчыл кеше булган. Сатаевларның варисларында Нәгыймә Габдрахман кызының борынгы асылташлар белән бизәлгән балдагы саклана. Сатаевларның балалары булмаган, милек Зөфәр Караметдин улына күчә. Шуны да әйтеп китәргә кирәк, бертуган Мөхетдин һәм Караметдин Сатаевлар бертуган Нәгыймә һәм Әсхәбҗамал Габдрахман кызларына өйләнгән булган.

Мөхетдин Сатаев җитеш тормышта яшәгән. Аның өендә аш-су гарнитуры, 2 буфет, комод, зур көзге, Будянск фаянс заводында эшләнгән фарфор савыт-саба, 1905-нче елда Тулада ясалган самавыр булган. Шулай ук аның китаплары һәм кульязмалары сакланган.

Зөфәр Сатаев тарих белән кызыксына, үзенең ата-бабларының һәм җәмәгате Әдия Мөхәммәт кызының ата-балалары Емашев һәм Хисамовларның шәҗәрәсен төзи. Зөфәр Караметдин улы төзегән шәҗәрә буенча Сатаевларның 14 буын вәкилләре билгеле. Шәҗәрә Темниковода яшәүче Саты морзадан башлана. Сатының балалары Әлимбәктән башлап XVII гасыр ахыры XVIII гасыр башында әлеге Башкортостанның Кушнаренко районы җирләренә күчеп утырып, Чәрмәсән буенда Рәсмәкәй авылына нигез салганнар.

Зөфәр Сатаев юллар проектлаучы булып эшли, 1930-нчы елларда «Яшь коммунар» һәм «Ленинсе» гәзитләрендә җаваплы мөхәррир, анары немец теленнән тәрҗемәче булып хезмәт сала. Соңрак ул хәрби частьларда инспектор була, Кенгсбергтагы бункерларны, Байконурдагы космодромны кабул итүдә катнаша.

Әле Зөфәр Караметдин улының оныгы Рөстәм Фәрит улы Мөхетдин Сатаевтан калган борынгы мебельгә реставрация үткәрә, гаилә архивын системага сала, тарихи әйберләрне кадерләп саклый.

### *Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк...*

Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк, дигән бер акыл иясе. Хак сүзләр. Уфадагы 3-нче җәмигъ мәчет, «Хәсәния» мәдрәсәсендә эшләүче шәхесләрнең нәселен дәвамчылары тарихка битараф түгел. Сатаевларның килене Эльза Мәүлимшина һәм Мөхәммәтсабир Хәсәнинең нәселен дәвам итүче Юлия Хәсәнова тарафыннан интернеттагы «Фейсбук» һәм «ВКонтакте» социаль челтәрләрендә «Третья Соборная мечеть Уфы и медресе “Хасания”» дигән төркемнәр ачылды. Көн саен диярлек анда та-

рихи документлар, фотосурәтләр урнаштырыла. Оештыручыларның төп максаты – мәдәни мирас объектларын киләсе буыннар өчен саклап калу, төзекләндерү һәм аларны популярлаштыру.

Киләчәктә тарихи мәчет һәм мәдрәсә турында тарихчылар, туган якны өйрәнүчеләр катнашында телевизион тапшырулар, видеороликлар төшерү планлаштырыла.



*Мөхәммәтсабир Хәсәни*



*Уфадагы 3-нче җәмигъ мәчете*

2017-нче елның 8 августында инциатив төркем Башкортостанның Мәдәни мирас объектларын дәүләт саклавы буенча идарәгә Уфа шәһәренең Нуриманов урамының 14-нче йортны «3-нче җәмигъ мәчет, «Хәсәния» мәдрәсәсе һәм имам Сатаев йорты» тарихи-архитектура комплексының бер өлеше итеп тану турында мөрәҗәгать юллый. Русия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте дә мөрәҗәгатьне хуплый.

Әйтергә кирәк, әлеге вакытта элекке 3-нче җәмигъ мәчет һәм «Хәсәния» мәдрәсә биналарына торак төзүче компанияләр тарафыннан куркыныч яный. Аларны сүтеп, урынына күп катлы йорт салырга хыялланучылар да бар. Әмма бу биналарның тарихи әһәмияте искиткеч зур булуын күз уңыннан ычкындырырга ярамый. Шуңа да мондый эшкә юл куелмаска тиеш! Русия Федерациясе Конституциясенең 44-нче маддәсендә «... һәркем тарихи һәм мәдәни мирасны сакларга, тарихи һәм мәдәни комарткыларны сакчыл кулланырга бурычлы», – дип язылган. Гомумән, тарихи үткәнгә төкерү – куркыныч нәрсә. Шуны онытмасак иде...

***М.Х. Ибрагимов***

# ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ И ЕГО РОЛЬ В ОБРАЗОВАНИИ АВТОНОМИИ БАШКОРТОСТАНА И ТАТАРСТАНА

***Аннотация:*** *Статья посвящена вкладу государственного и общественного деятеля, классика татарской литературы, историка и просветителя Галимджана Ибрагимова (1887–1938) в образовании автономий Башкортостана и Татарстана. Он широко известен как основатель современной литературы и письменности Татарстана, является автором более 500 научных статей, им написаны такие романы как «Судьба татарки», «Дочь степи», раскрывающие нелегкую судьбу женщины в далеком прошлом.*

*Галимджан Ибрагимов является участником двух русских революций, принимал участие в Гражданской войне, по решению руководителей Советской России назначался представителем Наркомнаца по Уфимской губернии. Кроме того, он последовательно и упорно занимался созданием территориальных автономий Башкортостана и Татарстана.*

***Ключевые слова:*** *тюрки-мусульмане, Временное правительство, социал-революционеры, большевики, штат Урал-Идель, территориальная автономия, Национальное собрание, Башкортостан, Татарстан.*

В свете подготовки к 100-летнему юбилею со дня образования автономии Башкортостана автор настоящей публикации изучил множество документов и материалов, связанных с этим важным событием в многовековой истории тюрков-мусульман. При этом он столкнулся с таким фактом, что процесс изучения формирования автономий «малых народов» Урала-Поволжья обошел вниманием роль Галимджана Ибрагимова в этом вопросе. По мере изучения его биографии и жизнедеятельности, автор настоящей статьи установил, что Галимджан Ибрагимов шел целеустремленно и упорно к претворению в жизнь идеи территориальной автономии тюрков-мусульман данного региона.

В публикуемой статье были использованы материалы и документы, характеризующие его роль и место в образовании автономии республик Башкортостана и Татарстана в сложный период становления обновленной России от Февральской революции до принятия решений об образовании автономии Башкортостана и Татарстана.

Свои первые шаги в политику Галимджан Ибрагимов сделал в медресе «Валия-муллы» (Оренбург), где под влиянием бурных событий начала

XX в. были организованы выступления шакирдов против устоев старометодного медресе. Однако, «данный проступок не остался без внимания царских властей и хозяев медресе, поэтому его выгнали из медресе “Валия”» [Ибрагимов: 2012. С. 266].

Осенью 1906 г., он поступает во вновь открытое медресе «Галия» (Уфа), где пишет свой первый рассказ «Изгнание шакирда Заки из медресе», и несколько позже было опубликовано его сочинение «Коран от бога или нет?». В них Галимджан Ибрагимов отражает негодные методы обучения, за что он вновь был изгнан из медресе, но под благовидным предлогом.

Свою известность среди демократически настроенной мусульманской молодежи Галимджан Ибрагимов приобретает после издания романа «Молодые сердца» (1909) и став известным во всем татарском мире писателем. Однако, лидерство привело его к противостоянию со старой татарской интеллигенций, поэтому он в 1913 г. появляется в Киеве (Украина) в качестве учителя татарского языка и культуры.

Автор полагает, что существует еще одна версия его отъезда в Киев: он принял предложение от «личного друга» И.В. Сталина для организации политической партии среди молодежи из числа мусульман–выходцев с Кавказа. Так, в своей автобиографии 1924 г. Галимджан Ибрагимов указал, что «… во время реакции 1912–1913 гг. был в Киеве, где принимал активное участие в подпольных организациях мусульманского революционного студенчества, за что был арестован и заключен в тюрьму …» [Ибрагимов: 2012. С. 9]. Участниками подпольной организации намечалось проведение съезда «Общества мусульманского студенчества» [Сенюткина: 2007. С. 256–268]. Автор полагает, что именно это событие сыграло существенную роль в его становлении как видного политического деятеля, стоящего на пути преобразования России с учетом интересов мусульман.

После возвращения в медресе «Галия» (1915) Галимджан Ибрагимов ведет просветительскую работу и одновременно разрабатывает ряд методических пособий для татарских учебных заведений. Так, в своей монографии А. Хабутдинов подчеркнул, что «основным феноменом развития нации в начале 1910-х гг. становится расширение национальной элиты за счет учителей джадидистских школ и медресе» [Хабутдинов: 2008. С. 206]. Галимджан Ибрагимов надеялся, что татарский язык станет единым для тюрков-мусульман России, не исключая население будущего Татарстана и Башкирии. В своих первых учебниках «Татарская грамматика» (1911), «Теория литературы» (1916), «Методика преподавания родного языка» (1918) Галимджаном Ибрагимовым на научном уровне была заложена грамматическая и филологическая база современного татарского языка и литературы.

После Февральской революции (1917) Временное правительство сняло ряд ранее существовавших запретов для участия в политической жизни страны, предоставив право на выборы в органы местного самоуправления и иные государственные органы без каких-либо ограничений. Тогда наиболее развитая часть мусульманского общества самым активным образом включилась в этот процесс. Эти события серьезнейшим образом повлияли на 30-летнего Галимджана Ибрагимова, который покидает медресе и вплотную подключается к политической жизни России.

Уже в феврале 1917 г. он становится членом социал-революционной (эсеры) партии, программа которой была близка крестьянству и учитывала аграрный характер царской России. При этом Галимджан Ибрагимов сумел создать в Уфе организацию татарских левых эсеров вместе со своими вчерашними шакирдами из медресе «Галия», которую сам возглавил [Ибрагимов: 2012. С. 272]. Большевики в принятый II Всероссийском съездом Декрет о земле включили «Крестьянский наказ о земле», в подготовке которого приняли участие и эсеры [Бухарин: 1988. С. 454].

Занимаясь разрешением вопросов, возникающих у Галимджана Ибрагимова как члена партии эсеров, он не пропускал ни одного мероприятия, проходившего в Уфе. «Практически ни одно значимое мероприятие не прошло без его участия» [Ибрагимов: 2012. С. 273].

При образовании 2 марта 1917 г. «Комитета общественных организаций» в Уфе Галимджан Ибрагимов принимает участие в качестве представителя партии эсеров и входит в его руководство. Он прекрасно понимал, что осознание населением происходящих событий невозможно без мугаллимов (учителей). С этой целью 8 апреля 1917 г. при его участии проводится организационное собрание, имеющее своей задачей создание «Общества учителей-мусульман». В состав его правления был введен также Галимджан Ибрагимов.

Участвуя в работе многих общественных организаций, Г. Ибрагимов решает вместе со своим соратником, писателем Сайфи Казанлы, начать выпуск газеты под названием «Ирек» («Свобода»). Именно эта газета становится главным информационным рупором «территориалистов» и первой социалистической газетой в Уфе. С ее страниц активно пропагандировалась идея необходимости создания собственной республики народов Волго-Уральского региона (штат Идель-Урал), что позволяет считать Галимджана Ибрагимова одним из первых идеологов создания территориальной автономии (республик).

Как известно, одним из своих декретов Временное правительство 15 апреля 1917 г. сняло ограничения гражданам России на участие в органах управления всех уровней, невзирая на вероисповедования и нацио-

нальность, а также на социальное положения. Воспользовавшись этим обстоятельством, в 1917 г. Галимджан Ибрагимов избирается в гласные Городской Думы Уфы. Это избрание является для него одним из главных шагов в большую политику.

Его бывший шакирд и писатель Сайфи Кудаш в своих воспоминаниях весьма красочно изобразил проходившие выборы: «После Февральской революции в Уфе часто проводились митинги и собрания. Эти собрания проходили крайне шумно. Иногда споры были настолько бурными, что стороны кидались друг на друга стульями и вступали в драки» [Кудаш: 1974. С. 270]. После выборов «... группа Галимджана Ибрагимова выдвинула в общей части программу, близкую к программе эсеров. В национальном вопросе каждая нация должна была взять под свой контроль театр, литературу, язык, школу» [Хабутдинов: 2008. С. 292].

Затем, в мае 1917 г., в Москве состоялся I Съезд мусульманских народов, избравший Милли Шуро – представительный орган всех российских мусульман. В работе съезда активное участие принял и Галимджан Ибрагимов, сумевший дать «наиболее квалифицированную оценку ... положению дел». К сожалению, он не учел «выделение такой этнической группы, как башкиры» [Юлдашбаев: 2002. С. 171]. Но в резолютивной части I Всероссийского съезда мусульман России, состоявшегося в мае 1917 г. в Москве, о формах управления мусульманских народностей записано, что «...[это] демократическая республика на национально-территориальных началах» [Касимов: 1997. С. 61]. В дальнейшем на областном съезде башкир, прошедшем 25–29 августа 1917 г., было подтверждено это решение о федеративно-демократическом устройстве России. «Таков тот путь, по которому идут башкиры-федералисты», – заявлял съезд. Здесь же было выделено, что имеется ввиду концепция «автономного Башкортостана» [Касимов: 1997. С. 63].

В то же время Заки Валиди свое участие на этом съезде оценил следующим образом: «... на московском съезде я не выступал за независимость Башкортостана...» [Гумеров: 1997. С. 11].

О характере противостояния различных этнических групп и принятых там решениях пишет И. Гарифуллин: «Второй мусульманский съезд, проходивший в Казани в июле того же года, был уже целиком татаро-башкирским, т.е. без участия остальных мусульманских народов бывшей Российской империи. Здесь было принято решение созвать позднее в Уфе Милли Меджлис (Национальный парламент) – для реализации программ. Отметим, что два этих съезда успели выявить оппонирующие друг другу политические проекты. Первая группа – «тюркисты» («төрекчеләр») или «унитаристы», собралась вокруг бывшего депутата

Госдумы, кадета Садри Максуди. Вторая группа [Галимджана Ибрагимова] – «территориалисты» («туфракчылар») состояла в основном из числа стремительно набиравших популярность татарских «левых» (левые эсеры, большевики и меньшевики-интернационалисты). Эта группа выступала за немедленное провозглашение территориальной автономии на большей территории Идель-Урала (Урало-Поволжья), где проживала основная масса татаро-башкир и других народов Поволжья. И на I Всероссийском мусульманском съезде эта идея о национально-территориальной автономии была поддержана в форме декларации о необходимости её создания». Далее этот историк указывает: «Через два месяца в июле 1917 г. в Казани на Втором мусульманском съезде сторонников национально-культурной автономии оказалось несколько больше – тем не менее идея о необходимости территориальной автономии не исчезла с повестки дня, а получила свое дальнейшее развитие. При этом… единственно верной оказалась ставка именно на построение территориальной автономии (республики), без которой любые проекты экстерриториальной национально-культурной автономии являются утопическими. Национально-культурная автономия могла быть эффективной только при стечении определенных обстоятельств и только при наличии крепкой базы в лице республики (территориальной автономии)» [https://www.idelreal.org/a/tatarskomu-parlamentu-100-let/28886696.html].

Активная жизнеутверждающая позиция Галимджана Ибрагимова потребовала его участия в большой политике и он принял решение участвовать от Уфимской губернии в выборах Учредительного собрания России. Результат был ошеломляющим: 65% голосов против 5% большевиков, 14% башкир-федералистов и 1,4% кадетов.

Впервые в истории татарского политического движения Галимджан Ибрагимов достиг значительных результатов, объединив 4 организации: Уфимский Губернский совет крестьянских депутатов, левую фракцию Губернского мусульманского Национального совета, Уфимскую Губернскую организацию социал-революционеров-татар и Уфимский Мусульманский совет, возглавив список № 3 по Уфимскому избирательному округу [Юлдашбаев: 2002. С. 176].

Необходимо отметить, что воздух революционных преобразований захватил и «лидер башкирской автономии» Ахмед-Заки Валиди, бывшего коллегу Галимджана Ибрагимова по медресе «Галия» [Ибрагимов: 2012. С. 272]. В свою очередь, Заки Валиди выдвинулся в Учредительное собрание от партии «Федералисты-башкиры», возглавив список № 11 по тому же округу [Юлдашбаев: 2002. С. 179]. По поводу контактов этих двух лиц есть ряд документов в Национальной библиотеке имени Заки

Валиди (Уфа), свидетельствующих о начале совместной деятельности двух лидеров национального движения в 1912 г. В сохранившейся книге «Карак мулла» (1912) имеется автограф Галимджана Ибрагимова следующего содержания: «С уважением тюркологу господину Заки Валиди. 1912 год, февраль». Эта находка открывает новые страницы из их жизни.

Поэтому нет ничего удивительного в том, что они шли к образованию территориальной автономии в одном русле вплоть до момента образования Башкирской Автономной Советской Социалистической Республики (1919) в пределах Малой Башкирии. Также были обнаружены свидетельства продолжения их дружеских взаимоотношений. Так, из сообщения Башкирского Областного отдела ОГПУ от 23/III г. №274 «…у Г. Ибрагимова хранится личный архив буржуазного националиста, эмигрировавшего в Турцию Заки Валидова. Ибрагимов Г. после эмигрирования за границу Заки Валидова и Батталова, через мулл, поехавших в Мекку, установил с ними связь…» [Ибрагимов: 2012. С. 39].

После роспуска Учредительного собрания большевиками и встречи с лидерами партии большевиков В.И. Лениным и И.В. Сталиным, Галимджан Ибрагимов принимает для себя нелегкое решение о сотрудничестве с большевиками. По результатам встречи были внесены предложения по проведению национальных преобразований на территории преимущественного проживания мусульман и принято решение об организации при Советском правительстве Комиссариата по делам мусульман Внутренней России, в состав которого были включены: председателем Мулланур Вахитов – от Казанской губернии и его товарищем Галимджан Ибрагимов – от Уфимской губернии, Шариф Манатов – от Оренбургской губернии.

Таким образом, следуя понятиям XXI в., Галимджан Ибрагимов фактически был назначен Советским Правительством первым руководителем вновь образующейся в пределах Уфимской губернии республики. Этот факт почему-то в настоящее время остается без должного внимания. В создавшейся ситуации, несмотря на некий компромисс, подобное предложение имело большое значение, так как была реальная возможность осуществления намеченных планов по созданию автономии в Урало-Волжском регионе с численным преимуществом тюрко-мусульман.

На проходившем в Уфе заседании с 22 ноября 1917 г. по 11 февраля 1918 г. было вынесено постановление о принятии «Основ национально-культурной автономии мусульман внутренней России», которая явилась первой «попыткой документального оформления государственности татар» [Фахрутдинов: 2015. С. 314]. Принявшие участие на этом заседании две группировки – «тюркисты» и «туфракчылар» («территори-

алисты») смогли достичь согласия между собой. 29 ноября 1917 г. высокое Собрание приняло решение о создании территориальной автономии (государственности) в форме штата [Фахрутдинов: 2015. С. 314].

Татарские социалисты – Галимджан Ибрагимов и его сторонники были не только за провозглашение территориальной автономии, но и разрабатывали планы создания национальной государственности татар, поэтому Ибрагимов выступил резко против решения съезда о культурной автономии мусульман внутренней России и Сибири [Там же. С. 315].

В дальнейшем, 12 декабря [1917 г.] на совещании башкирского курултая, в резолюции «О поддержке Национальным собранием идеи федерации», выступление Галимджана Ибрагимова как представителя Уфимского национального собрания мусульман было встречено аплодисментами [Юлдашбаев: 2002. С. 254].

Однако, какое-либо решение о формах автономии ещё принято не было. 15 декабря 1917 г. Центральным Башкирским Шуро было вынесено Постановление (резолюция) Курултая «О национально-суверенных правах автономии в составе федеративно-демократической России», которое было подписано председателем съезда Курултая Ахмет-Заки Валидовым и одним из «помощников председателя» Галимджаном Ибрагимовым [Юлдашбаев: 2002. С. 201].

Ряд последующих документов ярко освещают отношение народов Урало-Поволжья и их лидеров к вопросу создания Урало-Волжского штата с включением в его состав Башкортостана. Протокол № 7 от 3 апреля 1918 г. «Заседания Уфимского отделения коллегии по осуществлению Урало-Волжского штата», завершен следующей фразой: «Куда татары пойдут, и мы туда же» [Юлдашбаев: 2002. С. 459–460]. 17 апреля 1918 г. в Москве газета «Чулпан» опубликовала воззвание к башкирам о признании Башкиро-Татарской республики: «Она воплощение священного желания башкирского народа» [Юлдашбаев: 2002. С. 456–457]. 28 апреля 1918 г. на собрании уфимских рабочих-татар после выступления Галимджана Ибрагимова была принята резолюция: «Татаро-башкирские рабочие всеми силами поддерживают осуществление Татаро-Башкирской советской республики». А через несколько дней, 2 мая 1918 г., Галимджан Ибрагимов в доме рабочих-татар в течение 2-х часов докладывал о современном положении и о Татаро-Башкирской республике» [Юлдашбаев: 2002. С. 460]. После рассмотрения включенного в повестку дня вопроса «О создании Татаро-Башкирской советской республики», было принято постановление, в 4-м пункте которого записано буквально следующее: «Собрание приветствует объединение татаро-башкирских братьев как в Центральном комиссариате, так и в Уфимской губернии, и выражает уве-

ренность, что эти два племени единые в своих устремлениях, будут идти рука об руку в будущем» [Юлдашбаев: 2002. С. 461].

Однако, время внесло свои коррективы в угоду националистам, действовавшим от имени башкир и татар: чаяния простого народа не оправдались. Но нельзя отрицать и роли ряда большевиков в этом противостоянии, бывших категорично против создания Татаро-Башкирской советской республики и тем самым внесших свой вклад в разобщение башкир и татар. Так, большевистское правительство, провозглашая право народов на свое самоопределение, выражало недовольство созданием национальными меньшинствами своих республик. Наример, большевик Грасис высказался следующим образом: «… осуществление Татаро-Башкирской республики усилит межнациональную рознь… Сказать прямо, нет возможности образования Татаро-Башкирского штата» [Юлдашбаев: 2002. С. 498].

И вновь, на совещании, проходившем в Москве с 10 по 17 мая 1918 г. «По вопросу об образовании Татаро-Башкирской республики» Галимджан Ибрагимов выступил с докладом о необходимости образования Татаро-Башкирской республики, утверждая «что она явится прочной основой для революции и Советской республики» [Юлдашбаев: 2002. С. 507]. По завершении, как мы знаем, на совещании было принято компромиссное решение о созыве Учредительного съезда Татаро-Башкирской республики для принятия окончательного решения. Но самым удивительным явился тот факт, что Председатель СНК В.И. Ленин не согласился с мнением ряда большевиков, возражавших против создания Татаро-башкирской республики.

Галимджан Ибрагимов, уверовав в возможность образования Татаро-Башкирской республики, принимал участие на III Всероссийском съезде учителей-мусульман, на котором утверждал, что вопрос о Татаро-Башкирской республике был одобрен лидерами большевиков, несмотря «на некоторых большевиков». При этом он добавил, что «вопрос о создании штата впервые был поднят башкирами» [Юлдашбаев: 2002. С. 509].

И уже 31 мая 1918 г. из Москвы в адрес Уфимского губсовнаркома поступает телеграмма с указанием даты созыва Учредительного съезда советов Татаро-Башкирской республики, с включением в него Галимджана Ибрагимова в качестве представителя от Уфимской губернии. Но последующие события привели к тому, что Учредительный съезд не состоялся, а сама идея создания Татаро-Башкирской советской республики осталась только на бумаге в виде проекта.

В конечном счете 13 декабря 1919 г. Политбюро ЦК РКП приняло постановление об отмене декрета о Татаро-Башкирской республике.

Завершая историю претворения в реальную жизнь идей о самоопределении татар и башкир при самом активном участии Галимджана Ибрагимова, можно сказать, что Советская власть, на словах расширяя права малых народов, низводила их на самом деле на нет. Как указывается, «в бывшем СССР и сегодня считается дурным тоном говорить о национальном суверенитете, о национальных проблемах, о национальной независимости, о национальной государственности. …Но ведь от того, что проблему не называют и о ней не говорят, она не перестает существовать». И далее: «…Колониальная политика царизма, а потом и советская имперская политика ставила одну цель – быстрее покончить с национальной самобытностью…» [Валеев: 1993. С. 18, 73].

Для подобного утверждения достаточно привести один документ, чтобы понять ложность и двойственность деклараций, провозглашенных большевиками относительно прав малых народов на самоопределение, касающихся интересов большей части мусульман России.

Из письма И.В. Сталина В.И. Ленину от 22 сентября 1922 г.: «…За четыре года Гражданской войны, когда мы ввиду интервенции *вынуждены были демонстрировать либерализм* (выделено нами – М.И.) Москвы в национальном вопросе…» [Султанбеков: 1998. С. 99].

В итоге остался только один единственный вариант для осуществления планов по автономии Татарстана – в виде отдельной республики, то есть образование ТАССР (Татарская Автономная Советская Социалистическая Республика).

Духовный лидер мусульман России Ризаэддин Фахруддин положительно оценил борьбу за территориальную автономию, что нашло отражение в отчете Галимджана Ибрагимова в Обком РКП(б) о встрече 23 февраля 1925 г. с ведома партийных органов: «О Татреспублике свое мнение муфтий [Ризаэддин Бин Фахруддин] выразил приблизительно следующими словами: «Мы старые работники татарской культуры некогда мечтали о многом, но наши мечтания не могли дерзнуть того, чтобы представить татар организованными в самостоятельной, автономной республике» [Ибрагимов: 2012. С. 14].

В 1927 г. Г. Ибрагимов к юбилею 10-летия со дня Октябрьской революции написал брошюру «Каким путем пойдет татарская культура?», в которой затронул больные точки о великорусском шовинизме и о не сбывшихся планах по созданию единого территориального пространства для мусульман-тюрков России. Именно в этом году он покинул пост председателя Академцентра с формулировкой «в связи с ухудшением здоровья». Однако, имеется другая точка зрения – был вынужден уйти за «активную националистическую деятельность».

В представленной широкой публике статье отражены роль и место Галимджана Ибрагимова в образовании автономий как Башкортостана, так и Татарстана, осуществленных путем упорной и настойчивой деятельности этого политика. Его роль в национальном движении за самоопределение высока и достойна самого пристального внимания, невзирая на утверждения некоторых исследователей о том, что Галимджан Ибрагимов «сдал северо-западную часть территории Уфимской губернии», в основном состоящую из значительного числа татар, в состав современной Республики Башкортостан. Но детальное изучение его жизнедеятельности говорит об обратном – вся его жизнь была направлена на благо тюрко-мусульманского населения, не исключая татар и башкир. Остается только сожалеть, что многие факты его биографии недоступны и вряд ли мы когда-нибудь узнаем всю правду о нем. На сегодняшний день нам даже неизвестно место, в котором его настигла смерть, а памятник, установленный ему на Архангельском кладбище, всего лишь – кенотаф, что не позволяет утверждать, что он нашел свое последнее пристанище именно в этом месте.

Галимджан Ибрагимов был истинным патриотом своей родины, героем татарского народа и остается им. Он не покинул страну во время гонений за инакомыслие. О нем можно сказать: он великий человек, приложивший немало усилий для процветания своей Родины и ради достойной жизни для многих из нас. Остается только сожалеть, что до настоящего времени в полной мере не изучена его роль в образовании государственности двух братских республик.

## Источники и литература

1. Бухарин Н.И. Избранные произведения. М.: Политиздат, 1988. XII. – 499 с.
2. Валеев Д.Ж. Национальный суверенитет и национальное возрождение. Уфа: «Китап», 1993. – 160 с.
3. Ибрагимов М.Х. Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / [авт.-сост. М.Х. Ибрагимов]. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – 336 с.
4. Гарифуллин И. Рожденный революцией. Татарскому парламенту исполнилось 100 лет. https://www.idelreal.org/a/tatarskomu-parlamentu-100-let/28886696.html (дата обращения 2020.01.12).
5. Гумеров Ф.Х. У истоков борьбы за суверенитет Башкортостана, 1917–1925 гг. Документы и материалы. Уфа: «Китап», 1997. – 232 с.: илл.

6. Касимов С.Ф. Автономия Башкортостана: становление национальной государственности башкирского народа (1917–1925 гг.). Уфа: Китап, 1997. – 352 с.: ил.
7. Кудаш С. Навстречу весне. Незабываемые минуты: по следам юности. М.: «Сов. Писатель», 1974. – 560 с.
8. Сенюткина О.Н. Тюркизм как историческое явление (на материалах истории Российской империи 1905–1916 гг.) / Сенюткина О.Н. Нижний Новгород: Изд-во НГЛУ, 2007.
9. Султанбеков В.Ф., Харисова Л.А., Галямова А.Г. История Татарстана. XX век. 1917–1995 гг. IV часть: Учебное пособие для общеобразовательных заведений. Казань: «Хәтер», 1998. – 416 с.
10. Фахрутдинов Р.Г. История татарского народа / Р.Г. Фахрутдинов, Р.Р. Фахрутдинов. Казань: Тат. кн. изд-во, 2015. – 407 с. с илл.
11. Хабутдинов А.Ю. От общины к нации: татары на пути от средневековья к Новому времени (конец XVII – начало XX вв.) /Айдар Хабутдинов, Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. – 214 с.
12. Юлдашбаев Б.Х. Национально-государственное устройство Башкортостана (1917–1925 гг.). Документы и материалы: в 4 т. / [Авт.-сост. Юлдашбаев Б.Х.]. Т. 1. Уфа: «Китап», 2002. – 608 с.

*Ильмир Мифтахов*

# ОБ ОСНОВАНИИ ДЕРЕВНИ «ВЕНЕЦИЯ» СУЛТАНБЕКОВЦАМИ

С одной стороны, Агидель возле которой озера, круглые и блестящие, словно выпавшие с девичьих карманов, и заросли уремы. С другой – окруженная сосновым лесом и утопающая в зелени, состоящая из одной только улицы деревня. Такими словами описывает деревню Венеция, что на Северо-западе Башкортостана, в Дюртюлинском районе классик татарской литературы, народный писатель Республики Татарстан Фатих Хусни в своем одноименном рассказе, написанном в 1972 г. Он не раз приезжал отдыхать вместе с супругой в 1960-е гг. в «Башкирскую Италию». Здесь и были написаны его произведения «Венеция» и «Звезды над деревней».

Венеция – это название всегда приковывает внимание людей, которые в Дюртюлинском районе Башкортостана оказываются впервые. Рядом с указателем на трассе Дюртюли – Бураево часто можно увидеть останавливающиеся машины: многие спешат запечатлеть себя и своих близких на фоне столь необычного названия. Здесь бывали русский и советский физик, отец атомной бомбы Игорь Васильевич Курчатов, композитор, заслуженный деятель искусств Башкортостана Нариман Гилязетдинович Сабитов. Проживали такие знаменитости, как писатель Фердинанд Мирзаевич Бигашев, поэтесса Ильсияр Зиннуровна Ганиева. И мало кто знает, что слова песни – «Возвращайтесь, журавли» («*Кайтыгыз, торналар*»), написанные Ильсияр Ганиевой, посвящены одному из озер возле деревни.

Первое упоминание о венецианской стороне в историческом архиве датируется 14 марта 1738 г. Это документ, составленный сыновьями Султанбека Мятикова, основателя села Старосултанбеково Дюртюлинского района – Сатаем и Киязом. В нем говорится об отдаче «рыбных ловлей... по Белой реке Иванаевской воды... до озер Агач и Сургат» крестьянину Ф.М. Устюжанину со сроком на пять лет. Ему разрешалось ловить рыбу, рубить дрова и собирать хмель. Расплачиваться должен был 10 рублями денег, 5 осетрами и 5 белорыбицами ежегодно. Правобережьем реки Белой, напротив села Дюртюли исторически владели султанбековцы. И это не случайно. Ведь когда-то, еще в петровские времена башкир Султанбек Мятиков был единоличным хозяином обширных дюртюлинских земель. И его потомкам переходило это право. Надо сказать, что еще до революции венецианские земли были облюбованы и освоены султанбековцами. Здесь можно было наловить рыбы, заготовить дрова и накосить сена.

Родной брат моего дедушки (1906 г.р.) однажды весной, присматривая за вывезенными на выпас овцами, едва не погиб возле одного из озер. Вода вдруг стремительно стала прибывать. Он и стадо оказались отрезанными от суши. Ему тогда было 11–12 лет. Стало быть, случилось это еще гораздо раньше возникновения деревни, в 1917–18 гг. Об этом мне рассказывала его дочь (1927 г.р.).

В царское время между с. Дюртюли и правым берегом р. Агидель действовала паромная переправа, обеспечивавшая связь между северными населенными пунктами с крупным хлеботорговым селом. Владели им с тех незапамятных времен тоже потомки Султанбека Мятикова.

Чтобы выгоднее продать, на Дюртюлинскую пристань рожь и пшеницу везли отовсюду, и далее на баржах хлеб уходил вниз по Волге.

Моя покойная бабушка, 1910 г.р., очень много рассказывала о деревне: как и кем она основывалась, как тяжела была доля основателей. Эти истории я слушал с детства. По ее словам, первыми перебрались на правый берег р. Белой ранней весной 1921 г. шесть семей. Это мой прадед Сиразетдинов Мифтахетдин. С ним Муфазалов Файзрахман, Бадретдинов Аглетдин, Галяутдинов Нурмухамет, Шарафутдинов Саитгарей и Галяутдинов Салях. Все были крестьяне-середняки. Тептяри. Сначала они перенесли на новое место хозяйственные постройки: амбары, сараи, бани, вывезли скот и птицу, затем перенесли дома. Бежали от войны, голода, продразверстки в надежде на новые земли и хорошие урожаи. Западнее от нового поселения было расчищено поле, где были выделены земельные участки для частного сева ржи и других культур. Рядом с деревней – земля Саитгарея, дальше – Мифтахетдина, Саляха, в самом конце поля, рядом с березовой рощей – земля Нурмухамета и т.д. Такими были рассказы бабушек деревни. Первые годы были богаты на урожаи. Новая земля щедро вознаграждала тружеников сохи и плуга.

А старожил деревни Бадретдинова Сагадат апа – ровесница деревни, где она и родилась, уточняет, что первоначально стояло только три дома: Бадретдинова Аглетдина, Мифтаха Сиразетдинова и Галяутдинова Саляха. Для выделения земли переселенцам в новообразованном поселении появились землемеры – русские. Они отмеряли землю под хозяйства, под посевы, а также территории вокруг леса, луга. Поскольку Бадретдинов Аглетдин мало-помалу мог изъясняться на русском языке, землемеры остановились в его дворе и жили, разбив палатки. В тот год весной было много воды. «Вы живете словно в Венеции», произнес один из землемеров. Так название и закрепилось. Затем и эти русские основались в Венеции. Правда, задержались они недолго, в 1930-х гг. обе семьи покинули деревню.

На основание деревни именно султанбековцами указывал наш соотечественник, почетный краевед Республики Башкортостан, автор книги «На земле Дюртюлинской» Ахсан Салимгареевич Салимов. Его отец Асылгареев (Салимов) Салимгарей тоже мог бы быть в числе тех первых переселенцев, однако его супруга была в положении, и глава семейства не был уверен, что до зимы успеет поставить дом на новом месте. А в декабре 1921 г. в с. Старосултанбеково на свет родился Ахсан Салимов.

О султанбековских корнях д. Венеции упоминал и известный Дюртюлинский краевед, заслуженный педагог Виль Суфиянович Казыханов.

Первое короткое упоминание о д. Венеция мы находим в книге «Память земли», изданной в 1984 г., известного башкирского топонимиста и автора современного гимна Республики Башкортостан Рашида Шакура. В ней указывается, что Венеция образовалась как выселок жителей из д. Старосултанбеково в 1924 г. К 1925 г. в деревне насчитывалось порядка 14–15 хозяйств. Название было дано межрайонным агрономом Сомовым.

В работе известного башкирского историка Анвара Закировича Асфандиярова «Населенные пункты Башкортостана», изданной в 1995 г., Венеция описывается как деревня, образованная в 1920 г. при 19 дворах и 95 жителями. А в последние годы в различных республиканских изданиях все чаще можно встретить статьи об основании деревни в 1920-е гг. русскими семьями из с. Андреевка Илишевского района.

Однако изучая архивные документы, можно выяснить, что в 1920 г. деревни Венеция еще не существовала. Впервые она попадает под запись во Всесоюзной переписи населения в 1926 г. Там действительно значатся 18 дворов и 99 жителей. Вместо 19 дворов и 95 человек в издании А.З. Асфандиярова.

Многие исследователи давно отмечают множество неточностей в работе Асфандиярова, который основывался на обобщенных документах, находящихся в архивах Республики Башкортостан. Ведь издать такой колоссальный труд и не ошибиться было просто невозможно.

Наиболее полную картину о хозяйствах, составах семей дает первая Всесоюзная сельскохозяйственная перепись населения 1920 г. Проходила она в то время, когда на дальних рубежах молодой Российской республики еще полыхала Гражданская война.

В ней также можно узнать об имеющихся орудиях труда, численности скота и птицы, земельных наделах. Кстати сказать, все переселенцы, в том числе и русские из с. Андреевка, значатся тогда еще в своих селениях.

Михаил Игоревич Роднов, доктор исторических наук, сотрудник Уфимского научного центра РАН, много изучавший документы 1920-х гг., в том числе и по Бирскому уезду, в личной переписке отмечал, что особенностью

сельскохозяйственной переписи 1920 г. являлось фиксирование жителей по факту своего существования.

Сегодня в деревне почти в каждом доме вам скажут, что их предки переселились в Венецию в 1921–22 гг. И каждый их предок – выходец из Старосултанбеково. А вот название, видимо, действительно было дано одним из русских переселенцев. Писатель Фатих Хусни прямо указывает на султанбековские корни. Он слышал рассказы аксакалов и интересно описывает жизнь деревни в те годы.

Сегодня в архивах можно найти и похозяйственные книги различных лет, где отмечались составы семей, проживавших в деревне, их хозяйственные постройки, скот, посевы и насаждения.

Что меня особенно привлекло, так это то, что у тех первых переселенцев из Старосултанбеково год возведения домов и других построек четко обозначен 1921 г!

Таким образом, с полной уверенностью можно сказать, что деревня Венеция возникла именно весной 1921 г. и в течение 2–3 лет разрасталась. У первых переселенцев даже дома были однотипные, шестистенные. Поначалу дома располагались по одну сторону, выстроенные в ряд со стороны леса. После, по мере разрастания семей их отпрыски переходили на другую сторону, заводя свои хозяйства и образовывая полноценную улицу.

Основание деревни Венеция старосултанбековцами более закономерно, чем связь с появлением здесь русских. А стало быть, рассказы наших дедушек и бабушек достоверны.

В этом году моя родная деревня отметит свое 100-летие.

В наши дни люди все больше начинают интересоваться своим прошлым. Кто их предок, откуда пошел их род, каким видом деятельности они занимались. Составляют свои родословные. В деревнях проводят праздники шэжэре.

Установить истинную историю своей малой родины мы можем только сами, досконально изучая биографии, сопоставляя документы. И, конечно же, наиболее интересно рассказать о тех временах, поделиться воспоминаниями могут старожилы. Мне посчастливилось поговорить со многими из них. Самой пожилой жительнице деревни – Сагадат апа сегодня 97 лет! Она проживает вдалеке от родных мест, но связи с родиной не теряет. Другие перевалили за отметку 80 и 90 лет.

Их удивительные истории возвращают нас к тем далеким и сложным годам и дают почувствовать весь драматизм эпохи и неистовую энергию людей, которые своим рвением и трудом оставили нам, своим потомкам, наш цветущий край.

## Литература и источники


1. Анвар Асфандияров. Населенные пункты Башкортостана. Кн. 6, Уфа, 1995.
2. Материалы по истории Башкирской АССР. Т. III. М.–Л., 1949.
3. Ахсан Салимов. На земле Дюртюлинской. М.: «Колос», 1994.
4. Фатих Хөсни. Адәм балалары. Казан, 1999.
5. Рашид Шокур. Память земли, Уфа, 1984.
6. ЦГИА РБ. Р–472. Оп. 1. Д. 550.
7. ЦГИА РБ. Р–473. Оп. 1. Д. 760.
8. ЦГИА РБ. Р–473. Оп. 1. Д. 754.
9. АО МР Дюртюлинский район. Ф. 14. Оп. 1. Д. 1.
10. АО МР Дюртюлинский район. Ф. 14. Оп. 2. Д. 14.

*Р.Г. Ярулла*

## АТАУ-ТАЙМЫЙ ТАРИХЫНДА СӘГЪДИЛӘР НӘСЕЛЕ

Мин, элеккеге Уфа губернасы Златоуст өязе, Морзалар волосте, хәзерге Башкортостан Республикасы, Салават районы, Таймый авылы турында кыскача мәгълүмат биреп, һәм шул авылдан чыккан күренекле Сәгъдиләр нәселе турында искә алып китәрмен.

Авылның рәсми исемен бүгенге көндә Таймый дип йөртәләр. Архив материалларыннан күренгәнчә, чын исеме Туймый булып башланган. XX-нче гасыр азакларында тора-бара Таймыйга әйләнеп киткән. Авылның Туймый дигән исеме кыскартып кеше исеменнән алынганын күрәбез. Ул я Туймөхәммәд, я Туйкилде булып һәм башка вариантлары да булуы мөмкин. Күрүебезчә, бу исемнең тамырында *туй* дигән сүз ята. Иске һәм яңа карталарда да бу исемдәге авыл башка очрамый. Авылыбызның халык телендәге исеме Атау булып та йөри. Шул ук вакытта авылны икегә бүлеп аккан кечкенә елганың исеме дә «Атау» дип йөретелә. Атау сүзе туган телебездә утрау дигән мәгънәгә туры килә.

Атау елгасы кечкенә булса да, суы, шарлап, бик шәп ага. Димәк, Атау елгасы бабаларыбызга тегермәннәр кору өчен бик тә җайлы һәм кулайлы дип табылган. Авыл тирә-яклап яссы таулы калын гына катнаш урманнар белән уратып алынган. Мәгълүм булганча, бу төбәк җирләр тәүдә Алтын-Урда, аннан соң Казан ханлыгы, аннан соң Нугай Урдасына караганнар. Авыл кешеләренең чыгышына килгәндә инде, аларның кайлардан килүе әлегә төгәл генә билгеле түгел. Ә шулай да Татарстанның Тау ягыннан килгәннәр, дигән караш яши. Боларны, архив материалларына таянып, ачыклыйсы бар әле. 1720-нче елгы 1нче ревизия материаллары буенча, авылда 7 йорт булып, ирләр саны 32 ир-ат теркәлгән. Хатын-кызларны да шулай ук булган, дип исәпләсәк, 60 тирәсе кеше яшәгән булып чыга. Кызганыч, 2-нче һәм 4-нче ревизия материаллары сакланмаган. 3-нче ревизиядә 1762-нче елга туры килә, 102 ир-ат теркәлгән. Кырыс шартларда яшәгән булуга карамастан, авыл үсә, зурая. Ни сәбәпледер аерылып калган туганнары һәм аерым гаиләләр берникадәр вакыттан соң гына килеп кушылалар. Авылның 1795-нче елгы 5-нче ревизия материалы буенча, ирләр саны 159, хатын-кызлар 145 кеше теркәлгән. Беренче тапкыр муллалардан указлы мулла Гобәйдулла Бохармәт улы күренә.

Халкыбыз дәүләтчелеген югалтса да, үзара элемтәләрне һәм бәйләнешләрне өзмәскә, укымышлылык үзенчәлеген югалтмаска тырышканнар. 1831-нче елдан гына башлап Оренбург Духовный Собраниесе тарафыннан кулланышка кертелгән метрикәдә авылның 2 мәхәлләсе булып, 2 мәчете

эшләп торган. Икенче мәхәллә мулласы имам-хатыйп Искәндәр Салих углы булса, беренче мәхәлләдә 2-нче мәчет хозурында имам-хатыйб вә мөдәррис Сәгъди Мәкъсүд углы дип имза куелган. Халкыбызның мәшһүр галиме тарихчы Ризаэддин Фәхреддин үзенең 4 томлык «Асар» дигән хезмәтендә Сәгъди хәзрәт турында болай язган: «Сәгъди бине Мәкъсүд бине әл-Мөхәммәд бине Исмәгыйл әт-Туйми – Туйми аувылында имам вә мөдәррис булып 1843-нче елда 84 яшендә уафат булган», – һәм артабан болай дип дәвам итә, – Сәгъди хәзрәт йомшак сүзле, мөлаем мәҗлесле, күркәм холыклы, күп гыйбәдәтле, дөрес гыйлемле, вәгъдәсенә тугры, сүзендә рас, кешегә сөйләгән нәсыйхәтләре илә үзе дә гамәл кылучы бер зат иде, диләр».

Сәгъди хәзрәт үз авылы шәкертләрен генә түгел, тирә-як авыллардан да мәдрәсәсендә күпләп шәкертләр укыткан. Сәгъди хәзрәтнең 3 хатынынннан күп уллары булып, шуларның берсен – Ульданны, үзе укыткан мәдрәсәдән соң, чит якларга зуррак остазларга укырга җибәрә. Уфа тирәсендәге «Каршин-Шәриф» дигән мәдрәсәдә, 28 яшендә генә укуын тәмамлап туган авылына кайтып керә һәм атасының уң кулы ярдәмчесе булып китә. Шул ук 1834-нче елда Уфада имтихан тотып, указлы мулла свидетельствосы ала. Атасы Сәгъди хәзрәт вафат булгач имам-хатыйп һәм мөдәррис вазифасын тулысы белән башкара. Ризаэддин Фәхреддиннең китабы «Асар»ның 2-нче томында Ульдан хәзрәт турында мондый юллар бар: «Ульдан бине Сәгъди бине Мәкъсүд бине әл-Мөхәммәд бине Исмәгыйль әт-Туйми. Аның бихисап шәкертләре булыр иде. Зирәк вә тугры зиһенле. Күп гыйлемнәр белән таныш. Бигрәк тә нәхү (грамматика) вә фикъһ фәннәрен яхшы белә иде. Фарсы телендә маһир булып, Җәләлетдин әр-Руминың «Мәснәүи»енә гашыйк булып, даими укый торган иде. Баштарак дәресләрен тырышып, өзлексез укытса да, соңрак авыру сәбәпле хезмәтенә шактый зәгыйфьлек килде, диләр. Ульдан хәзрәтнең уфатыннан соң аның Гайнан исемле фазыйл бер улы калды. Хәзрәтнең 3 хатыны булып, уллары һәм кызлары күп булды». Ульдан хәзрәт озак кына уку сәбәпле соң гына өйләнеп, 67 яшендә мәрхүм булып китеп, балалары ныклап аякка баса алмый калалар. Иң өлкән улы Яруллага (ул минем карт бабам – Р.Я) 23 яшь булса, иң төпчек Гайнанга 17 генә яшь булып кала. Шулай да, Ульдан хәзрәт улы Гайнанга мәгърифәт оеткылыгын салып калдырган. Яшь Гайнан иң башта атасыннан белем алып, аннан соң үз алдына максат куеп укуын дәвам итәргә тырыша. 18 яшендә Сафыйулла кызы Гайнелҗәмалга никахланып, дөнья мәшәкатьләренә уралып китә. Шул хәленә һәм эш күплегенә карамыйча, Гайнан гыйлем юлын дәвам иткән, укуны камилләштерүне туктатмый, хәтта шәкертләргә дәрес тә бирә. Сукасы белән урагы арасында дәрес биреп, шул ук вакытта Оренбург Духовный Собраниегә барып, Уфада имтихан тотып, имам-хатыйп вә мөдәррис дәрәҗәсенә лаек булып, указлы

мулла шәһадәтнамәсе алып кайта. Шәкертләрен укытуны дәвам итә. Тора-бара Гайнан хәзрәт үзенең алган белем тәҗрибәсенә канәгать булмыйча, гаиләсен калдырып, мәдрәсәсен бертуганы Җиһангиргә тапшырып, 1877-нче елда 27 яшендә авылдан чыгып китә. Шәкертләре елашып торып калалар. Урта Азиянең Үргәнеч шәһәрендә бер мәшһүр шәех Котлыхуҗа хозурында белем ала. Берничә елдан остазының киңәше белән гаиләсенә туган авылына әйләнеп кайта. Тынгысыз җан бер урында гына туктап калмыйча, 1882-нче елда Гайнан хәзрәт бу юлы хаҗ сәфәренә чыгып китә. Шул сәфәрендә бер уңайдан Мәдинә шәһәрендә абруйлы шәехләр белән аралашып белемен камилләштерә.

Риза Фәхреддиннең «Асар» хезмәтенең 3-нче, 4-нче томнарында мондый истәлекләр язып калдырган: «Гайнан бине Ульдан бине Сәгъди бине Мәкъсүд бине әл-Мөхәммәд бине Исмәгыйль әт-Туйми,–артабан дәвам итеп болай ди.–Иген кәсебе итү сәбәбендән, соңгы елларда мәгыйшәте яхшы гына киңәйде. Шулай булса да, кием-салым, йөрү-торуда тәкәллефе юк, андый эшләрне сөйми иде. Нотык куәте камил һәм дә үзе гамил (хезмәт иясе–Р.Я) булганлыкдан, вәгазьләре әсәрле буладыр, халыкларны ялкаулыкдан мәнгы итеп, кәсеп эшкә кызыксындыра белә иде. Музыка сөюче булып: «Әгәр дә музыка әдәп вә фазыл әһелләре арасында кабул ителгән булып та, туйганчы шундан истифәдә итсәң иде!»–ди вә бу замандагы тәкъваларның (фанатларның–Р.Я) музыканы бозык вә тыелган эш итеп санауларыннан риза булмыйдыр иде. Соңгы елларында «Тәрҗемән» газетасын укырга башлады. И.Гаспринскийның хезмәтен тәкъдир итәдер вә мәгълүмәте киңлегенә гаҗәпләнәдер иде. Гайнан хәзрәт үз гомерендә базарга чыкмады, гайбәт сөйләмәде, үз-үзен мактамады, сүз ярыштырмады, буш вакытында Коръән укыр иде, диләр. Безгә язган мәктүбләрендә (хатларында–Р.Я ) дә дөньядан шикаяте булмыйдыр, берәү хакында андый-мондый сүз язмыйдыр иде».

Гайнан хәзрәтнең 2 хатыны булып, 1-нче хатыны Гайнелҗамалдан 1880-нче елда беренче улы Гафур туа, 1883-нче елда 2-нче хатыны Сафиядан икенче улы Мөхәммәдһадый туа, 1885-нче елда шул ук хатыныннан Шәйхислам дигән өченче улы туа. 1889-нчы елда Гайнелҗәмалдан дүртенче улы Габдрахман туа. Гайнан хәзрәт ниндидер билгесез чирдән 1902-нче елның 25-нче маенда 52 яшендә кинәт үлеп китә. Мәрхүм хәзрәттән зур гына хуҗалык, алты почмаклы өй, чәчү җирләре, умарталар, мәдрәсәсе, һәм, иң әһәмиятлесе, зур гына китапханә [кала]. Бабаларым сөйләве буенча, бу китапханәдә бихисап кульязма һәм басма китаплар, авылның метрикә кенәгәләре, карталар, «Шура» журналы, «Вакыт» гәзитәләре җыелмалары була. Кызганыч, язмыйча булдыра алмыйм. Шул бай китапханә мирасын, кызыл афәт-раскулачивание елларында Гайнан хәзрәтнең өстә әйтеп кител-

гән Шәйхислам атлы улы, режимга ярарга тырышыпмы, куркуданмы, әллә бераз сәеррәк булуданмы, ат әрҗәсенә төяп, кат-кат йөреп, авыл читенә ташып, демонстративно яндыра. Көне дә җилле генә була. Олы кешеләр, авыл өстендә кәгазьләр китап битләренең күпләп очып йөрүләрен искә алып, кайгырып сөйлиләр иде. Яндыручы гаиләсен, йортын ташлап Урта Азия якларына кача. Бу фаҗига 1936-нчы елларда була. Мәрхүм хәзрәтнең төп йортта яшь хатыны Сафия ике ир баласы белән кала. Ә өлкән хатыны Гайнелҗәмал Гайнан хәзрәтнең анасы Фатыйма абыстай һәм ике ир бала белән авылның икенче очындагы, хәзрәтнең икенче йортында калалар.

Алдагы сүзем татар дөньясындагы зур галим, филолог, олы шәхес Габдрахман Гайнан улы Сәгъди турында барачак. 13 яшьлек яшүсмер Габдрахман атасыннан үрнәкле тәрбия, укуга һәм белемгә омтылу тырышлыгы сыйфатларын алып кала. Профессор Габдрахман Сәгъди үзенең язган автобиографиясендә атасының үзенә карата кырыс булуын яза: «Син сука сукалар өчен яралгансың, бар эшлә, – дип анам белән икебезне урамга куып чыгарды», – дип тә куйган. Ул вакытларда ул шулай язса да, чынлыкта алай булмаган. Коммунистик кызыллык чиренең котырган заманнарында ул шулай язарга мәҗбүр булган. Замандашларының, якын туганнарының истәлекләрендә киң күңелле, заманының алдынгы карашлы зыялы кешесе Гайнан хәзрәттән мондый тупаслык, каты бәгырьлелек, бигрәк тә үз баласына карата була алмаганы күренеп тора.

Булачак галим башлангыч белемне, табигый, иң беренче атасыннан алып кала. Гадәт буенча безнең авылның муллалары Троицк шәһәренең «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем алганнар. Яшь Габдрахман да авылдашлары кебек үк шул мәдрәсәгә укырга керә. Билгеле, атасыз калган үсмер егеткә тәүбашта бик җиңелдән булмаган, әлбәттә. Байларга да яллanып эшләргә туры килгән. Сәләтле яшь егет озакламый үзе дә шәкертләргә дәрес бирә башлый. Беренчедән, шәкертләр арасында абруе күтәрелсә, икенчедән, мөгаллимлек эшендә тәҗрибә туплауның беренче адымнары ясала. Яшьләрнең демократик хәрәкәтеннән дә читтә калмый. Шәкертләр уку программасын, уку алымнарын тамырдан үзгәртүне таләп итәләр.

Мәдрәсәне уңышлы тәмамлаганнан соң, үзенең туган авылы Таймыйда һәм Мәчетле авылларында урыс-татар мәктәпләрендә укыта. Яңалыкка омтылучы, прогрессив карашлы булачак мөгаллимнең уку-укыту эшләренә тәрбия чараларына «җәдитче»ләрчә якын килүенә башлангыч адымнар шунда салына, диярге була. Аның мәктәптә җәдитчә укыта башлавы, ана теле һәм әдәбияты дәресләрен балаларны кызыксындырырлык дәрәҗәдә, әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләрлек итеп алып баруын, нәтиҗәле эшләвен раслаучы фактлар бар. Мәсәлән, «Вакыт» гәзитендә түбәндәге хәбәр басыла: «Златоуст өязе Атау-Таймый авылында мөгал-

лим Габдрахман Сәгъди әфәнденең карамагында булган мәктәп бу санә бик гүзәл сурәттә дәвам итеп, имтихан мәҗлесләре гомүмнең тәхсиненә (мактап яхшы дип әйтү – Р.Я.) мөзаһир булмышдыр. Мөгаллим Сәгъди әфәнденең гүзәл нәмүнәлеге (үрнәклеге – Р.Я.) исә уку эшенең таралуына, уңышына сәбәп булса кирәк» (Вакыт, 1906, апр. №455). Үз чорының алдынгы идеяләрен туплаган яшь мөгаллим милли мәдәният һәм фәнгә хезмәт итәргә омтыла. Заман таләбе, урыс телен, әдәбиятын яхшы белергә кирәклеген аңлап, яшь кеше югары урыс мәктәбенә керүне максат итеп куя. Урыс булмаган милләт балаларына югары уку йорты мәктәпләренең ишекләре бик тар булуы сәбәпле, укырга керү хыялы насыйп булмый. Артабан атасыннан калган мирасның үзенә тигән өлешен сатып, укуга, белем алуга дәрте ташып торган егет, Төркиягә Истамбул шәһәренә юл ала. 1911-нче елда Югары Төрек университеты филология факультетының «төрки-татар әдәбиятлары тарихы» белгечлеге буенча югары филологик белем алып, уку йортын уңышлы тәмамлап, туган яклары Златоуст өязе авылларында 6 еллык урыс-татар мәктәпләрендә укыта башлый. Аннан Актүбә, Алма-Ата, Ыргыз мәктәпләрендә укытучы да, җитәкче дә булып эшли. Укыту эшләре белән беррәттән гыйльми эшләрен дә башлый. Аның татар теле грамматикасы, әдәбият теориясе, гомуми педагогика, педагогика дәресләре, татарча аерым китаплар булып басылып чыга.

Актүбәдә укыткан чорында аның укучылары арасында шагыйрь Кави Нәҗми дә була. Булачак шагыйрь беренче тәҗрибәләрен ана теле укытучысы Габдрахман абзыйга күрсәтеп, иҗат эшенә фатихасын ала. К.Нәҗми истәлекләрендә остазына зур ихтирам хисе сизелә. Патша хөкүмәте демократик каршылыкларны күзәтүдә тоту шартларында, шәкертләр хәрәкәтендә актив катнашкан прогрессив карашлы Г.Сәгъдинең укытучылык эше дә тыныч кына бармый. 1913-нче елдан башлап сәяси күзәтү астында яши ул. 1914-нче елда Алма-Ата жандарм идарәсе тарафыннан аны укыту эшчәнлеге алып барудан һәм мәктәп җитәкчесе булып эшләүдән тыялар. Ә апрельдә 24 сәгать эчендә Урта Азия җирлегеннән эчке Россиягә куыла. Бу турыда Оренбургта нәшер ителгән «Мөгаллим» журналында һәм «Вакыт» газеталарында игълан бирелә [Вакыт: 1914, 15 апр. №1461]. Моннан соң үз теләге белән Екатеринбургка килә. Монда ел ярым яшәгән чорында милли мәктәпләр һәм милли мәдәни хәрәкәтнең башында торган иске фикерле кадимче интеллигенция һәм реакцион карашлы дин башлыкларына каршы көрәш алып бара. Ләкин шул гамәлләре өчен эзәрлекләнеп, Екатеринбургны ташлап китәргә мәҗбүр була. Аннан Ыргыз якларында 1915–16-нчы елларда бераз укытып, үзенең туган авылына Атау-Таймыйга кайта, 1916–17-нче елларда туган авылында балалар укыта. Бу вакытта авылга укытырга килгән яшь мөгаллим Нәкый Исәнбәт белән якыннан таныша. Күп

тә үтми авылга тагын ике яшь кеше килеп өстәлә. Берсе–мөгаллим Галим Әхтәриев, икенчесе–бик оста скрипкада уйнаучы Насыйр Әхтәриев. Янәшә генә авыл Өлкендедән 15 яшьлек булачак шагыйрь Әхмәт Ерикәй бик еш килеп йөри. Яшьләр, бер-берсе белән дуслашып китеп, авылның калган яшьләре белән шау-гөр килеп көн дә диярлек әдәби кичәләр үткәрәләр, спектакльләр, концертлар куялар, үзләре–драматург, артист, үзләре–рәссам-декоратор. Шуларның уртасында–җитәкчеләре билгеле Габдрахман Сәгъди. Көннәрдән беркөнне, бу яшьләр төркеме ераграк авылларга спектакль куярга чыгып киткән генә вакытны чамалап, караңгы бәндәләр боларның бөтен булган спектакль декорацияләрен йортка ташып өеп яндыралар. Бу хәл курку гына түгел, яшьләрне, киресенчә, котыртып кына җибәрә [Сәгыйтҗан Сәгъди көндәлекләреннән–Р.Я.].

Г. Сәгъди Февраль революциясе чорында Златоуст өязе морзалар волостенда ревком рәисе булып та эшләп ала. Шул ук елның җәендә 3 айлык татар-башкорт педагогия курсларында татар теле һәм әдәбиятыннан дәресләр алып бару өчен Бөгелмәгә чакырыла.

Илдәге иҗтимагый-сәяси вазгыять, яшь төрекчеләр идеясен (тигезлек, туганлык, азатлык) булачак галимне зур эшләргә рухландыра. Ул Төрек дәүләтендәге милли үзаң һәм әдәби гыйлем үсешен, уку-укыту системасындагы үзгәрешләрне Татар җирлегендә булдыру өмете белән яна. Милли мәгарифне теләгәнчә яңартуга реформаларны киң җәелдерергә, иске фикерле интеллигенциягә каршы көрәшү аша гына ирешү мөмкин түгеллеген аңлаган Г. Сәгъди гыйлми эзләнүләрен башлап җибәрә. Тел-әдәбият укытуда яңа агымның башка баскычлары өчен дә дәреслекләр яза башлый. 1913-нче елда «Телебезнең сарыфы» (морфология) китабын тәкъдим итә. Дәреслекнең кереш өлешенә язылган «Балаларга эндәш сүз»дән дә галимнең туган телгә, тел гыйлеменә мөнәсәбәтен күрергә мөмкин: «...Газиз балалар! Сезнең өчен һәм барыбыз өчен дә иң зур бәхет–үзебезнең милли туган телебезне укуда, шуңа бик нык ябышуда, шуны чын күңелебез белән сөюдә генә икәне күңелләребезгә һич бервакытта да онытылмаслык итеп урынлаштырыйк та, йәгез, Аллага тапшырып, дәресебезне башлыйк, сөекле туган телебезнең сарыфын укуга тотыныйк» [Сәгъди: 1913. 5 б.]. Шулай итеп, Бөгелмә чоры Г. Сәгъдине тагын бер баскычка югары күтәрә. Ул инде укытучылар әзерләү белән шөгыльләнә башлый. Төп игътибарны педагогика, дидактика һәм методика мәсьәләләренә юнәлтә. Бу чор аны Казанга якынайта. Хезмәтләре Казанда басыла башлый. Шулай да Октябрь инкыйлабы белән зур үзгәрешләр юлына чыккан дәвер аның өчен катлаулы, каршылыклы була.

1921-нче елның көзендә Төркестан республикасының мәгариф халык комиссариаты аны Ташкентка укытучылык эшенә чакырып ала. Монда

ул хәрби мәктәптә үзбәк классик әдәбиятыннан һәм Төрки-татар мәгариф институтында татар әдәбиятеы, педагогика тел һәм әдәбият укыту методикаларыннан лекцияләр укый.

1925-нче елда Татарстан халык комиссариаты Г. Ибраһимов инициативасы белән, Г. Сәгъдине Казанга чакырта. Галимнең тормыш һәм иҗат юлында Казан чоры (1925–1930 )–гыйльми эшчәнлегенең иң продуктив өлешләренең берсе. Казанда эшләгән чорында Г. Сәгъди 30лап фәнни хезмәт яза. Алар арасында иң зурлары–«Татар әдәбияты тарихы» (1926); «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» (1926); «Галимҗан Ибраһимов һәм аның иҗатлары» (1928); «Пролетар диктатура дәверендә татар әдәбияты» (1928); «Символизм турында» (1930). Кешелек дөньясында борынгы заманнарның мәдәни байлыкларын соңгы заманнарга күчереп баруда Г. Сәгъди телне иң кирәкле, иң кыйммәтле чара дип саный. Ул язуны җәмгыятьтә фикернең үзгәрешенә, үсешенә киң юл ачты, дип билгели. Тел һәм әдәбият тарихында VI һәм IX гасырларда иҗат ителгән, рун язуында бирелгән борынгы төрки язма истәлекләргә игътибар итүче һәм беренче мәртәбә аны фәнни әйләнешкә кертүче дә Г. Сәгъди була.

1929-нчы елда Г. Сәгъдине Көнчыгыш педагогия институтына әдәбият методикасыннан профессор итеп сайлыйлар. Шул уңайдан «Кызыл Татарстан» гәзитендә аның хакында биографик язма басыла. Ләкин Г. Сәгъдинең эшчәнлегенә аяк чалырга теләүчеләр дә табыла: «Яңа авыл», «Эшче» гәзитләрендә аның турында җәмәгать фикерен чуалтырлык язмалар чыга. Аларда галимнең революциягә тиклем булган эшчәнлегенә, дөнья күргән хезмәтләрендә дини-милли идеология чагылуын әйтеп, аны коммунистик идеологиядән читләшүдә гаеплиләр. Күренә ки, 1920-нче еллар азагында аның исеме тирәсендә йөргән шикле фикерләр күбәя. Әдәбият галименә мондый мөнәсәбәтне шул еллар әдәби-гыйльми мохитендәге каршылыклы хәрәкәтләр белән аңлатырга мөмкин. Бу вакытта аның якын фикердәше Г. Ибраһимов та Кырымга бик озакка дәваланырга китеп бара. Бу мохиттә бүлгәләнүләр, капма-каршылыклар, әдәбият галимнәре бер-берсен каралта башлыйлар. Мондый катлаулы мохиттә, туктаусыз күзәтүләр астында, һәрдаим ихласлыгыңны, хаклыгыңны исбат итеп яшәү зыялы галимдә канәгатьсезлек хисе уята. Галим үзе дә яхшы тоемлаган эшләрнең кая таба баруын һәм 1930-нчы елның башында ул кабаттан Урта Азиягә юл ала, һәм гомеренең ахырына кадәр үзбәк әдәбияты фәнен үстерүгә хезмәт итә.

Шулай итеп, Г. Сәгъди рәттән берничә югары уку йортларында лекцияләр укый башлый. 1937-нче елның азакларында Казан чорында ук башлаган эшен, Көнчыгыш Ренессансының күренекле вәкиле А. Нәваи иҗатын өйрәнүен дәвам итә, шуның буенча фәнни докладлар ясый. Нәваи фәненең

зур ачышларында нәтиҗәле үсүендә Г. Сәгъдинең өлеше бәяләп бетергесез. Галим Г. Сәгъдинең бу юлдагы иң зур хезмәте – өч томлык тәшкил иткән докторлык диссертациясен ул – «Үзбәк классик әдәбияты үсешендә югары этап буларак Нәваи иҗаты». Бу диссертациясен 1949-нчы елда Мәскәүдәге Шәрык институтының Гыйльми Совет утырышында яклый һәм аңа филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә бирелә.

Г. Сәгъдинең көчле йогынтысында булган аның укучысы, үзбәк галиме Р. Мөкимов болай ди: «...Урта буйлы, кара коңгырт чәчле һәм күзлекле урта яшьләрдәге бер татарның безне укытуына әллә ни хәйран калмаган идек. Хәйран калдырганы шул – татар милләтеннән булган бу укытучының саф үзбәк телендә үзбәк әдәбияты тарихын укыту гына түгел, ә Шәрыкнең шушы төбәгендә яшәүче күп кенә халыкларның әдәбият вә мәдәният тарихын су кебек эчүе иде. Безне укытканда ул якын тарих белән чикләнмәде, Ибн Халдун, борынгы грек фәйләсуфлары, Әфләтун, Сократ фикерләре белән таныштырыр иде. Әбугалисинә, Фәраби, Бируни, Җами, Нәваи, Заһретдин һәм Бабур язып калдырганнар белән безне кызыксындырды».

1952-нче елның октябренә кадәр ул үзбәк әдәбияты профессоры булып эшли, яшь фәнни кадрлар үстерүгә, аспирантлар әзерләүгә күп хезмәт куя. 1954-нче елның көзендә Г. Сәгъди Казанга килеп китә. Шул вакытта «Совет әдәбияты» журналында «Татар халкының үсешендә Каюм Насыйриның роле» дигән мәкаләсе басылып чыга. Бу галимнең татар телендә басылган соңгы язмасы һәм профессорның Казан белән хушлашуы булып чыга.

Атаклы галим 1956-нчы елның 6-нчы ноябрендә 67 яшендә каты авырудан вафат була.

Г. Сәгъди – филология белгечлеге буенча татарлардан беренче профессор һәм беренче фән докторы дәрәҗәсенә ирешкән шәхес.

**Әдәбият:**

1. Вакыт. 1914, 15 апр. № 1461.
2. Габдрахман Сәгъди: Фәнни-биографик җыентык. Төзүчеләр Д. Заһидуллина, Ч. Гыйләҗева. Казан: «Җыен», 2008. – 416 б.
3. Ризаэддин Фәхреддин. Асар. Т. 1, 2, 3, 4. Казан: «Рухият», 2009–2010.
4. Ревизские сказки дер. Туймеевой 1720, 1762, 1782, 1811, 1816, 1834, 1850, 1859 гг. ЦГА РБ. Ф. 138; РГАДА. Ф. 350. Оп. 2.
5. Туймый-Атау авылының метрикә кенәгәләре: 1831–1923 ел // ЦГАБ. Ф. 295. Оп. 1-9-16.
6. Г.Г. Сәгъди. Беренче сыйныф шәкертләре өчен дәрес китабы. Казан: «Өмет», 1913.

***Ф.Г.Дашкин***

# ДАШКИННАР ТАРИХЫ

Үз халкының тарихын, гореф-гадәтләрен тирәнтен өйрәнгән кеше генә үзе туган ягының, иленең чын патриоты була ала. Халык мәкале дә «Үз халкының үткәннәрен белмәгән халыкның киләчәге юк», ди. Ә тарихка мәхәббәт тәү чиратта гаиләдән киләдер. Мәктәптә тарих дәресләрендә без борынгы Мисыр халкы, Грек аллалары һәм әллә кайдагы геройлар-каһарманнар турында укыдык.

Ә кан тамырларыбызда бер үк кан, бер үк һава сулаган, бер үк чишмә суларын эчкән, бер үк сукмактан йөргән шәхесләребез турында белмәдек, дисәк тә дөрес булыр. Чынлыкта исә Башкортостанның Фёдоровка районында урнашкан Югары Явыш авылыннан чыккан шәхесләр үзебезнең Башкортостан тарихында гына түгел, ә күрше тугандаш Татарстан тарихында да, ил тарихында да тирән эз калдырган шәхесләр булганнар. Әйе, безгә ата-бабаларыбыз тирән тамыр, бай тарих калдырган. Менә инде 400 елдан артык Дашкиннар нәселе туган иленә тугры хезмәт итә. Нәсел тамыры кенәз Беханнан башланса да (Акчуриннар, Кудашевлар һәм башка татар дөньясында билгеле фамилияләргә нигез салучы), мин үземнең язманы Дашкиннар фамилиясенә нигез салучы Дәшкәдән башлыйм. Тарих битләреннән белүемчә, 1611 елда илдә барган чолганыш вакытында Дәшкә бабай Пожарский һәм Минин белән бергә Мәскәүне поляклардан азат итүдә катнаша һәм яуда һәлак була. Аның урынына, ул вакыттагы тәртип буенча, аның өч малаеның (Сүнчәләй, Ишмакай, Алмакай) олысы – 15 яшьлек Сүнчәләй баса. Ул Дмитрий Пожарский кулыннан кенәз титулына ия дигән таныклык ала һәм дә соңрак ул титулга калган ике энесе дә лаек була.

Пётр I патшалык иткән чорда Ишмакай Дашкинның оныгы Бүркәй майор чинында хезмәттә була. 1713 елның 13 ноябрендә татар морзаларын ярты ел эчендә чукындырып бетерү, чукынмаган очракта аларның җирләрен крестьяннары белән тартып алу, һәм дә югары хәрби чиннарда булмаска тиеш дигән фәрманы чыга. Әлбәттә, бу фәрман чукынырга теләмәгән морзаларга зур зыян сала. Бүркәй Дашкин да, үз дәрәҗәсен югалтудан куркыптыр инде, Юрий исеме белән христиан динен кабул итә һәм Клинда воевода булып кала. Тик Бүркәйнең кече улы Бахтый гына үз динен саклап кала. Бу чорда татарларның кайберләре инде христиан динен кабул итеп, үзләренең гореф-гадәтләрен, телләрен югалтып, руслашып бетә. Шуңа күрә бүгенге көнне Дашкин фамилиясен йөртүчеләр арасында, тамырларында татар каны акса да, рус милләтеннән булучылар

бар. Шуларның берсе – бүгенге көнне Мәскәүдә Генеральный штаб академиясендә белем бирүче генерал-полковник Юрий Алексеевич Дашкин (1959 елгы).

XVIII гасырның икенче яртысында, әби патша рөхсәте белән, татарлар Ырымбур һәм Уфа өязенә күченә башлый. 1775 елны Бахтый улы Йосып Дашкин да үзенең уллары Мортаза, Мостафа, Гомәр, Ибраһим, Абдрәзәк һәм абыйсы Якупның улы Заит белән Ырымбур өязенә күченә.

Әлеге Фёдоровка районына беренчеләрдән булып бер төркем татарлар: Гөбәйдулла Морозов, Асиян Акбулатов, Надирша Акчурин, Заит Дашкин килеп, Бөркетле елгасы Ашкадарга койган урында урнашкан Казбулат авылында яшәгән Карабай Китеев дигән башкорттан җир сатып алалар (алар төзегән килешүнең миндә күчермәсе бар). Әлеге килешүнең ул вакытта да шулкадәр төгәл, дөрес итеп төзелүенә хәйран калырлык. Соңрак, Явыш авылына нигез салынганнан соң, Заит Дашкин да Явышка күченә. Мин тәүдә аның тамырларына игътибар итмәгән идем, эзләнүләрдән соң ул минем әни ягыннан бабайның әтисенең бабасы булып чыкты (миңа 6-нчы буын бабай).

Ә инде Явыш авылына нигез салучы Вәлиша улы Нәрбик Дашкин (ул Дәшкә бабайның олы улы Сүнчәләй тармагы) исәпләнә. Ул 1785 елны җир сатып алганмы, әллә шул ук елны авылга нигез салынганмы, анысы төгәл генә билгесез. Әмма Явыш Муллашевтан (йөзбашчы) җир сатып алынган һәм авыл аның исемен йөртә.

Архив материалларында авыл Старое Яушево дип күрсәтелсә, бүгенге көнне ул татарча Югары Явыш, башкортча Үрге Яуш, халык телендә кенәз Явышы дип тә йөртелә. Балыклинка елгасыннан түбәнрәк 3 чакрым чамасы Түбәнге (халык телендә Өяләмә) Явыш та бар иде, анда башкортлар яши иде, үткән гасырның 60-нчы елларында ул перспективасызлар исеменә кереп, таралды, күбесе безнең авылга күченсә, кайберләре Бала-Чытырман авылына күченә. Бүгенге көнне алар, безнең халык белән аралашып, татарлашып беткәннәр. Бала-Чытырман авылыннан ерак түгел Ашкадар елгасы буенда башкорт авылы Яңа Явыш та бар, алар инде Түбәнге Явыштан элегрәк бүленеп чыккан халык.

Нәрбик Дашкин (1761–1824) үзенең ике малае Халит (1782–1824) һәм Абдулхәмит белән 1796 елны (ул инде Явышта туган булса кирәк) төпләнеп кала, аның ике туганы – Токтар, Ханбәк Бүздәк ягына күченеп китәләр. Аларның балалары бүгенге көндә Башкортостанның Бүздәк районы Бүздәктә, Шланлыкүл, Кушнарен районы Мәүлет, Чакмагыш районы Яңа Балак авылларында яшиләр. Республикабызда татар телендә чыккан «Кызыл таң» гәзитендә 1967–1986 елларда баш мөхәррир вазифа-

сын башкарган тарих фәннәре кандидаты, Башкортостанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1993) Ремель Миргазиян улы Дашкин (1928–2001) тумышы белән Бакай авылыннан. Аларның тамырлары Дашкинның кече улы Алмакайдан башлана.

Кемнәр соң ул бүген авылыбызга нигез салучы Нәрбек Дашкинның нәсел дәвамчылары, дигән сорау туа. Чөнки авылда яшәгән Дашкиннарның берсенең дә тамыр җепләре аңа барып тоташмый. Бу сораугa без җавапны «Ревизские сказки» битләрен тикшергәндә таптык.

Нәрбикнең улы Халитның балалары – Вәлит (1807–1828), Мохтар (1813–1846), Дилмөхәммәт (1817), Зюмзюма (1821), Абдулгаллэм (1825) Халитов фамилиясе белән язылганнар һәм алар бүген авылда яшиләр. Ә икенче улы Абдулхәмит Нарбеков булып киткән. Нарбековлар инде авылда калмадылар, дисәң дә була, чөнки Явышта туган Нарбековларның соңгысы Рәшит улы Радик (1975 елгы) Салават шәһәрендә яши, бер гаилә районыбызның Өчбүләк авылында Сәгыйдулла бабай улы Гобәйдулла абый яши. Аның да малайлары – Гали, Вәли, Флүр Мәләвез шәһәрендә яшиләр.

Нарбековларның бер төркеме Күгәрчен районы Калдар авылында яши. Калдарда элегрәк башкортлар, ә Нарбековлар Явыш дигән авылда яшәгән булганнар. Ике авыл бергә кушылгач, авыл исеме Калдар калган, ә анда аккан елганың исеме Явыш булып калган. Бу версия әле безнең яктан өйрәнелмәгән. Күптән түгел генә минем кулыма килеп эләккән, авторлары Сәгыйтдинов М.Ш., Сафин М.Х. булган «Родовые корни айдаралинцев» китабында (Айдарале авылы безнең күрше Стәрлебаш районында урнашкан) болай дип язылган:

«В 1873 году, после окончания Стерлибашевского медресе, в Айдаралино заселился как представитель духовенства, иными словами указным муллой, Габдулкулуй Бикмухаметов (1840–1909) из деревни Яушево Стерлитамакского уезда. Он был потомком мурзы Нарбека князя Дашкина (Нарбек – Абдулхамит – Бикмухамет – Габдулкулуй). Позже его сыновья тоже пошли по стопам отца: Махмут стал указным муллой в Айдаралино. Мухаммет – азанчеем в Ново-Айдаралино. В древо рода мурзы Нарбека включены 115 человек и они сегодня носят фамилию Абдуллины и Кулуевы, Мухаметовы.

Абдуллин Зариф Махмутович (1916–2007), участник ВОВ, лейтенант, проработал учителем в Айдаралинской школе, награжден орденами и медалями. Другой сын Махмута муллы Кулуев Анвар Махмутович (1927) был бессменным главным экономистом колхоза «Ключевые горы». Им организован в Айдаралях историко-краеведческий музей». Алла бирсә, исән булсак, җәйгә ул музейны барып күрәсе бар.

Архив документларында болай дип язылган: «Мурза Юсуп Бахтиев сын князь Дашкин в 1749 и 1750-м годах по выбору находился в Шацкой провинциальной канцелярии у приему денежной казны родных городов с мурз и татар и именно: по Шацку, Касимову, Кадому, Темникову, Инзорь, Керенску и Верхнеломовску, порядочно начетов и нареканий не имел, а с 773 по 777 год находился трех жительствах по выбору и Аксельскому стану сотником...»

1782 елгы 4 ревизиядә Бәхти улы гаиләсе һәм дә бертуган абыйсы Якупның улы Заит Ырымбур өязе Чесноковка авылында, дип язылган. 1791 елның 3 декабрендә Сенатның 4440 номеры әмере белән Рәсәйдә мөселманнардан беренчеләрдән булып Йосып Дашкин дворяннар катламына киредән торгызыла.

1797 елда Йосып Бәхти улы 5 малае Мортаза, Мостафа, Умәр (Гомәр), Ибраһим, Әбдрәзәк Стәрлетамак өязе Явыш авылында төпләнәләр. Алар тыныч хезмәт белән бергә хәрби хезмәтләрен дә дәвам итәләр. Кайберләре хәрби хезмәттә зур казанышларга да ирешә.

Мортаза улы Әхтәм Дашкин 1779 елда туган, 1807–14 елгы рус-төрек сугышында катнаша. Ватан сугышында катнашып, 1813–14 елларда Алман шәһәре Гамбургны азат итүдә катнаша. Майор чинына кадәр күтәрелә, мөселманнарга ул вакытта рус армиясендә, майордан югарырак чин бирелмәгән.

Ильяс улы Идрис Дашкин, 1835 елның 10 октябрендә туган. Хәрби хезмәтен 1856 елның 30 мартында башлый. 1867 елның 26 июнендә Ходжент шәһәрен алганда күрсәткән батырлыгы өчен Изге Анна орденының 4-нче дәрәҗәсе белән бүләкләнә. 1870 елның 6 июлендә Бохара эмиратының Кармин шәһәрен яулаганда күрсәткән батырлыгы өчен Изге Станислав орденының өченче дәрәҗәсе белән бүләкләнә. 1870 елның 11 августында аңа поручик чины, ә 1879 елның 7 мартында штабс-капитан чины бирелә. Отставкага чыккач, туган авылы Явышта яши, тау башында аның өенең торган урыны билгеле.

1908 елның 17 июлендә мәрхүм була, кабере ташлар белән уратылып алынган, әле дә саклана. Кабер ташына: «Аллаһтан башка илаһи юк, Мөхәммәт аның пәйгамбәре. Капитан Ильяс улы Идрис Дашкин 1908 елны үлде», – дип язылган.

Алда искә алынган майор Әхтәмнең оныгы Саит Гөфер улы Шәңгәрәй 1824 елда Оренбург өязе Нижнеозерский станицасында дөньяга килә. 1861 елда инде ул кече офицер дәрәҗәсендә хезмәттә була. 1869 елның 12 июлендә ул йөзбашчы дәрәҗәсендә була. Изге Станислав өченче дәрәҗәле ордены белән бүләкләнгән була. 1872 елның 26 февралендә император Александр II-нченең фәрманында болай дип әйтелә: «Нашему

сотнику 3 пешего батальона Оренбургского казачьего войска Шангирею Саит Ягоферову Дашкину. В воздаяние отлично-усердный и ревностной службы Вашей Начальством засвидетельствованной.

Всемилостивейше пожаловали Мы вас, Указом, в 26 день февраля 1872 года Капитулу данным, Кавалером Императорского и Царского Ордена Нашего Светлой Анной третьей степени...». Дүрт елдан соң, 1976 елның 13 августында ул есаул чинында ялга чыга.

1861 елның 22 июнендә аның Зөлкарнаин исемле улы дөньяга килә. Ул да, әтисе юлыннан китеп, 1876 елны хезмәт юлын писарь булып башлый. 1877 елның сентябрендә уңышлы имтиханнар биреп, Ырымбур юнкерлар училищесына укырга керә. 1878 елның августында, яхшы укыганы өчен, урядник чины бирелә. 1880 елның июлендә училищены уңышлы тәмамлап, портупей-юнкер чинында 5 Ырымбур-Казан полкында (полк Орск шәһәрендә була), хезмәтен дәвам итә. 1881 елда инде хорунжей чинына лаек була. 1889 елда ул хезмәтен йөзбашчы булып Ташкент шәһәрендә дәвам итә. 1896 елда ул үзенең беренче бүләгенә – көмеш медальга лаек була. 1904 елда офицерлар курсын «биш»легә генә тәмамлап, хезмәтен Төркестан округында дәвам итә. 1907 елда ул войсковой-старшина чинында 2-нче Урал-Казан полкының командиры була. 1915 елның 19 декабрендә аңа полковник чины бирелә. Беренче Бөтендөнья сугышында танылган генерал Брусилов кул астында 14-нче Ырымбур-Казан полкы белән җитәкчелек итә.

Хезмәт иткән чорда ул бик күп бүләкләргә лаек була. Бохара Әмиренең ике алтын йолдызы, Изге Станиславның II, III дәрәҗәле орденнары, Изге Аннаның II, III дәрәҗәле орденнары, Изге Владимирның IV дәрәҗәле ордены, Романовлар династиясенең 300 еллыгы уңаеннан бакыр юбилей медале, исемле нагany, Зодар фабрикасының аучылар мылтыгы, атта чабышу, ату буенча оештырылган ярышларда җиңгәне өчен кылычына 31 мәртәбә алтын хәрефләр белән языла. 1917 елны аңа генерал-майор чины бирелә. Шул елны революция башлангач, тәҗрибәле генерал революциянең нинди аяныч хәл икәнен аңлап, «революция сәятчеләр эше – хәрбиләрнеке түгел», ди. Гражданнар сугышында катнашасы килми, әмма революция давылы аның ихтыярына карамыйча үз эченә суырып ала. Һәм ул атаман Дутов белән китәргә мәҗбүр була. Соңгы тапкыр аны 1921 елны Сәмәрканд шәһәрендә күрәләр. Аннан соң эзе югала. Имеш, аны кызыллар Арал диңгезендә пароходта барганда кулга алып, муенына таш бәйләп диңгезгә ыргытканнар, дигән хәбәр дә ишетелде. Аның дөресме, түгелме икәнен хәзер бер Ходай гына белә.

Без Зөлкарнаин Дашкинның I Бөтендөнья сугышында катнашуын әйтеп киттек. Бу сугышта һәм дә Гражданнар сугышында катнашучылар

тарихта ак нокта булып тора. Ә алар да бит Ватаныбызны саклыйбыз дип кан койганнар, алар да бит безнең бабаларыбыз. Аларны оныту безнең тарафтан дөрес булмас. Явыш авылыныкыларның бу сугышта катнашканнарның исемлеге «За честь и Родину свою» дигән җыентыкта басылган. Китапның җаваплы сәркатибе А.Г. Терегулов, төзүчесе М.У. Сюндюков. Бу китапка минем дә, Р.Р. Дашкинның мәкаләләре кергән.

1917 елга караган мобилизация буенча сугышка Явыш авылыннан 19 яшьтән алып 42 яшькә кадәр 75 кеше алынган. Шуларның 58е – Дашкиннар, Халитовлар (5), Нарбековлар (3), Якуповлар (4), Мостафин (1), Чанышев (1), Йосыповлар (3). Алтысының фотографияләре дә куелган, тагын алтысының фотографиясен тапкан идем, басмага өлгермәде. Үземдәге китапка кушымта итеп өстәп куйдым.

Исемлектә минем Зиннур бабайның энесе Кәлимулла да бар. Ул сугыштан исән-сау әйләнеп кайткан. 1945 елны гына мәрхүм булган. Күрсәткән батырлыгы өчен IV һәм III Георгий тәресе белән бүләкләнгән.

Аның оныгы Ринат (аңа ул вакытта 5–6 яшь булса, мин аңардан 9 айга зуррак), әбисенең сандыгыннан кульъяулыкка төргән ике медальны тартып чыгарды. Ул вакытта без аның нәрсә икәнен аңламыйча, немец тәресе диеп җиргә казып, «немецларны җиңдек», дип тапап-тапап[1] күмеп куйдык. Күмдек, оныттык. Күрәсең, аны сораучы да булмаган инде. Үзебез олыгайгач кына искә төшердек, тик төгәл генә урынын да белмибез. Бәлки ул инде бакча сөргәндә эләккәндер, я булмаса язгы сулар югандыр, кем белә, бәлки урынында да ятадыр. Менә шундый «батырлык» эшләдек без.

Әлеге авылдан Гражданнар сугышында 5 кешенең катнашканы билгеле. Терентьев Егор һәм Юсупов Төхфәт аклар ягында сугышкан. Әлеге Ишембай районында бер авыл янындагы урманда кызыллар белән атышканда һәлак булганнар. Урындагы халык аларны шунда җирләгән.

Акчурин Гыйрфан Усман улы һәм Халитов Фәйзрахман Абдулла улы кызыллар ягында сугышканда һәлак булган, ә Дашкин Габделсабир Габдҗәлил улы, Дашкин Хәсән Фәсхетдин улы исән-сау туган якларына әйләнеп кайткан.

***Дашкин Фәрит Шәкүр улы***

1934 елның 1 августында Башкортостанның Фёдоровка районы Югары Явыш авылында Шәкүр Закир улы һәм Зөһрә Кәһәрмән кызы Дашкиннар гаиләсендә дөньяга килә. Гаилә гади крестьян тормышы белән яшәсә дә, Шәкүр һәм Зөһрәнең туу турындагы таныклыгында дворяннар нәселеннән, дип язылган. Ә бит Шәкүр бабайның тамырлары ша-

[1] Тапап-тапап – таптый-таптый.

гыйрь Дәрдемәнднең әнисе Хәнифәнең бертуган абыйсы Хөснетдингә барып тоташса: Шәкүр–Закир–Мирхәйдәр–Хөснетдин, Зөһрә әбинең тамырлары Хәнифә әбинең бертуган энесе Әбүбәкергә барып тоташа: Зөһрә–Каһәрмән–Әбүбәкер.

Гаиләдә тагын берничә кыз һәм малай туа, ләкин энеләре Хәмит (1937 елгы) һәм Рәшит (1941 елгы) гына исән кала. Фәриткә 8 яшь тулгач, әтисен фронтка алалар һәм ул Ленинград янында барган яуда һәлак була.

Өйдәге ир-ат эше, өйне җылытыр өчен урманнан чыбык-чабык алып кайту, өйдәге малны карау, колхоз эшеннән арып кайткан әнисенә һәм ике энесенә ашарга пешерү, аларны карау аның җилкәсенә төшә. Укуга омтылган малай, дөнья авырлыкларына кармастан, авылдагы китапханәдәге барлык китапларны укып чыга. Авылдагы дүртьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, укытучысы Дашкина Хәнифә Нәҗметдин кызы (ул минем әнием була) киңәше буенча, 7 чакрымны көн дә җәяү йөреп, район үзәге Фёдоровкада 8-нче классны тик «5»ле билгеләренә генә укып, «Мактау кәгазе» белән тәмамлый. 1952 елны Октябрьский каласындагы нефтьчеләр көллиятенә укырга керә. Ерак Көнчыгышта армия сафларында бурычын үтәгәннән соң, көллиятне уңышлы тәмамлый. Аңа Мәскәү өлкәсендәге Щелково шәһәренә эшкә юллама бирәләр. Бөтен гомере газ өлкәсе белән бәйле була. Бурильщик ярдәмчесеннән башлап «Союзбургаз»ның генераль директоры дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Ул Европада иң зур газ саклагычын ясауда катнаша һәм андагы хезмәте өчен «Почёт билгесе» ордены белән бүләкләнә. Аңа «Газ промышленностеның атказанган эшчесе» исеме бирелә һәм ул тагын күп кенә башка төрле бүләкләр белән бүләкләнә. Алар тормыш иптәше Рәйлә Зиязетдин кызы (ул күрше Балыклы авылыннан, аның әбисе-әтисенең әнисе Тайбә әби Явыш мулласы Рәхмәтулланың кызы) бер ул–Альбертны тәрбияләп үстерәләр. Фәрит абыйның гаиләсе В.С.Черномырдин гаиләсе белән дус мөнәсәбәттә яшиләр. Виктор Степанович аны якташ һәм безнең бабайлар I-нче Бөтендөнья сугышында бергә сугышкан бит,–дип әйтә иде, ди. Аның бабасы полковник Зөлкарнаин Дашкин белән бергә сугышта булган икән.

Пенсиягә чыккач та Фәрит Шәкүр улы үзенең актив эшчәнлеген ташламый. Щелковоның мөселманнар оешмасында актив катнаша, мәчеткә йөри, намаз укый. Ул үзенең кече Ватанын да онытмый, ел саен әнисе, энекәшләре янына кайтып йөри. Ныклап авырый башлагач та: «Минем Явышта, туганнарым янында буласым килә»,–дип әйтә иде, ди. 2010 елның октябрендә ул бакыйлыкка күчә, Мәскәүнең мөселман зиратында җирләнгән.

Улы Альберт берничә ел Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсенең татар морзалар оешмасын җитәкли. 2018 елның сентябрендә ул авылга кайткач,

мәчеткә кереп, сөйләшеп утырган идек. «Бала чакта авыл ничектер үзенә тартмый иде, хәзер минем кайтасым килә, ешрак кайтырга тырышырмын инде», – дигән иде. Ел да үтмәде, ул да 2019 елның августында кинәт үлеп китте.

2019 елның 21 сентябрендә Мәскәүнең морзалары үзләренең җитәкчесе итеп Альберт улы Тимур Дашкинны сайлыйлар.

***Рәмиевләр***

1825 елны Әлмөхәммәт Ибраһим улы һәм Әминә гаиләсендә Хәнифә исемле кыз дөньяга килә. Бу гаиләдә Хөснетдин (1810–1876), Әбүбәкер (1843–1913), Хисаметдин (1812–1875) – аның тамырларын әле белмибез, исемле малайлар була. Аларның тәүге икесенең бүгенге көнне нәсел тамырлары өйрәнелгән, шәҗәрәләре төзелгән.

Тагын Мәргүбә (соңыннан Чанышева), Гайшә (соңыннан Чанышева), Хәдичә (соңыннан Габитова), Фатыйма (ул кияүгә чыкмас борын мәрхүм булгандыр – кияүдәге фамилиясе һәм балалары күрсәтелмәгән) исемле кызлары да булган. Кызганыч, кызларның нәсел дәвамчылары белән элемтә өзелгән, аларның балалары турында бездә мәгълүмат юк.

1850 елның 10 мартында Хәнифә Әлмөхәммәт кызы, Зирган егете Мөхәммәтсадыйк Рәмиев белән Явыш авылында никахлаша. Никахта кияү егетнең туганы Сәлим улы Бәхтияр Рәмиев тә катнаша. Бу никахтан 4 малай һәм 1 кыз дөньяга килә. 1862 елны гаилә Орск өязе Юлук (әлеге вакытта Башкортостанның Баймак районы) авылына күченә һәм алтын табу һәм эшкәртү эшен уңышлы гына оештыра.

Олы уллары Шакир (1857–1912) үзен Рәсәйдә генә түгел, Европада да алтын эшкәртүдә зур белгеч – инженер итеп таныта. Ә инде икенче уллары Закир (1859–1921) үзен меценат, депутат һәм бар татар дөньясына шагыйрь классик (Дәрдемәнд) итеп таныта. Калган өч балалары – Камилә, Гомәр, Галихәйдәрнең туган һәм үлгән еллары турында мәгълүмат юк.

Алар бәләкәй чакта алтын шахталарында уйнап йөргәндә нәрсәдәндер куркып калып, чирлиләр. Аларны хәтта Явышта Рәхмәтулла имамга өшкертергә дә алып килгәннәр, дип Балыклы авылында яшәүче Альмира апа сөйләгән иде. Альмира апа – Рәхмәтулланың кызы Тайбә әбинең оныгы. Рәхмәтулла мулла халык медицинасында бик көчле булган, хәтта берничә китап та язган. Кызы Тайбә әби дә гомере буе Балыклы авылы халкын дәвалаган.

Альмира апаның сүзләренә караганда, Закирның тәүге мәхәббәте дә Рәхмәтулла мулланың кызы Зәйнәб була. Тик аларга бергә булырга шагыйрьнең әнисе Хәнифә әби рөхсәт бирми. Бу хәл дөрестер-

ме, юкмы, әмма шагыйрьнең тормышын өйрәнгәннән соң уйланырга урын бар. Бәлки, кайбер шигырьләре дә сөйгән яры Зәйнәбкә багышлангандыр.

Төркиядә чагында, сөйгәне белән ашкынып очрашуны көткән шагыйрь Зәйнәбнең үлеме турында хәбәр ала. Әмма Зәйнәб исән була. Явыш хатын-кызлары арасында беренчеләрдән мөгаллимә булып, Орский якларында Мостай авылында гомерен балалар укытуга багышлый. Тормышка чыкмый. 1919 елны мәрхүм була.

Төркиядән кайткач, Закир Татар Каргалысыннан сәүдәгәр Мостафа Борнаев кызы Мәхүпҗамалга өйләнә. Аларның 7 балалары туа: Искәндәр (1886–1943), Рауза (?–1938), Зәйнәб (1891–1977), Гариф (1893–1971), Ягъфәр (1895–1976), Морад (1898–1919), Фоад (1903–?).

Шагыйрь үзенең бер кызына сөйгәненең исемен – Зәйнәб дип куша. Мәскәүдә яшәгән Әсмә Ибраһимова (Закирның балдызы Мәгруйның кызы болай дип искә ала: «Езни озын буйлы, зәңгәр күзле, чәчләре дә дөм-кара түгел, коңгырт иде. Әнием бик куанып: “Менә езнәгез мине матур, диде. Бай кызлары матур булсалар, акыллы булмый, акыллы булсалар, матур булмыйлар. Менә мине матурлыгың да бар, акылың да бар”, – дип мактады», – дип безгә ничә мәртәбәләр сөйләгән иде. Миңа калса, бу сүзләрдә йөрәкнең иң түрендә нindидер сагыш та, сер дә бар кебек. Гомумән, шагыйрь халкы серле халык, ә Дәрдемәнд – бигрәк тә.

Тагын шуны әйтергә кирәк, Закир Рәмиев үзенең тормышка ашмаган хыялын үти сымак. Улы Искәндәрне энисе ягыннан үзенең ике туганы Гомәр һәм Зарифа Дашкиннарның кызы Шәрифзадәгә өйләндерә.

Тик нигәдер Лирон абый Хәмидуллин китапларында шагыйрьнең энисе Хәнифәне дә, килене Шәрифзадәне дә Дашковлар нәселеннән, дип яза. «Без Дашковлар түгел, ә Дашкиннар», – дип мин Лирон абыйның үзенә дә, 2017 елны Казанда I-нче Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр съездында әйткән идем инде.

Закир Рәмиевнең «Дәрдемәнднең» тормышы, иҗаты турында Лирон Хәмидуллин да, Оренбургтан Мәдинә Рәхимкулова да күп яздылар.

Ә менә кода-кодагыйлары турында берничә сүз язып үтәм. Кодасы Гомәр Дашкин – Закир Рәмиевнең энисенең бертуган энесе Әбүбәкернең малае. Әбүбәкернең берничә хатыны булганлыктан, эзләнүләргә берникадәр уңайсызлыклар да тудырды.

Аның беренче хатыныннан өч малай: Хәйдәргали, Кәһәрмән, Шәһибәк.

Революциядән соң алар Юлыктан Явышка күченеп кайталар. Нәсел дәвамчыларының да шәҗәрәсе төзелгән. Икенче хатыныннан (алар Стәрлебашта яшәгәннәр), ике кызы Фатыйма һәм Камилә була. Фатыйма әби

Явышта Кәрим бай улы Хөсәен Дашкинга кияүгә чыгып дөнья көтсә, Камилә әби Уфада яшәде.

Ә Гомәр өченче хатыныннан булса кирәк. Бу тарихның очына да чыгып булмас иде, аны миңа авылның тере тарихы булган Рәйзә әби Дашкина (Халитова) сөйләде. Ул үзе әле дә исән, аңа 91 яшь. Рәйзә әбинең әбисе Шәрифә әби Зарифа әби белән бертуган икән. Революциядән соң Зарифә әби Шәрифзададән соң калган балалары Гөлсем, Зөһрә, Камил белән Үзбәкстан якларына күченеп китә. Тик аларның гомерләре анда фаҗигале өзелә. Иртәгә Камилнең туе көнне төнлә караклар кереп гаиләне суеп чыгып китәләр. Иң кечеләре Зөһрә генә иптәш кызларына куна киткән була һәм исән кала. Аның оныкчыгы Равилә, 1990-нчы елларда Таҗикстаннан күченеп кайтып, авылда яши.

Закир улы Искәндәр 1917 елны Шәрифзадә Дашкинага өйләнә һәм 1918 елны аларның Бәшир исемле уллары туа. Тик гаилә озак яши алмый, 1919 елны Шәрифзадә тиф авыруыннан үлә. Бәшир Искәндәр улы тугыз класс белеме белән (аның югары белеме булмый, «халык дошманы малае» дип институттан куалар) техник фәннәре докторы исеменә лаек була. Ул беренче дәрәҗә Дәүләт премиясе лауреаты, СССРның Министрлар Советы премиясе лауреаты, РСФСРның атказанган уйлап табучысы (изобретатель), ике Хезмәт, Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. 1994 елны мәрхүм була.

Бәшир Искәндәр улы Рәмиев турында мәкалә «Туган җир» журналының 2020 елның беренче санында басылган иде. Мин аның әнисе ягыннан гына үзем белгән мәгълүматларны язарга тырыштым.

***Солтангалиевләр***

Явыш авылында беренче мәктәп 1883 елның 19 мартында ачыла. Мәктәпнең попечителе отставкадагы поручик Морза Гобәйдулла кенәз Дашкин була. Ә беренче укытучы Ырымбур татар укытучылар мәктәбен тәмамлап килгән 20 яшьлек Хәйдәргали Хаҗимөхәммәт улы Солтангалиев була. Архив материалларына караганда, 1883–1884 елгы уку елында мәктәптә 24 укучы була. Укытучының еллык хезмәт хакы 300 сум була.

Озынча буйлы чибәр егет үзенең мәхәббәтен һәм язмышы булган яшь сылу ятим калган Мөхәммәтрәхим Хусрави улы Чанышев һәм Зәйнәб Ягъфәр кызы Дашкинаның кече кызлары Гайнелхәятне (1860 елгы) очрата һәм алар язмышларын бергә бәйлиләр. Явышта чакта аларның мәхәббәт җимеше булып ике кызлары Сәрвәр һәм Суфия туа. Ләкин гаилә нидер сәбәпле бүгенге көнне күрше Стәрлебаш районындагы башкорт авылы Еләмбәткә күченә. Һәм шунда 1892 елны булачак революционер, Үзәк мөселман комиссариаты рәисе Мирсәет Солтангалиев туа. Беренче

белемне ул әтисеннән алган. Мин Мирсәетнең балачагы белән кызыксыну максаты белән Еләмбәткә барган идем, кызганычка каршы анда аның турында бер мәгълүмат та сакланмаган.

Мирсәет Солтангалиев, Якуб Чанышев белән бергә Казанда татар укытучылар мәктәбендә белем алалар. Уфада Мирсәид үзенең дусты Якубның абыйсы Мөхәммәдиннең кече кызы Рауза белән танышалар һәм өйләнешәләр. Яшь гаилә Стәрлетамак өязе Шәрип авылында укыту эше белән шөгыльләнәләр. Аннары гаилә Баку шәһәренә күченә, Рауза гимназиядә укытса, Мирсәет гәзитләргә мәкаләләр яза. Икесе дә революция эшенә баштан чумалар. Икесе дә РКП(б) әгъзасы була: Мирсәет 1917 елда, ә Рауза 1919 елда.

Мөселман хатын-кызларын яклаучы хәрәкәттә Рауза актив катнаша. Бу хәрәкәтнең ике революция арасында Казанда үткән I һәм II Бөтенрусия мөселманнары съездында катнаша, съезд президиумына сайлана. Тик аларның ире белән мөнәсәбәтләре үзгәрә һәм Рауза 1918 елны Орскига китеп, аклар ягында сугышкан Зәки Вәлиди армиясенә үз теләге белән керә. 1919 елның март аенда гаскәр кызыллар ягына күчә, монда Мирсәетнең дә роле зур була. 1919 елның ноябрендә Раузаны Кече Башкортостанның хөкүмәтенә эшкә алалар. Ул РКП (б)ның I-нче Бөтенбашкорт конференциясендә катнаша. 1921 елны тиф авыруы белән чирләп үлә. Уртак кызлары Рәсидә туганнары карамагына кала.

Мирсәетнең апасы Сәрвәр Шәһибәк Чанышев һәм Гарифә Дашкинаның улы Рөстәмбәккә кияүгә чыга. 1917 елдагы җанисәп нәтиҗәләре буенча Явышта яшәгән булалар. Ул вакытта Рөстәмбәккә 35 яшь була, аларның уллары һәм кызлары була. Мирсәетнең җизнәсе 1918 елда Стәрлетамак өязенең мәгариф бүлеген җитәкли. 1919 елда Зәки Вәлиди Хөкүмәтендә эшли. Репрессиягә эләгә.

Ә Мирсәет исә икенчегә – Фатыйма Ерзинага өйләнә, туйларында Сталин да катнаша. Әмма соңрак ул Мирсәет Солтангалиевне өнәми башлый һәм аңардан баш тарта. Чөнки Солтангалиев белән Сталинның милли мәсьәләләрдә карашлары капма-каршы килә. Бу темага ул күп мәкаләләр яза. 1921 елда язылган «Методы антирелигиозной пропаганды среди мусульман» мәкаләсендә ул болай дип яза: «В религии Ислама больше, чем в какой-либо другой, имеется гражданско-политических элементов, тогда как в других религиях преобладают чисто духовно-этнические мотивы.

Среди законов Ислама он считал имеющими положительный характер:

обязательность просвещения, промышленности и труда;

– обязанность родителей воспитать детей до совершеннолетия;

– допустимость гражданского брака;

– отрицание частной собственности на землю, воду и леса, отрицание суеверий, запрещение колдовства, азартных игр, роскоши, расточительности, употребления спиртных напитков, взяточничества, установление детально разработанной прогрессвино-налоговой системы,

– натуральной и налоговой (закят, гомер);

– Султангалиев утверждал, что нужно открыто сказать, кому это следует, что мы никакой борьбы, с какой-либо религией не ведем, а лишь ведем пропаганду своих атеистических убеждений, осуществляя свое вполне естественное право на это».

Менә шундый идеяләр белән ул И.В. Сталинның үзен, хәтта ленинизмны тәнкыйтьләү юлына баса. Әлбәттә, бу ил башлыкларына ошамый. Һәм дә шуның өчен Мирсәетне милли оешма оештыруда һәм милли мәсьәләдә партия җитәкчеләренә каршы чыгуда (саитгалиевщина) гаепләп, 1923 елның 14 июнендә беренче тапкыр кулга алалар. Әмма эш туктатыла, ТатАССРның җитәкчеләре хәстәрлеге аркасында аны азат итәләр. Ул 1928 елның 12 декабрендә икенче тапкыр кулга алына. Аны СССРны таркатуга максат куйган милли оешманың җитәкчесе булуда гаеплиләр. Атуга хөкем итәләр, ләкин 1931 елның 13 гыйнварында бу хөкемне 10 еллык сөргенгә алыштыралар. Исәнлеге начарлануы аркасында, 1934 елны ул кабат азат ителә. 1937 елның 19 мартында өченче тапкыр кулга алына. Бу юлы инде аны чит ил разведкасы белән элемтәдә торуда гаеплиләр. Бусы инде бик зур гаепләү, Солтангалиев инде хәзер үзе дә бу тозактан котыла алмасын аңлый. Һәм ул хатынына, аны да эзәрлекләмәсеннәр өчен, аңа балачак дусты Дашкинга кияүгә чыгарга тәкъдим ясап, записка яза. Чыгарылган карар буенча, 1940 елның 28 гыйнварында ул атыла. Мәскәү каласының Бутово каберлегендә җирләнә. Тамырлары Дашкиннар нәселе белән бәйле, Явыш авылында балачагын уздырган, Татарстан бәйсезлеге өчен көч салган татар улы Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиевнең гомере шулай өзелә.

*P.S. Ә Мәскәүдә яшәгән Мирсәетнең балачак дусты Дашкинның без әле кем икәнлеген ачыклаганыбыз юк. Бәлки аның турында да мәгълүматлар белүче бардыр?*

***Полковник Әмирхан Дашкин***

Дашкин Әмирхан Шәйхлислам улы 1903 елның 15 октябрендә Стәрлетамак өязе, Фёдоровка волосте Явыш авылында дөньяга килә. Ул вакытта авылда мәдрәсә һәм 4 еллык рус мәктәбе була. Балалар көндез рус мәктәбендә укысалар, кичен мәдрәсәдә белем алалар. Авылда 4 еллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул Фёдоровка авылындагы 8 еллык мәктәпкә укырга керә. Татарлардан анда нибары 3 бала укый. Мәктәптә уку көчле куелган була, тәртип көчле, балалар хәтта хәрби дәресләр

дә алалар. 1918 елны бу мәктәпне тәмамлаганнан соң, Әмирхан туган авылында беренче класс балаларын укыта. 1919 елны волисполкомда писарь булып эшли, комсомол сафларына керә. Ә 1925 елны гади авыл малаеның тормышы кискен үзгәрә. Бу елны авылга кунакка I-нче Бөтендөнья сугышында катнашкан, Гражданнар сугышы герое, Казандагы укчылар дивизиясе командиры Якуб Джангир улы Чанышев кайта. Аның бертуган апасы Зәйнәб һәм әтисенең энесе Шәһибәк Чанышев Явышта яшиләр. Булачак генерал үзенең өчтуган энесе Әмирханны һәм аның якын дусты Корбан Абдулгани улы Нарбековны (1898 елгы) Казандагы татар-башкорт хәрби командирлар әзерли торган мәктәпкә укырга чакыра. Корбан Нарбеков Явыш авылына нигез салучы Нәрбик Дашкинның оныгы, Бөек Ватан сугышын майор чинында тәмамлый. Сугыштан соң Вышний Волчек шәһәрендә Калинин өлкәсе, хәзерге Тверь эчке эшләр органнарында эшли. 1977 елда подполковник дәрәҗәсендә мәрхүм була.

Амирхан мәктәптә яхшы укый, сыйныфташлары арасында рус телен яхшы белүе белән аерылып тора. Икенче курста укыган вакытта ук ул курсантлар белән үзаллы политзанятиеләр үткәрә башлый. Ә 1927 елда инде ул курс командирының ярдәмчесе була. 1928 елны Тат. ЦИК исемендәге мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул Советлар Союзының булачак маршалы Г.К. Жуков җитәкләгән полкка взвод командиры вазифасына юллама ала. Тактик укулар вакытында уңышлы разведка ясаганы өчен, СССРның тагын бер булачак маршалы К.К. Рокоссовский аңа рәхмәт белдерә. Үзенең хезмәт иткән вакытында Әмирханга СССРның маршаллары К.Е. Ворошилов, С. Буденый, А. Егоров, М. Тухачевскийлар белән очрашырга насыйп була. Булачак сугышта ат гаскәрләре түгел, ә бронетанк гаскәрләре зур әһәмият уйнавы ачыклана һәм яшь коммунист А.Ш. Дашкинны танк курсларына укырга җибәрәләр. Укуын тәмамлагач, ул танк взводы командиры, соңрак рота командирының ярдәмчесе була. 1941 елның гыйнвар аеннан 16-нчы танк корпусының политбүлек җитәкчесе була. Бөек Ватан сугышын ул Көнбатыш, Көньяк-Көнбатыш фронтларында башлый. Мәскәү өчен барган сугышларда 26-нчы танк бригадасының комиссары була. Малоярославск юнәлешендә барган каты бәрелеш вакытында комбриг полковник Левский снаряд ярчыгы эләгеп, һәлак була.

Әлеге аяныч вакытта бригада комиссары Дашкин яу белән җитәкчелек итүне үз өстенә ала. 26-нчы бригада үз җирләрендә нык тора, немецлар танклары атакасы туктатыла, безнең яктан да югалтулар күп була. Штаб начальнигы соединение штабына безнең югалтулар турында отчет бирә. Батырларча үлүчеләр исемлегендә полк комиссары

Дашкин да була. Ә ул шушы вакытта карда кан эчендә ята. Үлүчеләрне һәм каты яраланучыларны җыйнап йөрүче отряд аны шул хәлдә табып ала. Госпитальдә дәвалаучы табиблар аның тәнендә 7 яра булуын ачыклый. Бу яуда катнашканы өчен үзенең беренче хәрби бүләге – «Кызыл Байрак» ордены белән бүләкләнә. Яраларын төзәткәннән соң, ул яңадан сафка баса. Өченче тапкыр каты яраланганнан соң, аны 1943 елны Чиләбе танк училищесына политбүлек җитәкчесе итеп җибәрәләр. Чиләбедә хезмәт иткән вакытында ул танк заводында очраклы рәвештә үзенең авылдашларын, фронт өчен танк ясаучы трудармеецлар Дашкин Сабир Габҗәлил улы һәм Дашкин Хафиз Мөхәррәм улын очрата. 7 ел буе ул Чиләбе танк училищесында политбүлек җитәкчесе булып хезмәт итә һәм танк гаскәрләре өчен офицерлар әзерләүдә зур өлеш кертә. 1950–55 елларда ул лаеклы ялга чыкканчы Казанның Совет районының хәрби комиссариатын җитәкли. 30 ел дәверендә коммунист Ә.Ш. Дашкин, совет офицеры исеменә тап төшермичә туган иленә тугры хезмәт итә. Күрсәткән батырлыгын да Ватаныбыз зур бәяли. Аның күкрәген илебезнең иң зур ордены – Ленин ордены, Бөек Ватан сугышының – 3 ордены, Кызыл Байрак ордены, Кызыл Йолдыз ордены һәм 14 медаль бизи. Лаеклы ялга чыкканнан соң да, ул әле 20 ел буе агитация һәм пропаганда бүлеген җитәкли. Яшь буынны тәрбияләүдә зур өлеш кертә. Еш кына Казанның 3, 4, 93, 98 һәм 101-нче номерлы мәктәпләрендә батырлык дәресләре алып бара.

Пионерлар сборында, комсомоллар җыелышында катнаша. Ул һәр эштә дә тәртип, төгәллек, дөреслек ярата, үз тирә-ягындагы кешеләрне хөрмәт итә. Тыныч вакытта да фронтның алгы сызыгында була. 1960-нчы елларда 4 номерлы мәктәп укучылары тимер сыныгы, макулатура җыйган акчага Кызыл Байраклы 146-нчы укчылар дивизиясе хөрмәтенә һәйкәл куела.

1970-нче еллар башында йөрәксез, ваемсыз чиновниклар бу һәйкәлне кирәксез дип табалар һәм җимерәләр. Шулвакытта фронтовик Ә.Ш. Дашкин һәйкәлне торгызу өчен барган көрәшне җитәкли. Һәм һәйкәл фронтовик-ветеран яшәгән өй каршысында торгызыла. Көрәштәшләре, Әмирхан Шәйхлислам улына зур хөрмәт йөзеннән, аңа багышлап шигырь язалар.

1995 елның 19 ноябрендә полковник Ә.Ш. Дашкин бакыйлыкка күчә, ул Казанның татар зиратына җирләнә. Вахитов районының халкы аның фидакарь хезмәтен онытмый. Катоновский переулокның өченче номерлы өйдә яшәүчеләр, хезмәт ветераны А.Г. Степаненко җитәкчелегендә 2010 елны, үзләре яшәгән өйгә такта-таш куялар. Анда татар һәм рус телләрендә болай дип язылган:

«В этом доме в 1955–1995 гг. жил полковник Дашкин Амирхан Шайхлисламович, инвалид Великой Отечественной войны, борец за сохранение памяти воинов 146-ой дивизии».

Полковник Ә.Ш. Дашкинның эшен яңа буын дәвам итә. Минем бертуган апам Әлфия Һади кызы Галиева-Дашкинаның (ул инде мәрхүмә, Башкортостанның атказанган шәфкать туташы) улы Радик Тәлгать улы кайчандыр Әмирхан Шәйхлислам улы укыткан Чиләбе танк училищесын тәмамлап, Мәскәүдә Якуб Джангир улы Чанышев белем биргән Генеральный штаб академиясен тәмамлап, Ерак Көнчыгыш хәрби округта хезмәт итә. Ә абыйсы полковник Ринат Тәлгать улы Уфада яши һәм хезмәт итә.

***Якуб Чанышев һәм Мирсәет Солтангалиев***

2020 елны татарстанлылар, алар гына да түгел, бөтен татар дөньясы республиканың 100 еллык юбилеен билгеләп үтте. Бу бөек юбилейның башында, ул вакыттагы барган кызу бәйләнешләр казанында кайнаучы, үз гомерләрен аямыйча республиканың киләчәге өчен көрәшүчеләр арасында безнең якташларыбыз, авылдашларыбыз, дип әйтсәк тә ялган булмас, Якуб Джангир улы Чанышев һәм Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиев. Аларның язмышлары, тормыш юллары игезәкләр кебек охшаш та, шул ук вакытта аермалары күп, бер-берсе белән капма-каршы килгән чаклары да бар. Аларны туганлык җепләре дә бәйли.

Икесе дә бер үк елны дөньяга килгән, икесе дә Стәрлетамак өязендә, беренчесе – Тукай авылында (хәзеге Авыргазы районы), икенчесе – Еләмбәт авылында (халык телендә Калмак дип тә йөртәләр, Стәрлебаш районы). Икесенең дә нәсел тамырлары шул ук Стәрлетамак өязендә урнашкан Явыш авылы белән (әлеге Фёдоровка районы) бәйле, икесенең дә балачаклары шушы авыл белән бәйле. Берсе тәүге белемне Уфа гимназиясендә алса, икенчесе әтисеннән сабак ала. Икесе дә рус телен яхшы белгән, бу ул вакытта сирәк очрый торган хәл. Икесе дә бер үк вакытта белемнәрен Казанда камилләштерәләр. Беренчесе I-нче Бөтендөнья сугышында катнашып, медальләргә лаек булса, икенчесе бу чорда язучылык белән шөгыльләнә.

Икесе дә 1917 елны ВКП (б) әгъзалары булалар һәм дә икесе дә Гражданнар сугышы вакытында Көнчыгыш фронтның икенче армиясендә хезмәт итәләр, хәтта атылуга хөкем ителәләр, соңрак акланылалар. Ике туган, иңгә-иң терәп дус булып яшәсәләр дә, аларның юллары аерыла, беренчесе Бөек Ватан сугышын башыннан ахырына кадәр үтеп, картлыкны да күрүгә ирешсә, икенчесе арыслandай көчле чагында репрессия корбаны була. Икесенең дә каберләре илебез башкаласы Мәскәүдә. Язмышлары ничек кенә булмасын, алар икесе дә Башкортостан, Татарстан

тарихында гына түгел, бәлки Советлар Союзы дип аталган ил тарихында да тирән эз калдырган.

Тукай авылында яшәгән кенәз Чанышевлар кияү, киленнәрне үз тиңнәреннән сайларга тырышканнар. Аларның кодалары арасында Акчуриннар, Дашкиннар, Кудашевлар, Ибраһимовлар, Диваевлар булган. 1842 елның 24 мартында 55 яшьлек Ибраһим улы Якуб Чанышев явышлы Забир Гомәр улы Дашкинның 17 яшьлек Бибимаргубәгә өйләнә. Ике ел да үтми, Якубның тәүге хатыныннан булган олы улы Мөхәммәтгәрәй 1844 елның 24 гыйнварында шул ук Явыш авылыннан Ибраһим улы Хәсән Дашкинның Фагыйлә исемле кызына өйләнә. Аларның 6 балалары була:

I. Иң олысы – Җиһангир (1842–1902). Аның балалары: Мөхәммәди, Якуб, Хәсән, Зәйнәб.

Мөхәммәди – Уфада рус-татар училищесында укыта. Аның кызы Рауза.

Якуб – булачак генерал.

Хәсән – Стәрлетамакта милициядә хезмәт итә. Каты яраланганнан соң вафат була, туган авылында җирләнгән.

Зәйнәб – Бәдретдин улы Гомәр Дашкинга Явыш авылына тормышка чыга. Аларның балалары: Әгдам, Әхтәм, Әхсән, Шәрифзадә, Мәдинә, Камилә.

Тәүгеләрнең язмышы миңа билгесез.

Мәдинә әби – Явышта, ә кечеләре Камилә әби Казанда – яшәде.

II. Мөхәммәтгәрәй белән Фагыйләнең икенче уллары Шайхелислам (1853–1912), Казанда хәрби белем ала. Кавказ, Рус-төрек, Рус-япон сугышларында катнаша. Күп кенә бүләкләргә лаек була, генерал-майор дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. 1912 елны 60 яшендә мәрхүм булып Уфада җирләнә. Хатыны, балалары булмый.

III. Мөхәммәтгәрәй белән Фагыйләнең өченче уллары Шәһибәк Явыш мулласы Рәхмәтулла Дашкинның Гарифә исемле кызына өйләнә, һәм Явыш мәктәбендә укытучы булып эшли. Аларның уллары Гобәйдулла һәм Рөстәмбәк үз акчаларына Явыш авылында 1913 елда мәктәп салалар. Ул мәктәптә мин үзем дә 1964–67 елларда дүрт класс укыдым.

Кызлары Әминә тутакай да шул мәктәптә укытучы булып эшли. Соңыннан ул Уфада яши.

1920 елны Шаһибәк Чанышев гаиләсе белән Стәрлетамак шәһәренә күченеп китә.

Менә шундый бай тарихлы гаиләдә, 1892 елны дөньяга туа да инде булачак совет генералы Якуб Җиһангир улы Чанышев. 10 яшендә ул этисез кала, кышларын Уфада Мөхәммәди абыйсында тәрбияләнеп укыса,

җәйләрен Явышка апасы Зәйнәб һәм этисенең энесе Шаһибәкләргә кайтып йөри.

Аннан ул Казанга укытучылар мәктәбенә укырга керә. 1912 елны Стәрлетамак өязе Курманай авылында укыта. 1913 елны аны патша армиясенә алалар, ә бер елдан соң сугыш башлана.

1916 елда ул генерал Брусилов җитәкчелегендәге хәрби операцияләрдә катнаша. Күрсәткән батырлыгы өчен «Георгиевский крест» медале (IV дәрәҗә) белән бүләкләнә һәм унтер офицер чины бирелә. 1917 елның гыйнварыннан Казан хәрби училищесында укып, прапорщик чины ала һәм рота белән җитәкчелек итә. 1918 елның декабрендә Уфаның хәрби коменданты итеп тәгаенләнә. 1920 елның мартыннан Төркестан фронтында сугыша, Ферганә һәм Бохара шәһәрләрен алуда актив катнаша.

Ферганә группасының аерым укчылар бригадасының комиссары, Беренче Казан укчылар дивизиясенең комиссары һәм командиры була, 1934 елны М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлый. Урта Азия Хәрби округының 68-нче Кызыл байраклы тау укчылары дивизиясе белән җитәкчелек итә. 1937 елның 13 маенда троцкизмда гаепләнеп кулга алына. Бу вакытта ул Төркестанда укчылар дивизиясе белән җитәкчелек иткән була. 1939 елның декабрендә тулаем аклана. Бөек Ватан сугышында дивизия белән җитәкчелек итә, генерал-майор, генерал-лейтенант дәрәҗәсенә җитә. Ул Мәскәү янындагы барган сугышларда, Сталинградны, Харьковны, Польшаны азат итүдә катнаша, Берлинга кадәр барып җитә.

Якуб Чанышев Ленин ордены (2 тапкыр), «Кызыл Байрак» (4 тапкыр), Суворов (21-нче дәрәҗә), Кутузов I-нче дәрәҗә, Бөек Ватан сугышы I-нче дәрәҗә, Кызыл Йолдыз (2 тапкыр), Үзбәкстанның Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, АКШ һәм Польша орден-медальләре белән бүләкләнә.

Совет чорында Үзбәкстанда Якуб Чанышевны беләләр һәм хөрмәт итәләр. Андижан халкы аңа шәһәрнең «Почетлы гражданины» исемен бирә. 1962 елны Якуб Чанышевка 70 еллык юбилее белән ул елларда Үзбәкстан ССРның беренче секретаре Шәрәф Рәшидов котлау телеграммасында болай дип яза: «Үзбәкстан халкы Сезнең Төркестанда Гражданнар сугышы вакытында башкарган фидакарь хезмәтегезне олы бәяли. Совет власте урнаштыруда һәм басмачларны таркатуда Сезнең өлешегез һичшиксез бәясез».

Якуб Җиһангир улы Чанышев 1987 елда мәрхүм була, Мәскәүдә җирләнә. Әлеге вакытта Мәскәүдә аның оныгы Динә Чанышева яши, мин аның белән телефон аша хәбәрдар.

**Әдәбият**


1. М.У. Сюндюков. А.Г. Терегулов. На пути к возрождению. Уфа, 2018.
2. За честь и Родину свою // Сборник материалов и воспоминаний. Ответственный редактор Л.Г. Терегулов. Составитель: М.У. Сюндюков. Уфа, 2016.
3. Лирон Хәмидуллин. Дәрдемәнд. Казан, 2003.
4. Лирон Хәмидуллин. Дәрдемәнд. Казан, 2010.
5. Мәдинә Рәхимкулова. Рәмиевләр. Оренбург, 1995.
6. Мәдинә Рәхимкулова. Рәмиевләр. Оренбург, 1999.
7. Сагитдинов М.Ш., Сафин М.Х. Родовые корни айдаралинцев. Стерлитамак, 2010.
8. Статьи Смертиной (Дашкиной) Р.Р., Стерлитамак.
9. Статьи Адаменко (Дашкиной) Ф.Р., Уфа.
10. Воспоминания жителей с. Верхнеяушево Дашкиной Райзы әби – Верхнеяушево, Валитовой Альмиры әби из Балыклов.

*Рөстәм Мәһдиев*

## ТЫЕЛГАН КИТАП ЭЗЕННӘН

*(Дәвамы. Башы № 3/4, 2020)*

### *Муса Бигиев вә Морад хәзрәт каршылыгы*

1917-нче елның июлендә Казанда Бөтенрусия мөселман дин әһелләренең корылтае була. М. Рәмзи корылтайга Оренбург мөселманнары өммәтеннән сайланган делегат сыйфатында катнаша. «Йолдыз» гәзите әлеге зур вакыйганы берничә санда, көнүзәк тема итеп тәфсилләп яктыртып бара. Мәсәлән, 21 июль санында (№ 1816) беренче биттә корылтайның президиум исемлеге бирелгән. Кемнәр кергән аңа? Габдулла мулла Апанай, Садыйк хәзрәт Иманколый, Габдрахман хәзрәт Гомәри, Минһаҗетдин Кадермәти, Ахунд әл-Мәсгуди, Хәсәнгата Габәши, Шәһәр әфәнде Шәрәф, Хәсән Таһири, Габделгазиз хәзрәт Габделкәримов, Мәзһәр Камалетдинов, Кәрамәтулла Айдаров, Мәскәү ахуны Габдулла Шәмсетдинов, Кырым, Төркестан вә Казакъстан вәкилләре белән беррәттән Морад хәзрәт Рәмзи-Мәкки дә бар.

«Йолдыз» хәбәрчесе [26 июль санында, № 1818] корылтайда 24 июльдә булган вакыйгаларның кинәт куерып китүен болай тасвирлый: «Бишенче мәҗлес Габдулла хәзрәт (*Апанай*) рәислегендә ачылды... Башлап Морад әфәнде Мәкки хатын-кыз хакында комиссиянең карарга килгән докладын укый. Байтакка сузылган бу докладтан соң бер кыйсем халык доклад мозакәрә кылмый (*фикер алышмый*) гына кабул итәргә тели. Ләкин ул арада нәүбәткә бу хакта язылучылар 20гә кадәр җитә башлый. Рәис боларны чикләүне тавышка куя. Моннан алда Муса әфәнде Җаруллаһ чыгып: «Хәзрәтләр! Асыл, монда да иң мөһим нисаи (*хатын-кыз*) мәсьәләсе, дигән иделәр. Хатыннар хакындагы карарлар бигрәк миңа мөнәсәбәтле, беләсез, бу мәсьәлә миннән кузгалды, шунлыктан, бу хакта минем дә докладымны тыңлавыгызны үтенәм һәм миңа вакыт чикләмәвегезне телим» (*Халык шаулый башлый*). Сими Габделхак мәхдүм: «Без фикерләремезне менә мәҗәлләдә (*журналда*), гәзитәләрдә язармыз, монда сөйләшеп тормыйк», –ди.

Рәис: «Җәмәгать, вакыт тула, ләкин монда Муса әфәнде үзен аклар өчен дәлилләр китереп сөйләмәкче була. Бу аңар мөсагадә (*мөмкинлек бирү, булышу*) итәргә бурычлымыз», – ди.

Муса әфәнде рәиснең «үзен аклау өчен» дигән гыйбарәсен кайтарып алуны үтенә: «Мин үземне акларга чыкмыйм, бәлки, хаканиятне (*хаклыкны, дөреслек*) дәгъва итәргә чыгам», – ди. «Кирәкми, чыкма», – диләр. Та-

выш бик зурая. Шәех Морад: «Әфәнделәр! Муса әфәнде сөйләсен, аңа сүз бирмәү золымлык була». Ниһаять, рәис Габдулла хәзрәт, президиум рөхсәте белән, мөнбәргә чыгып сөйли.

Бу урында беркадәр аңлатма биреп китү урынлы булыр.

Мәгълүмдер ки, XIX йөз азакларында – XX йөз башларында ислам дөньясында кайбер фикер ияләре, көнбатыштан искән «җилләр» тәэсирендә хатын-кыз мәсьәләсенә игътибарны арттыра һәм аны чишү юлларында төрле ысуллар һәм чаралар тәкъдим итә. Мөселман җәмгатьчелегенең игътибарын җәлеп иткән ошбу проблемага Муса әфәнде Бигиев һич кенә битараф булмый. Чөнки электән аны борчыган бу мәсьәлә буенча аның тарафыннан эшләнгән махсус программасы була. Форсаттан файдаланып, ул әлеге программаны корылтай делегатлары алдында яңгырата. Программаның төп нигезен мөселманнар арасында байтактан бирле яшәп килгән дини, аның фикеренчә, «хорафатларны» кире кагудан гыйбарәт. Мәсәлән, Муса Җаруллаһ Биги хәзрәтләре Шәригать буенча ир-ат – беренчел, хатын-кыз – икенчел, дигән карашны кире кага; ир-ат – камил зат, ә хатын-кыз кабыргадан яратылганга зәгыйфь вә камил түгел, дигән карашны юкка чыгара; хатын кызның диндарлыгы да камил түгел, чөнки аңа һәр айда мәгълүм көннәрдә намаз уку, гыйбадәт кылу тыела, дигән хөкемне инкарь итә; мәхкәмәдә шаһитлык кылганда бер ирнең сүзе ике хатынның сүзенә тиң булуының хакыйкатькә туры килмәвен дәлилли; мирас бүлгәндә дә хатын-кызга азрак өлеш тияргә тиеш, дигән хөкемне дә кире кага; һәм, ниһаять, зәгыйфьлеге аркасында хатын-кыз, җиһад сугышларында катнашудан читләштерелеп, диндарлыкның иң югары дәрәҗәләренә ирешә алудан мәхрүм ителгән, дигән хөкемне ахмаклык, дип белдерә [Хәйретдин: 2003. 43, 47 бб.].

Биредә әлеге шәхескә хас бер сыйфат ярылып ята, ягъни, Муса әфәнденең бәхәсләшергә, капма-каршы фикер әйтеп, әңгәмәне кискенләштерә алуы чагылыш тапкан. Галим һәм язучы Адлер Тимергалин әйтмешли, кайчагында, бәхәскә бирелеп, ул хәтта хакыйкатькә хилафлык та кыла. Абруйлы дин әһелләреннән Габдрахман Гомәри бу турыда: «Муса әфәндедә бер яман холык бар: бер мәҗлестә бер кешегә артык игътибар булса вә ул кемсәнең сүзен яки мәгрузәсен (*чыгыш, доклад*) тәкъдир берлән каршы алсалар, шул мәҗлеснең артынча Муса әфәнде мәзкүр кемсәгә бер һөҗүм кылмыйча калмыйдыр» [Тимергалин: 2016. 1 т. 297 б.].

Хәер, корылтайга әйләнеп кайтыйк. Биредә дә Морад хәзрәт шәригать кануннарының какшамаслыгын яклап чыгуы белән хөрмәт казана. Ә инде Муса Бигинең хатын-кызлар мәсьәләсендә фикерләре 1917-нче елгы түнтәрелештән соң тора-бара тулысынча, хәтта артыгы белән, чын-

га ашырылды, аның нәтиҗәләре күз алдыбызда һәм бу турыда биредә сүз куертып торуның кирәге дә юктыр.

Менә «Йолдыз» гәзитенең 28 июль, 1819-нчы саны. Анда «Голяма съезды» дигән баш астында түбәндәгеләр хәбәр ителә: «25 июль 11 сәгатьтә Габдулла хәзрәт Апанай тәхет риясәтендә (*рәислегендә*) мәҗлес ачыла. Мәсьәлә, Мәскәү съездында үткән хәлаф шөруг (*керешү, башлау*) карарлар мөнәсәбәте илә кичә бер карарга киленә алмый аерылышып киттектән, ниһаять, аны бүгенге мәҗлескә кичектерергә вә ул хакта сөйләргә Муса әфәндегә гаер мәхдүд (*чикле*) бер вакыт бирергә булдыктан, беренче мозакәрәдә (*фикер алышу, җыелыш*) шул хакта ачыла вә хатын-кыз турында сөйләргә Муса әфәнде чыга һәм ислам хатыннарның хокукый вә гомуми хатын-кызлар мәсьәләсе хакларында ачык мофассал (*тулы, җентекле*) бианәт бирә. Сәгатьләрчә сузылган аның докладында «Адәм балалары, ирләре вә хатыннары да бәла истисна (*чикләнүсез*) бөтен хокукта мосауи (*бертигез*)!» диелгән шигарь тотыла... Мирас бүлү, шәһәдә мәсьәләсендә дә дәлилләр китереп, хатыннарны истисна мөмкин түгеллеген сөйли һәм ахыр сүзендә «инһан игълибан әл гакыл вә игълибһан әл-җәһел» (ягъни, «хатын-кыз гыйлем иясен дә җиңәчәкләр, әмма алар наданнар каршында көчсез»), дип, хатыннарга хокук бирүдә, хәзрәтләр, сез акыл ияләре буларак, мәгълүб (җиңелгән) булыгыз, диде. Бианәт (дәлилләү) иснәсендә халык тарафыннан бәгъзе алкышларга вә бәгъзедә «дөрест!» дигән сүзләргә очрала. Ниһаять, остазлар, инсаниятнең гакылы хәзер тәмам рәвешкә ирешеп, һуаларны үзенә җигеп анла очып йөргәндә фәкать бер генә нәрсә булган: гаилә низамнарын (*тәртипләрен*) хәл итүдән һаман гаҗиз калды, ди вә менә бездә милли, мәдәни мохтарият игълан иттек, ләкин гаилә хәлләремезне ислях (*килештерү, тигезләү*) итми торып, бер тиенлек тә моның әһәмияте булмаячак. Бинаән галәйһи (*шуңа күрә*) Ислам дәүләтен сүндермәү вә әүвәлге кеби шәүкәтен үстерәсегез килсә, әүвәл сездә гаиләдә автономия игълан итегез! Сүзен бетерә башлаганда халык тарафыннан «хиҗаб хакында сөйләшмәдек ич!» диләр. Муса әфәнде аңар кыска гына бер җавап биреп: «Мин хәзерге кеби хиҗабны тиеш генә түгел, хәтта хәрам, дим»,– ди.

Моннан соң Муса әфәнде сүзләренә каршы Морад Мәкки чыга вә, берникадәр җаваплар биреп, каршы дәлилләр күрсәтә. Ләкин кайбер сүзләрне хәтта ишетеп торганлыктан, Муса әфәнде әйтмәгәнне дә, әйтте, дия башлый. Аның бу сүзләре Муса әфәнде президиум һәм халык тарафыннан тасхих (*дөресләнә, төзәтелә*) ителә. Ул арада сүзне куәтләр өчен бер хикәя сөйлим, ди башлап мәҗлес шәрәфенә мөнасиб (*яраклы, килешле*) булган сүзләр ычкындыра... рәис тәнбиһ (*кисәтү*) ясый вә кайтарып алырга куша...»

Муса Биги белән Морад Рәмзинең фикер каршылыклары билгеле факт. Ошбу темага багышлап, тарихчы аерым китап та язып бастыра. Ул «Мөшәйәгат хизб ар-Рахман вә мөдафига хизб аш-Шайтан». Әлеге китапта М. Рәмзи каршы якны кискен рәвештә тәнкыйть итә һәм үзенең карашларын белдерә.

Бу – ике гыйлем иясе дини һәм иҗтимагый-социаль мәсьәләләрдә капма-каршы позицияләрдә торсалар да аларны якынайтучы уртак фикерләр дә булуын күрсәтми мөмкин түгел. Билгеле булганча, мөселман мифологиясендә, кыямәт көне алдыннан Ерак Көнчыгышта яши һәм бөтен Җир йөзендә имансызлык тарата торган Йәэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ кавеме һөҗүм итүе көтелә. Йәэҗүҗ халкы озын сыйраклы. Мәэҗүҗ кавеме исә базык буйлы, табак битле һәм кысык күзле, диелә. Бу хәшәрәтләр иң әүвәл мөэмин-мөселман өммәтенә куркыныч тудырачак, имеш. Бу хакта Коръән Шәрифнең «әл-Кәһеф» («*Тау куышы*») сүрәсендә хәбәр бар. Галимнәрнең икесе дә өммәткә ут, ягъни корал вә матди байлык ярдәме белән бөтен дөньяга хакимлек итәргә ашкынган христиан цивилизациясен шушы куркыныч чыгынагы итеп күрсәтә. Галим, филология фәннәре кандидаты, Казан университеты доценты Азат Ахунов үзенең бер мәкаләсендә патша цензурасы 1908 елда М. Рәмзинең китабын тыюда төп сәбәп итеп нәкъ шушы фикерне күрсәтә. Чөнки «Талфик...»ның 2-нче томында «Иван Мөдһеш явы тарафыннан 1552 елда Казан яуланганнан соң ханлык тармар ителеп туздырылгач, баскынчыларны тотып торган ныгытма-диварны «бөек милләтнең» Йәэҗүҗ-Мәэҗүҗе җимерде, чөнки татардан гайре аларга киртә булырдай бүтән кавем дөньяда юк иде» [Ислам: 2011].

***М. Рәмзи әсәренә Риза Фәхреддиннең бәяләмәсе***

«Шура» журналының 1908 ел 15 март (6-нчы сан) 180 сәхифәдә Морад Рәмзинең «Талфик әл-Ахбар вә талких әл-Асар фи вакаиг Казан вә Болгар вә мөлек әт-Татар» дигән баш астында Ризаэддин хәзрәт Фәхреддиннең мәкаләсе урнаштырылган. Анда «Шәех Мөхәммәд Морад әфәнде әл-Мәкки тарафыннан гарәби лисан илә язылмыш ошбу әсәрнең 716 биттән гыйбарәт булган беренче җилде Оренбург шәһәрендә «Горбунов-Хөсәенов вә шөрәкасе» матбагасында басылып тәмам улмыштыр», дип белдерелә. Автор әсәрнең әһәмиятен, аның татар тарихын өйрәнү өчен искиткеч зур роль уйнавын ассызыклый: «Бу әсәр исеменнән һәм аңлашылдыгы үзрә Казан, Болгар шәһәрләренең тарихлары вә боларның өсләренә килмеш олуг вә кечүк маҗараларны вә гомуми төрки вә татар ханнары вә бу мәмләкәттә булган исламларны тәгъриф (*таныту*) итмәк вә буннарның хәлләрне тәрҗемә ителмәктән гыйбрәттер. Беренче җилде исә Сарай шәһәре, Кырым ханнарыннан булган Миңлегәрәй хан тарафыннан тәхриб (*җимерү*) ителдекне сөйләп тәмам улмыш вә икен-

че җилд башыннан Хаҗитархан ханнары хәлләре сөйләнәчәкдер». Риза хәзрәт Морад Рәмзинең тарихи китапны нинди чыганакларга нигезләнеп язуын күрсәтә: «Шәех Морад әфәнде ошбу китапны иң могтәбәр булган гарәби, фарсы, төрки әсәрләрдән җәмигъ итмеш вә руслар кашында инабәтле (*ышанычлы*) булган Карамзин тарихыннан мәдехләрнең (*мактаулы*) иң җәзые (*өлеш*) булганнарына кадәр бер калдырмай дәреҗ (*урнаштырган*) итмештер. Ошбу беренче җилдендә авар, хун, сакалаб, болгар, чуаш, татар каумнәре хакында гаять мофассал (*тулы*) буларак мәгълүмат бирмештер». «Әлбәттә моңарчы да тарихыбыз турында әсәрләрләр бар, – дип яза мәкалә авторы, – әмма ләкин М. Рәмзинең тарихи хезмәте нәрсәсе белән үзенчәлекле, дигән сорауга «Морад хәзрәтләре ушбу әсәрен мәҗәррәд нәкыйл тарикы (*билгеле, ачык юлдан-фикердән китмичә*) илә тәртип итмәй бәлки мөәррихләрнең ихтилаф (*тарихчыларның каршылыклы*) итдекләре сүзләрене тәам күчердеге соң кәнди тарафыннан мәхкамә (*хөкем, тәнкыйть*) итмәк үзерендә язмыштыр. Бу исә китабә аерым бер өстенлек бирмештер». Риза хәзрәтләре китапны нәшер итү чыгымнарын үз өстенә алучыны да күрсәтә. «Ошбу бөек вә олуг масруфләр (*чыгымнар*) ихтыяҗлы булган әсәрне милләт өчен ядкяр калдырмак касд (*ният, максат*) илә хадим әл фукараи (*ярлы хезмәткәр*) шәех мөхтәрәм Зәйнулла хәзрәт җәнаблары (биредә сүз Троицкиның мәшһүр дин эшлеклесе Зәйнулла ишан Рәсүли (1833–1917) турында бара) кәнди хәраҗәт илә (*чыгым*) табиг итдермәктәдер».

«Милли тарихымыз, – дип дәвам итә автор, – русча белмеш мәгърифәтле шәкертләремез вә муллаларымыз тарафыннан языланачакны өмет итәр идек. Әмма Мәккә-и-Мөкәррәмәдә утырып мөритләр тәрбиясе илә мәшгүл булган бер шәех тарафыннан язылмасына хосуса бу илә затлар тарафыннан Карамзин тарихлары кылны кырыкка ярыр мәртәбәсенә дикъкать илә мөталәга нтеләчәкне хыялымыза улсын көтермез идек фәкать «вә йаи тик бәла хәбәр мән ләм түзуәди» (*Үзең белмәгән хәбәр сиңа да бер килер» борынгы гарәп шигыреннән), дип әйтәсе кала.*)

### *Төркия матбугатындагы бер хәбәр*

Морад Рәмзи шәхесе чит ил матбугатында да игътибар үзәгендә булган. Төркия газеталарының берсе [Вакыт: 1926. № 10] баш мәкаләдә «Казанлы мөәррих (тарихчы) Морад әфәнденең Истамбулга килүе» хакында хәбәр итә. Мәкалә ике фотография белән ачыла. Беренчесендә Кытай Төркестанындагы бер гыйбадәтханә манзарасы бирелгән. Икенчесендә – Морад хәзрәт. Эре план белән алынган рәсемдә башына түбәтәй кигән рәвештә сурәтләнгән. Редакциядә төшереп алынуы ихтимал.

Сүз уңаеннан, моңарчы безгә М. Рәмзинең берничә сурәте билгеле иде. Бер фотода хәзрәт уллары һәм кардәшләре белән төшкән. Алгы рәттә ак чал-

мадан, постаудан тегелгән ыспай казакидан, күзлекле, сирәк кенә сакаллы бер карт. Янә берничә фотосурәт Малик Чанышның «Кытайда татар мәгарифе тарихы» дигән китапта [Чаныш: 2007] бар. Беренчесендә Чүгүчәктә рус мәктәбе каршында М. Рәмзи, швед галиме Свен Һедин (Свен Андерс Һедин (1865–1952) – сәяхәтче, географ, язучы, җәмәгать эшлеклесе) һәм Хафиз карый (тарихчы Корбангали Хәмиди улы) белән, 1930 ел. Икенче рәсемдә М. Рәмзи тауларда гомер сөрүче казакълар арасында, Чүгүчәк, 1930 ел.

«Вакыт» гәзитендәге мәкаләнең беренче җөмләсендә үк кунакның күренекле галим-тарихчы, ике томлы «Талфик әл-Ахбәр» китабының авторы булуы, аның Кытай Төркестаныннан хосусый визит белән калага килүе турында хәбәр ителә. «Бу тарих төрки кауменең дуушына гаид (барлыкка килүенә карата) мөкаддимәе илә русларның казанлы татарга гаид мөзалимен тәшрих идәр (золымлык кылуын шәрех, аңлата)». «Вакыт» хәбәрчесе, тарихчы әлеге үзенчәлекле әсәрен гаять зур сабырлык вә хакыйкатькә тугры булып калу нияте белән иҗат иткән, дип ассызыклый. Әлбәттә, бу әсәр патша хакимиятенә охшап бетми вә тарихчы хөкемгә дучар була, дип белдерә. Морад әфәнде ике рус инкыйлабы арасында хиҗрәттә Мәдинәдә үткәрергә мәҗбүр ителә. Гаиләсен тәэмин итү өчен уку-укыту, дәрес бирү белән мәшгуль була вә буш вакытын «мәүзуг тарихны язмыштыр». Рус хөкүмәте галимгә карата хөкемен бары тик Романовларның 300 еллыгы уңаеннан гына өстеннән ала. Тарихчы Мәккәдән үзенең ватанына вә кардәш-ырулары белән күрешергә кайткан вакытта, рус-төрек сугышы башланып, Төркия ватандашы буларак, ул байтак михнәт чигеп, Төркестан, Бохара якларында җиде ел дәвамында шәйхелисламлык һәм мөдәррислек белән шөгыльләнә. Биредә ул, инде әйтелгәнчә, суфичылык, ишанлык мәсьәләләрен колачлаган мәшһүр дин-ислам галиме имам Раббанинның атаклы «Мактубат» дигән хезмәтен фарсы теленнән тәрҗемә итә. «Вакыт» гәзите Морад хәзрәтнең Истанбулга ике улы белән, күзләрен дәваларга килүен искәртә. Хәбәрче Кытай Төркестанында динкардәшләр төрки кавемнәрнең хәлләре турында да сораштыра. Дин тоту, мәгариф, мәдәният мәсьәләләре турында да фикер алыша.

Ахырда шуны да искәртик, әлеге мәкаләне эзләп табуда кардәшебез, Түбән Кама каласыннан Фатих хәзрәт Хәбибнең ярдәме зур булды.

***Күргәзмә, конференция***

2015 елның азакларында Кол Шәриф мәчетенең Ислам дине музеенда бер кызыклы гына күргәзмә ачылды. Бу чара Морад Рәмзинең тууына 160 ел тулуга багышланган иде. Әлеге биш-алты стендтан торган экспозицияне ачу тантанасында галим-голямадан, журналистлардан торган тар гына даирә катнашты. Әлеге вакыйга киң җәмәгатьчелек тарафыннан сизелми дә калды, ул матбугатыбызда да тиешле яңгыраш тапмады, дисәң

була. Ә шулай да анда куелган экспонатлар, әйтелгән тәкъдим-киңәшләр әһәмияткә ия. Чөнки биредә сүз Ислам диненең тарихына, үсешенә зур өлеш керткән бөек зат, безнең кардәшебез, якташыбыз турында барды. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин чыгышын Коръән сүрәсе укудан, галимнең рухына дога кылудан башлады. Мөфти хәзрәтләре Морад Рәмзинең искиткеч шәхес булуына игътибар юнәлдерде. Чыннан да, гаҗәпләнмәслек тә түгел, безнең төбәктә туып үскән, шушында күпмедер гыйлем туплаган ошбу зат, Урта Азия,Төркия, Гарәбстан мәдрәсәләрендә аң-белем эстәп зур абруй казанган, олы дәрәҗәләргә күтәрелә алган зат. Ул гарәп телен шул дәрәҗәдә үзләштергән ки, хәтта бүгенге көндә дә ул язган һәм тәрҗемә иткән китаплар кат-кат басылып, дәреслек сыйфатында хезмәт итә. Камил хәзрәт, әйтмешли: «Төрек кардәшләребез Морад хәзрәтнең олуг гыйлем иясе, мөселманнарның рухи остазы булуын таныйлар. Истанбулда шәех укыткан бинаны «Морад бәй мәктәбе», аның намаз кылган урыннарга кадәр хөрмәт итеп саклыйлар. Аңа карата нәкъ шундый ук мөнәсәбәтне гарәпләрнең фәнни-гыйльми даирәләрендә дә күзәтергә була. Алар галим тарафыннан иҗат иткән хезмәтләрнең теле турында сокланып, югары бәяләп телгә алалар. М. Рәмзинең язганнарының төп үзенчәлеге – галимнең Россия империясеннән читтә яшәп, эзәрлекләүдән курыкмый фикерен ачыктан-ачык белдерүе. Һәм иң мөһиме – галим Россиядә гомер иткән төркиләрнең тарихын альтернатив күзлектән карап иҗат итә. Аның хезмәтләрен бүгенге көндә гарәп илләрендә, аерым алганда Бәйруттa да китап кибетләре киштәләрендә очратырга мөмкин».

Хәзрәтнең сүзләрен куәтләп, галим-этнограф, тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков М. Рәмзинең Шиһабетдин Мәрҗани һәм Ризаэддин Фәхреддиннәр югарылыгындагы гыйлем иясе булуын әйтте. Әлеге бәяләмәнең безнең ватандашларыбыз арасында гына түгел, шәрык галимнәре арасында да киң таралуын искәртте. Дамир әфәнде шулай ук АКШ тарихчы-мөстәшрикләре арасында да М. Рәмзинең рухи мирасы игътибар үзәгендә булуын, фәнни хезмәтләр язылуы турында искәртте. Галимнең варислары белән бәйләнешкә кереп, аның архивын, шәхси әйберләрен Татарстанга кайтару мәсьәләсенә дә кагылды.

Бу вакыйгадан дүрт ел узгач, ягъни 2019 елның 12 апрелендә дип истә калган. Татар конгрессының бинасында М. Рәмзинең юбилее уңаеннан бер очрашу оештырылды. Фәрит Уразай бер атна алдан мине дә анда чакырды. Җомга көненә туры килүе сәбәпле, «Казан нуры» мәчетендә намаз кылганнан соң, Ирек мәйданына китеп бардым. Галимнәр, гаммәви матбугат чаралары вәкилләре, җәмәгать хәдимнәре катнашында уздырылган ошбу чара «Зыялылар мәҗлесе» дип атала икән. Чыгышыма әзерлек уңаеннан 40 битлек текст, фотолар әзерләгән идем, әмма оештыручылар, сүзне кыска

тотыгыз, нотык 5–7 минуттан артмасын, дип кисәтеп куйды. Мин, әлбәттә, моңа әзер түгел идем. Шул сәбәпле каушадым, колач җитмәслек теманы кыска вакыт аралыгына сыеп бетәрә алмавыма уфтандым, югыйсә әтрафлы гына әзерләнгән докладым белән аудиториянең игътибарын җәлеп итү иде ниятем. Бирелгән биш минутта нәрсәләр генә әйтә аласың! Беренче булып галимә Наилә Гәрәева чыгыш ясады, аннан соң рәис сүзне миңа бирде. Мин чыгышымны М. Рәмзи эшчәнлегенең матбугатта чагылышы темасына багышладым. Галим турында инкыйлабка кадәр чыккан язмалар, бүгенге көндәге гәзит-журнал, интернет сәхифәләрендәге кайбер материаллар турында хәбәр биреп киттем. М. Рәмзинең варислары, аларда саклана торган мирас турында да әйттем. Утырышның бик формаль төстә, ашык-пошык бер сәгать дигәндә үткәрелүе, Татарстан Илбашының фәрманын үтәү һәм шул турыда Конгресс беркетмәсенә «уздырылды», дип билге кую өчен генә үткәрелүе күңелемдә юшкын буларак утырып калды.

Казан университеты каршындагы фәнни китапханә фондларында Мөхәммәд Морад (әр-Рәмзи) тарафыннан язылган китап саклана. Аның исеме «Мөшәйәт хизбу р-рахман вә мөдәфигать хизбу ш-шәйтан» («Мәрхәмәт иясе таифәсенә итагать кылу һәм шайтаннан саклану») 1-нче кисәк, 80 б. 1912 елда Оренбургта Хөсәенов матбагасында нәшер ителгән; һәм шушы ук әсәрнең 2-нче җөзьэ 1913 елда нәкъ шул ук матбагада басылган.

1910–1914 елларда Морад хәзрәт актив рәвештә татар вакытлы матбугатында мәкаләләр бастыра. «Дин вә әдәб» һәм «Дин вә мәгыйшәт» журналларының сәхифәләрендә аның «Мәккә-и-Мөкәррәмәдә гүзәл бер тәшәббес», Мусага «Мәккә пүләмите», «Бөекләрнең араэ вә каләмнәренә даир бер-ике сүз», «Мәдрәсәи Хөсәения икъбалсез (*уңышсыз*) дияргәме?» һәм башка бик күп кызыклы, ул чорларда көн кадагына суга торган мәкаләләр дөнья күрә. Безнең заманда Рәмзинең мирасы өлешчә «Islam-today» интернет порталының Darulkutub сәхифәсендә чагылган.

Сүз уңаеннан, күптән түгел «Талфик»ның беренче томы Өфе каласында рус телендә нәшер ителде. Интернетта аны табарга була. Китапның керешендә һәм өстәмә рәвештә туплап бирелгән шәҗәрәләрдә кардәшләребез, гадәттәгечә, авторны сафтан-саф башкорт катлауга ялгарга онытмый.

Әмма моңа җирлек тә юк түгел икән шул. Ни гаҗәп, олуг галимнең тарихи китабы Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты бастырып чыгарган, Бөекбритания башкаласында тәкъдим ителгән җиде томлы «Татар тарихы»нда чагылмый диярлек. Хәер, Морад Рәмзинең исеме дә нибары өч урында узышлый гына телгә алына. Шундый мөнәсәбәт булганда безнең чиктәш җөмһүрияттәге кан-кардәшләребезгә дәгъва белдерергә хакыбыз бармы соң?

Җиде китаптан торган тарихыбызда М. Рәмзи беренче тапкыр 5-нче томда 530 биттә Г. Һидиятуллинаның XVIII г. икенче яртысы – XIX г.

башында Идел-Урал төбәгендә дини фикернең үсешенә багышланган мәкаләсендә телгә алына. Мәкалә авторы Бохараның Нәкышбәндийә-мөҗәддидийә шәехләренең ераклардан гыйлем эстәргә килгән шәкертләргә йогынты ясавы турында сүз алып барганда, күренекле дин әһелләре шәех Фәизхан Кабули һәм шәех Ниязколый Төркмәниләрне искә алып, алардан белем алган шәхесләр Ислам дине тарихында гаять тирән эз калдырулары ассызыклана. Аерым алганда, шәех Төркмәнинең безнең яклардан чыккан дистәдән артык шәкертнең остазы булуы искәртелә һәм шул җөмләдән Морад Рәмзинең дә исеме атала.

Икенче урында М. Рәмзинең исемен «Татар тарихы»ның алтынчы томында 375 биттә атаклы немец галиме, замандашыбыз Михаэль Кемперның суфичылыкка багышланган мәгълүм китабыннан алынган мәкаләдә очратабыз [Кемпер: 2008]. Автор әүвәлдә булган суфи тарикатьләре турында мәгълүмат нибары өч тарихи чыганакка таянып язылды, ди. Болар Ш. Мәрҗанинең «Мөстафа-дел-Әхбары...», Р. Фәхреддиннең «Асар»ы вә М. Рәмзинең «Талфик»ы... (Шуны да әйтергә кирәк Михаэль әфәнде Кемпер үзенең китабында тәсаувыфның татарлар арасында тамыр җәюе турында язганда сүзен дәлилләү өчен кат-кат Морад Рәмзигә мөрәҗәгать итә).

Һәм, ниһаять, шушы ук томның 384 битендә Ә. Сибгатуллинаның янә шушы ук суфичылык тарихына багышланган фәнни хезмәтендә М. Рәмзинең үз вакытында Мәккә каласында иң абруйлы Нәкышбәндийә тарикате шәехе вә бер үк вакытта мөҗавир (*дәрвиш*) булуын искә ала. Мәкалә азагында вак хәрефләр белән Морад әфәнденең Өфе губернасы Минзәлә өязендә тууы, дин әһеле, гыйлем иясе икәнлеге әйтелә. Аның дүрт ел Мәдинәдә укуы һәм хаждан соң Мәккәгә күченеп, озак вакытка шунда төпләнүе турында хәбәр ителә. Шуның белән вәссәлам!

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**


1. «Вакыт» газетасы. 1926, 10 июнь.
2. Ислам в мультикультурном мире. Материалы Первого Казанского международного форума. Казань, 2011.
3. М. Кемпер. Суфии и ученые в Татарстане и Башкортостане (1789–1889). Казань, 2008.
4. А. Тимергалин. Миллият сүзлеге. Т. 1. Казан: Тат. кит. нәшр. 2016.
5. А. Хәйретдин. Муса Җаруллаһ Бигиев хакында гыйльми хәбәрләрем. Казан, 2003.
6. Малик Чаныш. Кытайда татар мәгарифе тарихы. Казан: «Җыен», 2007.

## Исторические источники по краеведению

# ДОКУМЕНТЫ ЭПОХИ: ТАТАРСКО-БАШКИРСКИЕ ПРОТИВОРЕЧИЯ

В данном номере журнала представляются ряд материалов, характеризующих формировавшийся в границах БАССР, затем – в Республике Башкортостан, современный башкирский этнонационализм. Начальный этап его становления приходится на период позднего советского социализма и связан с деятельностью партийной номенклатуры этой республики, чьим идеологом выступал и известный этнолог Р.Г. Кузеев, о чем свидетельствует его записка в Башкирский обком КПСС (1986). Далее эта тенденция по усилению в этой республике этнонационализма прослеживается по приводимым в этой рубрике документам, сформулированным радикальными башкирскими националистами в постсоветский период. По публикуемым материалам отчетливо видна антитатарская направленность взглядов лидеров башкирского национального движения. Р.Г. Кузеев же выступает в качестве идейной предтечи указанного общественного движения. Полагаем, что знакомство с этими документами будет полезно как для исследователей, так и широкой общественности, включая краеведов.

* * *

# ОБРАЩЕНИЕ Р.Г. КУЗЕЕВА В БАШКИРСКИЙ ОБКОМ КПСС

*Приложение 3* *Копия*

В Башкирский обком КПСС

В январе 1989 г. состоится очередная Всесоюзная перепись населения. В связи с этим считаю необходимым информировать Вас о следующем.

I. После переписи 1979 г. в центральной печати, а также в Казани опубликована серия работ о языке, культуре и численности северо-западных, западных и юго-западных башкир (список части работ см. в приложении, № 1–15).

Основное содержание этих исследований сводится к утверждению о том, что всё тюркоязычное население западной Башкирии говорит на бар-

дымском, гайнинском, бирском, мензелинском, байкибашевском говорах среднего диалекта татарского языка и должно причисляться по родному языку к татарскому этносу. Другими словами, языковеды, историки, фольклористы ТАССР рассматривают разговорный язык и культуру тюркоязычного населения всей западной Башкирии целиком в языковой и культурной системе татарского этноса.

Аргументация этого тезиса в историческом аспекте имеет несколько вариантов:

а) Башкиры когда-то были исконными жителями западной Башкирии, однако после завоевания Русским государством Казани (XVI в.) в результате массовой миграции татар здесь формируется «сильно татаризованная группа башкир и испытавшая башкирское влияние татарская группа тептярей» (Садур, 1983, с. 3–4). К концу XIX в. происходит «полная ассимиляция» башкир в татарской среде и применительно к этому времени, тем более – к современности, их следует считать «принадлежащими к татарскому этносу» и, поэтому, исключить из числа башкир (Исхаков, СЭ, 1980, с. 30);

|---|---|---|---|---|---|
| | III | IV | | III | IV |
| Калейкино (рч. Нагайилка) | 72 | 97 | Сарсак Бли | 36 | 36 |
| Б. Батряс | 8 | 8 | Ср. Багряш (Сарсас Тамак) | 61 | 61 |
| Ток Чишма (Тавлы) | 54 | 54 | с. Петропавловск (Ляки) | 4 | 4 |
| Зичебаш | 71 | 74 | Ахтубы | 8 | 8 |
| Ерыклы | 42 | 56 | Нов. Кульменево (Ляки Тамак) | 13 | 13 |
| М. Ерыклы | 40 | 40 | | | |
| Ахтубя | 82 | 100 | Кушкачи | 62 | 62 |
| Светлое озеро | 101 | 115 | Сос. Мыс | 74 | 106 |
| Сурка-Байгулов | 58 | 58 | Бурды | 147 | 179 |
| Черем. Байдайкино | 56 | 56 | Танатмыш | 70 | 84 |
| По рч. Аты | 116 | 176 | с. Покровское (Налим) | 100 | 100 |
| с. Архангельское (Мелькени) | 52 | 90 | Нов. Шунак (Гуслятав) | 50 | 50 |
| Юшады Ниж. | 51 | 81 | Шубаян (Ильтень-Бутыт) | 70 | 73 |
| Нов. Мелькени | 56 | 56 | Иркино | 17 | 28 |
| Емаш (Сосновый) | 46 | 50 | Нов. Бухараево | 28 | 31 |
| Ниж. Урьмяды | 50 | 74 | Усак Баста (возле Куряково по рч. Мензеле) | 9 | 11 |
| Налим (рч. Укалы) | 26 | 27 | | | |
| Ср. Кадряково | 37 | 41 | Яйлев | 44 | 70 |
| Верх. Чална | 23 | 23 | Урваев (рч. Ирня) | 68 | 77 |
| Уразово | 20 | 20 | Иялитав | 36 | 44 |
| Чабьи | 33 | 33 | Нов. Сентяк (Иске Мунча) | 25 | 38 |
| Ниж.Бишево | 54 | 52 | М. Ерыклы | 1 | 1 |
| Кабан Бастырык | 69 | 69 | Тогашево (на о. Ускимень) | 38 | 78 |
| Чупай | 69 | 69 | Зычебалит | 1 | 1 |
| Алан | 10 | 10 | Увак Нарат (Баранчино) | 33 | 47 |
| Кленчи (рч. Шапшар) | 60 | 68 | Нов. Гардали | 31 | 51 |
| Нов. Пинячи (Тимерсу Алан) | 17 | 31 | Елантав (по рч. Зай) | 4 | 4 |
| с. Петропавловск (Ляки) | 62 | 70 | Бисипово | 12 | 21 |
| Башкитляр | 37 | 37 | Верх. Юшады | 97 | 106 |
| Мартыш (Бекчи Пустошь) | 39 | 39 | Савельево | 104 | 116 |
| Верх. Авлаш | 47 | 48 | Тонгузино | 1 | 1 |
| Нов. Багряш (Лысая гора) | 132 | 132 | Ургуды | 1 | 1 |
| Б. Ерыклы | 10 | 10 | Ст. Ашпала | 9 | 9 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Ниж. Кабан (Дюрт Мунча) | 36 | 42 | Игатево | 4 | 4 |
| М. Батряс (Драгуновка) | 7 | 11 | Ниж. Шукрале (по рч. Черне) | 1 | 1 |
| М. Багряш (Ерсубаево) | 78 | 96 | Ниж. Шипков | 4 | 4 |
| Серенкино | 11 | 11 | Ниж. Онбий | 9 | 9 |
| Бекечень Иванаево | 16 | 19 | Арасланово | 26 | 26 |
| Мушуги | 18 | 18 | Бурунчи | 39 | 39 |
| Степаново (Ниж. Абдулово, Степной ключ) | 3 | 19 | Чакмак | 5 | 5 |
| | | | Ниж. Ишады | 10 | 10 |
| Каин Илга | 2 | 2 | Ургункул | 8 | 8 |
| Ср. Кашир | 11 | 11 | Менли Батрас | 3 | 3 |
| Чишме (Янгыз Нарат) | 24 | 24 | Алансу | 5 | 5 |
| Нов. Елань (при рч. Кучуй) | 104 | 139 | Ниж. Бишево (рч. Ашит) | 15 | 17 |
| Елантау (рч. Зай) | 11 | 12 | Степаново (Клементево) | 36 | 36 |
| Черный ключ | 1 | 2 | Ниж. Лешев | 4 | 5 |
| Абдулово (Елхово) | 1 | 1 | Бикасас | 3 | 3 |
| Ниж. Буты | 36 | 34 | Баткас | 34 | 34 |
| Ашит Пустошь | 2 | 4 | Дыреево | 30 | 30 |
| Ср. Урмады | 79 | 96 | Ст. Баграш (Елховой ключ) | 8 | 8 |
| Акманово | 26 | 32 | Кирибурды | 2 | 2 |
| Урмяды | 3 | 19 | Уразаево | 4 | 4 |
| Серенкино | 58 | 66 | Шумыш | 2 | 2 |
| Серенкино (Б. Багряш) | 3 | 6 | с. Богородское (Акташ) | 150 | }416 |
| Тимирсян | 17 | 22 | -//- (Ашташ) | 234 | |
| Камышливраг (Уртамак) | 72 | 69 | Верх. Бутков | 133 | 156 |
| Пенячи (Темерсу Тамак) | 24 | 27 | Сыново Ст. Баграш | 32 | 42 |
| Янгыз Нарат (Пистеняш Чишма) | 12 | 12 | с. Николаевское (Курень Багряш) | 10 | 10 |
| Янгыз Нарат (Чишма) | 3 | 3 | Караельчи | 139 | 145 |
| Сармаш | 37 | 37 | Верх. Акташ | 168 | 233 |
| Бахметево | 24 | 43 | Солтанаево (Кузайкино) | 263 | 269 |
| Ахметево | 1 | 3 | Арбуз-Балчыклы (Бигеев Пустошь) | 44 | 53 |
| Шакшинар | 8 | 13 | | | |
| Чабуклы Елга | 23 | 28 | Мазино | 37 | 42 |
| Алкино | 3 | 4 | Кульменево | 4 | 11 |
| М. Ерыклы | 3 | 9 | Ниж. Мелекес | 61 | 61 |
| Верх.Челнов | 15 | 19 | Чады-Мелекес | 121 | 145 |
| Токтамыш | 8 | 8 | Козло-Кувак | 53 | 84 |
| М. Батряс (Гулкино) | 45 | 51 | Ширшилы | 32 | 41 |
| Кисков | 88 | 88 | Иванаев | 48 | 48 |
| Ниж. Кабан | 2 | 2 | Ст. Игинь (Наратлы-Биштово) | 42 | 42 |
| С. Бусеряк | 30 | 30 | Бештово | 25 | 31 |
| Абдулово (С. Багряш, Елховый Ключ) | 36 | 36 | Буракерты | 1 | 4 |
| | | | Тавлидрюш | 6 | 8 |
| М. Абдулово | 16 | 16 | Каран (Азиково Пустошь, Иски Мунча) | 72 | 100 |
| Ст. Ашпала | 35 | 35 | | | |
| М. Аты | 55 | 55 | Мазино (р. Кувади) | 5 | 11 |
| Ср. Кашир | 5 | 5 | Ниж. Чершилы | 5 | 5 |
| Ср. Бурда (Старая Пустошь Чукуч, Тат. Мазар) | 7 | 7 | Биситово | 5 | 5 |
| | | | Биситово | 5 | 5 |
| Нов. Аксарино (Асеево) | 25 | 25 | Шершили (рч. Аричимсан) | 10 | 12 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Ср. Ляшев | 38 | 57 | Нов. Гордали (рч. Шилна) | 25 | 25 |
| Юсупово (Аклык Чишма) | 1 | 1 | Ниж. Кувады (Сууксу) | 5 | 5 |
| Чершилы | 1 | 2 | Ниж. Нов. Ахметево | 5 | 5 |
| Чичебаш | 11 | 12 | Калмаш | 4 | 4 |
| Якшикево | 3 | 3 | | | |
| **Итого:** Чуваш ясашных старокрещен и новокрещен | | | | **6135** | **7134** |

***Мурз и татар, приписанных к Адмиралтейству:***

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Нов. Саклов (Сурунчак) | 7 | 12 | Тавлук | 55 | 55 |
| Варяшево | 47 | 47 | Бурунчи Чекан | 28 | 28 |
| Тимерчи (Черем пустошь) | 10 | 19 | Уразово | 12 | 12 |
| Махмутово (Багряш, Елхово озеро) | 33 | 47 | Ср. Челнов | 32 | 32 |
| | | | Биклянчи Карманово | 13 | 19 |
| Черный ключ | 115 | 171 | Якупово | 19 | 25 |
| Чукрали | 15 | 30 | Бекбулатово | 175 | 199 |
| Абдулово (Багряш) | 116 | 174 | Ст. Байраш | 2 | 5 |
| Беркет ключ | 82 | 132 | Янурусово (рч. Талбуга) | 2 | 3 |
| Ст. Багряш | 97 | 103 | Абдулово (рч. Ильбак) | 25 | 28 |
| Тойметкино (Черный ключ) | 107 | 109 | Асаново (Киркали) | 5 | 15 |
| Ниж.Челнов | 28 | 44 | Клементево | 32 | 44 |
| Чубар Абдулово (рч. Мелля) | 8 | 20 | Чекемак | 2 | 5 |
| Уртамак – дворовые из мурз старокрещен. Маметова | 3 | 3 | Милли Тамак | 1 | 4 |
| | | | Сармаш баш (Шуняк) | 1 | 5 |
| -//- Харитонова | 2 | 2 | Кызыл Чипчик | 5 | 10 |
| Черный ключ | 1 | 4 | Абдулово (Ильбак) | 7 | 12 |
| Казаклерово | 12 | 22 | Тойметово (Черный Ключ) | – | 18 |
| Меллитамак | 1 | 1 | Тогиледино | – | 15 |
| **Итого** | | | | **1100** | **1470** |

***Ясашных торговых татар:***

| Населенные пункты | Чис-ть ревизских душ по ревизиям | | Населенные пункты | Чис-ть ревизских душ по ревизиям | |
|---|---|---|---|---|---|
| | III | IV | | III | IV |
| Байряк (Чалнов, Токмак Каран) | 30 | 93 | Токмак Каран | 5 | 9 |
| Чалны | 1 | 7 | Нов.Ургуди | 3 | 3 |
| **Итого ясашных торговых татар:** | | | | **39** | **112** |

***Ясашных татар:***

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Нов. Ташлияр (поч.) | 2 | 8 | Бекчюрино | 4 | 8 |
| Ташлияр | 26 | 65 | Нов. Табын (рч. Камышлы) | 6 | 6 |
| Бюрган | 28 | 48 | Буляк (рч. Шиння) | 69 | 82 |
| Рангезертамак (рч. Мелля) | – | 2 | Нов. Актемир | 2 | 2 |
| Иркупер | – | 2 | Зай-Чишма | 21 | 33 |
| Тойметево | 11 | 11 | Кулметево | 3 | 3 |
| Муслюм (Севрели Каран, Чюпрели) | 1 | 11 | Чишма (рч. Чишме) новокр. | – | 24 |
| | | | (еще не крещеные) | 21 | – |
| Мелли Тамак | 10 | 43 | Кандыркуль | 5 | 8 |
| Янтово (рч. Мензеля) | 6 | 10 | Шуганово | 17 | 21 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Ерыкли Елга (Ялантау) | 11 | 15 | Карамали (Буляк, Таш Илга) | 39 | 39 |
| Калимово | – | 8 | Чебуклы | 53 | 53 |
| Кутемали | 9 | 9 | Пенячи | 22 | 22 |
| Саискан | 1 | 1 | Евлаш | 21 | 21 |
| Кандыркуль | 1 | – | Катык (Карин Мимак) | 9 | 12 |
| Крыккуль | 1 | 1 | Токеметево | 30 | 30 |
| Лешев Тамак (р. Мензеля) | 40 | 62 | Камышлы враг | 50 | 57 |
| Бурали (рч. Мелля) | 23 | 26 | Кабан бастырык | 41 | 43 |
| Маткауш Куяново | 28 | 29 | Верх. Луги | 57 | 57 |
| Беркет Ключ | 78 | 93 | Верх. Челны | 38 | 38 |
| Пустошь Ашит | 31 | 39 | Меллибаш | 54 | 54 |
| Бишево (рч. Камышли) | 29 | 21 | Еланкуль | 4 | 4 |
| Уруслутамак | 15 | 15 | Алансу | 36 | 56 |
| Тлянчи (Студ. Ключ) | 7 | 7 | Кудряково | 16 | 16 |
| Саискан | 28 | 35 | М. Шипки | 63 | 63 |
| Абдулово | 2 | 2 | Ураш Чишма | 19 | 18 |
| Нов. Тегерменник | 18 | 18 | Азяк | 13 | 13 |
| Буралы | 20 | 27 | Ашпале (Пайгул) | 18 | 18 |
| Верх. Урмяд | 12 | 12 | Шукрали | 19 | 19 |
| Верх. Кашир | 4 | 4 | Танасево | 52 | 52 |
| Турнас | 1 | 2 | Ниж. Челна | 40 | 40 |
| Шуган | 35 | 35 | Кызыл Чипчик | 50 | 50 |
| Толбуга | 9 | 9 | Терекли | 20 | 20 |
| Каинелга | 6 | 6 | Туба | 76 | 76 |
| Казаклар | 8 | 8 | Ниж. Кабан | 1 | 1 |
| Искимунча | 3 | 3 | Тимирсу (Черем. пуст.) | 16 | 16 |
| Ст. Ахмет | 8 | 8 | Ахметево | 54 | 54 |
| Алметево | 4 | 5 | Чакмак (р. Ик) | 20 | 20 |
| Чекмак (р. Ик) | 3 | 5 | Янтумяш баш | 10 | 10 |
| Сысангул | 8 | 10 | Бекленчи (рч. Еваш) | 33 | 33 |
| Содангу | 58 | 94 | Бекли Сарсас | 141 | 145 |
| Слияды | 2 | 2 | Чубар Абдулово | 2 | 4 |
| Кайриелга | 2 | 4 | Нов. Саклов | 2 | 3 |
| Бекбулат (р. Мензеля) | 38 | 39 | Игинь (рч. Шалчали) | 4 | 7 |
| Калмаш | 27 | 27 | Масягуково (Карамалы) | 8 | 8 |
| Бирган | 2 | 6 | Сармаш | 14 | 15 |
| Тавларево | 1 | 4 | Ниж. Кабан | 31 | 31 |
| Ст. Саклов | 1 | 1 | Чишма (Ялгыз Нарат) | 26 | 26 |
| Чубар Абдулов | 44 | 68 | М. Аурсали | 11 | 11 |
| Сарсал Мрали | 33 | 55 | Исангулово (Куюк Илга) | 4 | 4 |
| Ибраш Кубня | 6 | 7 | Ашпалп | 15 | 15 |
| Чуварт Зилга | 10 | 15 | Месягут (Карамали) | 108 | 108 |
| Атасево | 1 | 2 | Тавлерово | 36 | 49 |
| Ст. Игим | 10 | 10 | Мялим Верх. | 54 | 68 |
| По рч. Лешев | 4 | 4 | Верх. Чершилы | 72 | 85 |
| Куранды (Чикас Илга) | 30 | 30 | Ст. Дрюш | 2 | 4 |
| Изайкул | 2 | 4 | Явлаш (рч. Ашит) | 88 | 99 |
| Именкли (Сухой Катки) | 23 | 23 | Кутемели (Камышли) | 13 | 13 |
| Ерыкли Елантау | 22 | 22 | Ниж. Зичи | 41 | 41 |
| Ляки | 21 | 21 | Сармаш | 13 | 13 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дюсюмово (Карамалы Табак) | 155 | 155 | Табын | 16 | 20 |
| Исенбай | 7 | 7 | Верх. Кувады | 62 | 88 |
| Козешево | 9 | 9 | Ср. Лещев | 4 | 7 |
| Ашит | 33 | 33 | Ахтемир | 61 | 87 |
| Менделеево | 5 | 5 | Тавлук | 39 | 38 |
| Игентамак (сос.брод., Исангул) | 49 | 49 | Зибаш | 10 | 10 |
| Нов.Саклов | 19 | 19 | Клянчи Тамак | 42 | 42 |
| Кузечш(и) | 55 | 53 | Кугашево | 2 | 2 |
| Керепес | 65 | 58 | Буркерди | 96 | 96 |
| Бурали (Ильбак) | 49 | 69 | Миллярово (р. Сунь) | – | 3 |
| Дюсюлово (Карамали) | 59 | 86 | Ср. Кашир | – | 8 |
| Ташлык близ д. Шилганчи | 57 | 71 | Апасево (Чишма) В.К. | – | 8 |
| Кушнарат елга | 20 | 23 | Верх. Кашир | 6 | 6 |
| Шилганчи | 119 | 152 | Бикасас (Якшибай) | 12 | 12 |
| Малтобарово | 47 | 62 | Табыново | 6 | 6 |
| Кутемали | 24 | 24 | Тавли Дрюш | 16 | 31 |
| Кузембет | 1 | 5 | Ст. Тлянчино | 61 | 63 |
| Ташлияр | 1 | 3 | Чалпы (Асан Заитов) | 76 | 114 |
| Кушнарат илга | 26 | 29 | Чалпы (Ерыкли Елга) | 5 | 6 |
| Абдулово (рч. Ильбак) | 53 | 68 | Якупово | 12 | 13 |
| Маткауш (Медведево) | 70 | 91 | Тойгильдино | 16 | 20 |
| Канили (рч.Ерыкли) | 48 | 61 | Саклы Чураш | 32 | 39 |
| Искей Тегермен | 7 | 9 | Б. Бешандры | 45 | 74 |
| Усерган | 3 | 14 | Шукрали | 15 | 18 |
| Бектемир Пустошь | 91 | 100 | Иген бешанри | 34 | 34 |
| Уртамак | 24 | 26 | Туркаш | 47 | 47 |
| Сарали Бикметево | 20 | 20 | Кавзияк баш | 67 | 67 |
| Муслюмово | 7 | 16 | Асекеево | 77 | 77 |
| Натлы Челна | 5 | 10 | Ст. Гордали | 29 | 44 |
| Сарали Бикметево | 1 | 9 | Ст. Дрюш | 42 | 55 |
| Козеево | 59 | 72 | Сарсас Тегерман | 58 | 70 |
| Кулметево | 26 | 30 | Ляки | 8 | 9 |
| Кульметево рч. Ерыкли | 53 | 70 | Янурус (рч. Талбуга) | 38 | 45 |
| Тойгильдино | 1 | 4 | Иманово | 2 | 3 |
| Ниж. Чершилы | 16 | 16 | Сеитово | 98 | 97 |
| Чекмак | 42 | 66 | Нов. Акмистамак | 18 | 18 |
| Кугашев | 13 | 28 | Балымык | 5 | 8 |
| Верх. Саклы | 18 | 37 | Тойгильдино | 12 | 24 |
| Апасев (рч. Мартыш) | 12 | 19 | Кутусаз | 39 | 54 |
| Ургуд | 25 | 25 | Шикмаево | 98 | 107 |
| Козеево | 29 | 29 | Ширшили (Шанди Тамак) | 21 | 5 |
| Якшибай | 14 | 20 | Кашир (Камышлы Тамак) | 42 | 43 |
| Шукрали | 3 | 7 | Верх. Кашир | 6 | 6 |
| Якшибай | 36 | 55 | Мрясево (Иген Бешанди) | 83 | 83 |
| Яняк | 73 | 74 | Куперли | 87 | 87 |
| Саклов (рч. Зеля) | 27 | 50 | Азиково | 15 | 15 |
| Мендеево | 3 | 11 | Мартыш Тамак | 32 | 14 |
| Саколов (р. Сурунчак) | 43 | 72 | Шуган (Сарали) | 2 | 2 |
| Яшметов | 32 | 56 | Шигаево | 107 | 101 |
| Тузгунбаш | 2 | 2 | Енурусово | 24 | 33 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Уртамак | 15 | 15 | Калмаш | 1 | 1 |
| Кавзияк Тамак | 6 | 6 | Кызыл Чипчик | 1 | 1 |
| Куеди Сууксу | 114 | 118 | Байсарово | 1 | 2 |
| Ниж. Лешев | 78 | 79 | Ташлияр | 27 | 27 |
| Чекмак | 3 | 7 | Карамалы | 7 | 13 |
| Муслюмово | 1 | 6 | Кузлукувак | 12 | 21 |
| Сараас Устья Кавзияк | 8 | 11 | Мукаево | 1 | 1 |
| **Итого ясашных татар** | | | | **6387** | **7521** |

***Тептярей и бобылей:***

| Населенные пункты | Чис-ть ревизских душ по ревизиям | | Населенные пункты | Чис-ть ревизских душ по ревизиям | |
|---|---|---|---|---|---|
| | III | IV | | III | IV |
| Каймурзино | 1 | 6 | Кулметево | 7 | 7 |
| Заитово (Челны) | 4 | 5 | Арлак (рч. Мензеля) | 44 | 68 |
| Бимы | 38 | 115 | Муртыш Тамак | 1 | 2 |
| Тикашево | 11 | 21 | Талманас | 30 | 36 |
| Бязеково | 17 | 27 | Чераней | 37 | 58 |
| Ст. Кугаш | 8 | 12 | Казыкеево | 5 | 5 |
| Сарсас Такирмень | 4 | 4 | Мрясево | 23 | 33 |
| Бекбулово | 2 | 5 | Алимово | 4 | 4 |
| Актиелово | 5 | 7 | Актаныш | 43 | 77 |
| Янмурзино | 1 | 2 | Аишево | 12 | 24 |
| Сарсаз | 9 | 10 | Асалтуш | 3 | 7 |
| Беремово | 10 | 10 | Тат. Суксы | 1 | 1 |
| Кучуково | 24 | 32 | Бугады | 1 | 1 |
| Турнаташ | 1 | 3 | Бекбулово | 9 | 9 |
| Калмаш Псеево | 16 | 28 | Кыр Каин тюбе | 17 | 34 |
| Бексентеево | 20 | 31 | Мильяр | 41 | 67 |
| Янбулатово | 36 | 37 | Шабазбаш | 20 | 24 |
| Карасево | 34 | 48 | Маткауштамак | 11 | 15 |
| Измайлово | 5 | 10 | Именеево | 18 | 18 |
| Калларово | 5 | 5 | Урьяды | 51 | 57 |
| Азнакаеево | 17 | 20 | Тонгильдино | 7 | 7 |
| Амекеево | 42 | 46 | Лонгезар | 4 | 12 |
| Алтемирово | 18 | 18 | Топасево | 3 | 6 |
| Абдулово (Сухой Бешанды) | 42 | 96 | Аликсаз | 47 | 62 |
| Ятово | 26 | 26 | Ст. Тегермен | 59 | 68 |
| Курмаш | 53 | 56 | Тегермень подгорный | 7 | 8 |
| Игенбаш | 6 | 10 | Деметь Тарлов | 49 | 57 |
| Б. Мушугти | 1 | 2 | Ст. Ахметево | 31 | 45 |
| Кускеево | 19 | 19 | Егзититово | 2 | 3 |
| Чинниково | 19 | 19 | Меллитамак | 9 | 13 |
| Кадыкеево | 3 | 3 | Яна Ахметово | 7 | 13 |
| Касимково | 1 | 1 | Токталачик | 41 | 49 |
| Нов. Мелькени – крещ. типтяр. | – | 1 | Балтасево | 10 | 10 |
| Баймурзино | – | 4 | Азякуль | 3 | 3 |
| Теково | 3 | 8 | Мукшина | 28 | 33 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Елтимир | 5 | 14 | Варяш | 15 | 15 |
| Деуково | 35 | 58 | Таллимас | 1 | 1 |
| Иманово | 2 | 2 | Чугани | 7 | 7 |
| Суксу | 83 | 87 | Чубар Абдулово | 3 | 3 |
| Терпелей | 25 | 25 | Тамьяново | 41 | 41 |
| Сармашбаш (Ерыкли Елан) | 27 | 27 | Тагашево | 6 | 8 |
| Тонгузино (Чибинея) | 43 | 59 | Табын | 3 | 3 |
| Тулубаево | 6 | 6 | Тегерменник | 42 | 43 |
| Урусово | 16 | 16 | Саклавбаш | 20 | 22 |
| Караши Саклов | 4 | 4 | Тамьян | 5 | 7 |
| Ст. Байляр | 46 | 55 | Лангазар | 4 | 4 |
| Нов. Азкиешево | 23 | 23 | Саклавбаш | 4 | 4 |
| Байларово (Байсарово) | 33 | 43 | Кашкаран | 33 | 33 |
| Булер | 3 | 4 | Уразмет | 55 | 73 |
| Бекабыз | 14 | 14 | Клянчино | 40 | 65 |
| Кулуново | 4 | 4 | Кубяково | 27 | 28 |
| Кынчи | 4 | 5 | Амекеево | 37 | 47 |
| Нов. Алим | 11 | 13 | Ахуново | 9 | 17 |
| Кашир | 10 | 16 | Кулуново | 15 | 21 |
| Калымби | 10 | 11 | Мушуги | 9 | 9 |
| Сарманово | 16 | 31 | Альмет-Муллино | 45 | 45 |
| Кускеево | 12 | 12 | Ст. Буляр | 62 | 63 |
| Тавларово | 17 | 17 | Семяково | 18 | 18 |
| Кавзияк | 60 | 61 | Ниж. (Исти Елина) | 28 | 44 |
| Усаево | 13 | 27 | Ишикеево | 26 | 39 |
| Малтабар | 19 | 26 | Аккузеево | 8 | 10 |
| Кузембетево | 46 | 48 | Калтаково | 84 | 84 |
| Туки | 2 | 2 | Нуркеево | 1 | 6 |
| Иске Тигермень | 7 | 7 | Сарсаз | 5 | 6 |
| Селяково | 10 | 10 | Сарали Бикмет | 12 | 19 |
| Кугашево | 7 | 4 | Клянчи Тамак | 5 | 5 |
| Уртамак | 7 | 7 | Тегерменник | 28 | 42 |
| Ушуган | 26 | 29 | Башанди | 1 | 4 |
| Чекмово | 43 | 51 | Казакларово | 8 | 8 |
| Увариш | 5 | 7 | Караши Саклов | 3 | 3 |
| Шарлы Арема | 4 | 5 | Каскиново | 18 | 19 |
| Муртышбаш | 26 | 37 | Шуран | 12 | 21 |
| Айшеево | 8 | 12 | Семекеево | 3 | 7 |
| Акзино | 4 | 4 | Атрякли | 33 | 51 |
| Муслюмово | 49 | 85 | Осы | 53 | 60 |
| Леков | 8 | 8 | Урсали | 15 | 29 |
| Курманаш | 7 | 7 | Кузаково | 3 | 14 |
| Казаклерово | 4 | 6 | Буранчи | 8 | 8 |
| Измайково | 55 | 81 | Казгаляково | 2 | 8 |
| Куркеево | 28 | 28 | Каракково новокр. | – | 1 |
| Клянчи Тамак | 56 | 56 | Утяганово | 10 | 10 |
| Тонгильдино | 37 | 37 | Пепесово | 19 | 19 |
| Урмады | 18 | 18 | Шабаз баш | 2 | 2 |
| Меллитамак | 27 | 27 | Быргынды | 14 | 14 |
| Варяш | 23 | 23 | Атасево | 4 | 4 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Мерзешь | 1 | 1 | Чуганак | 6 | 6 |
| Сарсаз | 4 | 4 | Нов. Алимово | 25 | 25 |
| Наратово | 44 | 44 | Кадыкей | 3 | 3 |
| Каракуль | 23 | 23 | Ст. Алимово | 14 | 19 |
| Быргынды | 3 | 3 | Талнамас | 10 | 12 |
| Именеево | 22 | 22 | Айшеево | 2 | 5 |
| Киесов | 17 | 17 | Кулюково | 76 | 90 |
| Адаево | 6 | 6 | Тюки (Именево) | 41 | 41 |
| Азибей | 2 | 2 | Калмаш | 11 | 11 |
| Бекабыз | 16 | 16 | Поисеево | 43 | 43 |
| Усакли | 30 | 30 | Нарат асти | 3 | 3 |
| Уртамак | 4 | 4 | Карамалы | 3 | – |
| Наратово | 12 | 24 | Барсуково | – | 4 |
| Бекбулово | 48 | 59 | Аркинешь | 6 | 6 |
| Байтуган | 27 | 27 | Исенсупово | 86 | 87 |
| Тугашево | 1 | 1 | Поисеево | 112 | 119+2 |
| Шанчурино | 6 | 13 | Шанчурино | 54 | 65 |
| Табанаткуль | – | 1 | Анеково | 40 | 40 |
| Бишкумач | 43 | 52 | Такталачик | 7 | 7 |
| Билерово | 30 | 41 | Елтемир | 39 | 39 |
| Билямыш | 4 | 7 | Чупаево | 28 | 28 |
| Куяново | 2 | 2 | Чупликово | 28 | 28 |
| Ниж. Урьяди | 8 | 8 | Тегермен (Чуплик тамак) | 11 | 11 |
| Маткауш Тамак | 4 | 4 | Теке | 1 | 2 |
| Атрякли | 1 | 1 | Куяново | 1 | 1 |
| Балчиклы | 21 | 21 | Кашкумач | | 1 |
| **Итого тептярей и бобылей** | | | | *4181* | *5197* |

***Помещичьих [крестьян]***

| | | |
|---|---|---|
| Кадыкеево (рч. Сунь)<br>Майроши Дарьи Тевкелевой | 13 | 29 |
| Уртамыш<br>из мурз старокр. Василия Харитонова<br>дворовых из мурз старокр. Осипа Мамакова | <br>2<br>3 | <br>3<br>3 |
| 3. Верх. Ерыкли<br>служ. татарские мурзы Есупа Смаилева сына Яушева | 11 | 12 |
| Усмана Семенова сына князя Яушева | 8 | 8 |

*Текст к печати подготовлен Д.М. Исхаковым*

## Шәхесләребез

## Известные личности

*Г.Ш. Гатауллин*

# ИШМӨХӘММӘТ ЗӘИТОВ – БҮЗДӘКНЕҢ БӨЕК ЗЫЯЛЫСЫ

Исеме тарих төпкелендә калдырылып онытылуга дучар ителгәннәр арасында Ишмөхәммәт Заитов та бар. Заманында ул Идел-Урал төбәгендә, Ислам дөньясында киң танылу алган күренекле һәм абруйлы шәхес булган. Аның бөек мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанидән югары бәя алуы, Ислам гыйлеме галиме, мөфти Ризаэддин Фәхреддин тарафыннан дини эшчәнлеге җентекләп тикшерелүе һәм өйрәнелүе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Ишмөхәммәт 1750 елда (туган елы турында соңыннан да сүз булыр) Оренбург губернасы Бәләбәй өязенең Күбәк авылында (бүгенге Башкортостанның Бүздәк районы) туган. Шиһабетдин Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар» (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланган хәбәрләр) исемле әсәрендә тарихи вакыйгаларда нинди дә булса роль уйнаган тирән белемле руханилар турында язганда китабының икенче томында Ишмөхәммәт Заитовка да аерым туктала һәм аның шәҗәрәсен дә китерә: «Ишмөхәммәд бине Заид бине Бикмөхәммәд бине Әлмөхәммәд бине Алуш бине Урманчы бине Чытырман бине Аяз бине Бишмәт әл-Кибәки». «Биредә Ишмөхәммәднең унбер бабасы телгә алына. Аларның сигезе, ягъни: Бишмәт, Аяз, Чытырман, Урманчы, Кызылбай, Колаш, Кулыш һәм Алуш – саф төрки исемнәр, ә инде Әлмөхәммәд, Бикмөхәммәд, Ишмөхәммәд исемнәре – төрки катыш гарәп, Заһид исә – саф гарәп исеме. Димәк, Ишмөхәммәднең этисенең бабасы яшәгән чорда гына бу нәселдә (Ишмөхәммәд үзе 1750 елда туа, ата-бабаларына һәркайсына уртача 30ар ел чигергәндә, 1650-нче еллар тирәсендә) гарәп исемнәре кушыла башлаган. Ә аңарчы кушылган исемнәр буенча бу нәсел кешеләре яшәгән урыннарда урманлык-чытырлык булган, дигән фараз кылырга мөмкин. Чөнки төрки халыкларда да, Көнчыгыштагы башка халыклардагы кебек үк, җирсу, күк йөзе, табигать күренешләренә бәйле исемнәр киң таралган булган һәм ул гадәт XVII–XVIII гасырларгача сакланган» [Мәрҗани: 1989].

Шиһабетдин Мәрҗани язмасындагы «әл-Кибәки» сүзе-нисбә – Ишмөхәммәтнең ак бабасы Бишмәтнең туган төбәген – Кибәкне күрсәтә. Кибәк авылы бүгенге көндә Татарстанның Питрәч районына карый. Чал тарихлы әлеге авыл Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле.

1552 елда, Явыз Иван Казанны яулап алгач, Идел-Урал халыкларына карата бөтен җирдә суеш-үтереш, канга батырыш өстенә дингә каршы да сугыш игълан ителә – руслаштыру-чукындыру башлана: мәчет-мәдрәсәләр җимерелеп, алар урынына чиркәү һәм монастырьлар салына. Хокуксызлыкка, милли һәм социаль изүгә түзә алмаган Исламга тугры кешеләр яшәр өчен ифрат уңай, күп буш җирләр – Урал ягына күченә башлыйлар. «Нәкъ шушы вакыт Идел буйларыннан көнчыгышка халык агышы көчәя. 1719 елда, мәсәлән, Казан төбәгендә 19932 крестьян йорты бушап кала» [Социалистик Татарстан: 1990].

Шул сәбәпләр аркасында Ишмөхәммәтнең борынгы бабалары, туган төбәкләре Кибәкне калдырып, әлеге Башкортостан Республикасы ягына күченәләр һәм Күбәк авылында тамыр җибәрәләр. Ишмөхәммәт Заитов рәсми язмаларда «башкорт, типтәр даирәсеннән» дип искә алына.

Мәгърифәтче, галим, дин белгече Ризаэддин Фәхреддин дә үзенең «Асар» хезмәтендә Ишмөхәммәт хаҗиның дини эшчәнлеген ихтирам белән искә ала, аның тирән белемле дин белгече, галим, мөдәррис һәм мөгаллим икәнлеген раслый.

Риза Фәхреддин Ишмөхәммәт Заитовның тормыш юлын, дини эшчәнлеген өйрәнгәндә Күбәк авылына да килә. «Бу шәҗәрә, нәсел нәсәбенең кулында булган берничә нөсхәсеннән күчереп бу җирдә язылды, – дип күрсәтә ул «Асар»да. – Бәләбәй өязендә Күбәк авылында имам вә мөдәррис булып, 100 яшендә, 1256 елның зөлхиҗҗәсендә (1841 ел) вафат булган. Кабере өстендә булган ташы югалганга, яңадан икенче таш куелып, болай язылган: “Хаҗи, ахун Ишмөхәммәд Заидов, вафат булды 95 яшендә (Кәмәрия (Ай) ел хисабы белән 100 яшь ахыры була), 1 февраль, 1841 елда, яздым мин Габделлатыйф Ишмөхәммәд угылы 1870 ел 3 сентябрьдә”».

«Ишмөхәммәд хәзрәтләре яшь вакытында укый-яза белгәннәрдән булмый, – дип дәвам итә Р. Фәхреддин. – Авылдагы гади халык балалары илә берлектә вакытында эшләп, вакытында рәхәт чигеп, көн уздыра торган булган. Җырларга маһирлыгы сәбәбеннән, һәртөрле мәҗлесләргә чакырылып, төрле кешеләрнең кәефләрен күтәрә торган булган. Кыска вакыт эчендә скрипка уйнарга өйрәнеп, үзе кебекләр арасында кызыгырлык бу ике һөнәрне бергә туплаган. Шушы хәлендә яшәгәндә өйләнгән вә 22 яшендә, көннәрнең берендә, авылдан югалган».

Нигә Ишмөхәммәт, һич көтмәгәндә, беркемгә берни әйтми, туган авылы Күбәктән чыгып киткән? Ни кергән аның җырга-моңга бай күңе-

ленә? Аның һич көтелмәгән әлеге адымы сәер бер хәл була. Күбәк, пошаманга төшеп, шым кала – егетнең моңы авыл өстенә сибелми, скрипка кыллары күңелләрне сызмый инде хәзер.

Пугачев күтәрелешеннән соң XVIII гасыр азагында Русия империясендә мөселманнарга карата сәясәт йомшара башлый. Патшабикәнең 1783 елдагы Указы мөселманнарга ахуннарны үзләренә сайларга рөхсәт итә. 1784 елда татар морзаларына дворян хокукы бирелә; 1788 елның 22 сентябрендә Екатерина II Уфада Диния нәзарәте оештыру турында Указ игълан итә.

Үз гомерен Ислам диненә хезмәт итүгә багышларга ниятләгән Ишмөхәммәт, хаҗ кылгач, сигез ел Каһирәдә яши һәм мөселман уку йортлары арасында иң күренеклесе булган «Әл-Әзһәр» мәдрәсәсендә укый. («Әл-Әзһәр» мәдрәсәсе 1961 елда университет дип игълан ителде.) «Әл-Әзһәр» мөселман руханилары, шәригать нигезендә эш итүче казыйлар, мәдрәсә мөгаллимнәре әзерләгән. Әлеге мәдрәсәдә гыйлем алган кешенең абруе дин тотучылар арасында ифрат зур була.

Ишмөхәммәт хаҗи мәдрәсәдә укыганда бик өлгер, җитез акыл йөртүче фикер иясе һәм Коръәнне үзенчә матур итеп көйләп укучы буларак шөһрәт казана. Шәкерт чагында Ишмөхәммәт күп вакытын китап күчереп язуга багышлый. Аның каллиграфиясе бик матур булганлыктан, ул күчергән китапларга сорау зур була. Шулай ук күп акыл ияләренең, тарихчыларның хезмәтләре белән таныша, аларны өйрәнә. Гарәпчә, фарсыча һәм төрекчә иркен сөйләшә башлый.

Ишмөхәммәт хаҗи туган якларына үзе күчереп язган, аныңча сирәк очраган «Әл-миркате шәрхел-мишкят» китабын алып кайта. Алты кисәктән торган әлеге китапны мөфти Шаһингәрәй улы Сәлимгәрәй Тәвкилев сатып ала һәм файдаланыр өчен Килем авылы мәдрәсәсенә бирә. 1897 елның 12 маенда булган янгында әлеге китап янып юкка чыга.

Ишмөхәммәт хаҗи үзе кулланган «Фәтавый» китабы Уфа Диния нәзарәтендә саклана. Әлеге китапның бер битенә Ишмөхәммәтнең үз кулы белән: «1823 елның 13 гыйнварендә казага калган намазларымны янәдән каза кылырга башладым, мин фәкыйрь хаҗи Мөхәммәд, гәрчә сәфәр йөргәндә үтәгән булсам да», – дип язылган.

Ишмөхәммәт Заитовның нәсел дәвамчысы Равил Шаһгали улы Ишмөхәммәтовта искереп, таушалып беткән, күп урыннарда язулары да җуелган кульязма китап саклана иде. Аның да тышына: «Шәех Мөхәммәд Трабзони Мәдәнинең – Әл-Итхәфәтүс-Саниә фии-Әхәдис әл-Кудсиә (Изге Хәдисләр) китабын тәрҗемә кылып күчердем мин, хаҗи Мөхәммәд», – дип язылган. 1978 елның июлендә әлеге кульязма китапның укырга мөмкин булган бер өлеше безнең тарафтан күчерелеп алынды. Ишмөхәммәт хаҗи гарәпчәдән тәрҗемә иткән Изге хәдисләр бүгенге әдәби

тел таләпләренә яраклаштырылып тәкъдим ителә. Аларда, инде гасырлар үтсә дә, Ишмөхәммәтнең кул җылысы тоела, күз нурлары чагыла кебек.

Хиҗазда кайсыбер шәехләргә ышаныч китереп суфыйлыкта рөхсәте булса да Ишмөхәммәтнең мөрид (рухани җитәкчесенең эзеннән баручы) тәрбияләүгә теләге булмый һәм ул, «Әл-Әзһәр» мәдрәсәсен тәмамлагач, Бохарадагы «Күгелдаш», Сәмәркандтагы «Хуҗа Әхрар» мәдрәсәләрендә шәкертләрне Коръән уку серләренә төшендерә. 1783 елда Казан шәһәренең беренче мәчете каршындагы мәдрәсәдә укучыларга сабак бирә. Әлеге мәчет Екатерина IIнең махсус Указы белән салына, ул Казан шәһәренең тарихына, халык язмышына аерылгысыз рәвештә бәйле, үзендә бик борынгы хатирәләрне саклый (бу мәчеттә соңыннан, 1849–1889 елларда, имам булып Шиһабетдин Мәрҗани хезмәт итә. Хәзер ул мәчет «Мәрҗани» исемен йөртә). Әлеге мәдрәсәдә эшләгән чорында Ишмөхәммәт хаҗи Коръәнне матур итеп көйләп яттан укуы, матур язуы һәм тирән гыйлеме белән зур абруй казана.

Ишмөхәммәт хаҗи, Казан шәһәренең байлар мәхәлләсендәге мәчет (хәзерге Апанай мәчете) каршындагы мәдрәсәдә укытканнан соң, ак бабаларының туган төбәге Кибәк авылы мәдрәсәсендә шәкертләрне Коръәнне дөрес һәм матур итеп көйләп укырга өйрәтә.

Кибәктән Ишмөхәммәт хаҗи, мәдрәсә җитәкчесе Габделгалләм хәзрәтнең чакыруы буенча, Иж-Бубый авылы мәдрәсәсенә (бүгенге көндә Татарстанның Әгерҗе районына карый) эшкә килә. Ул дәвердә Вятка губернасының Сарапул өязе составындагы Иж-Бубый авылында ачылган мәктәп соңыннан мәдрәсә итеп үзгәртелә. Вакыт үтү белән әлеге уку йорты мөселман мәгърифәтчелегендә бик кирәкле үзәккә әверелә. Белемгә омтылган яшь егетләр, Русиядән генә түгел, Польшадан, Литвадан, Себердән, Төркестаннан бәләкәй генә авылдагы шушы мәдрәсәгә укырга киләләр. Уку 12 ел дәвам иткән. Программага алгебра, геометрия, тригонометрия, физика, биология, Русия һәм Шәрык тарихы, география, француз, рус, төрек, гарәп телләре кергән. Монда Коръәнне өйрәнүгә, аны дөрес һәм матур итеп укуга аеруча нык игътибар бирелә.

Габделгалләм хәзрәтнең өлкән улы Габдулла Буби, атасы мәдрәсәсен тәмамлагач, аңа ярдәмче мулла булып урнаша. Ул мөселман гыйлемендәге яңа юнәлеш белән мавыга һәм үзе дә китаплар яза. Аның язуы буенча, мәдрәсә тарихында Коръәнне Ишмөхәммәт хаҗи кебек матур һәм дөрес итеп укыган, аны шәкертләр күңеленә үтеп керерлек итеп аңлаткан, искиткеч матур каллиграфияле мөгаллим моңа кадәр булмаган.

Һиндыстан һәм Урта Азия дәүләтләре белән сәүдә итүне тагын да киңәйтү максатында, Екатерина II идарә иткән дәвердә Оренбургтан дүрт чакрым читтә Алыш-биреш йорты – ярминкә төзелә башлый һәм ул 1758 елда тәмам-

лана. Бик зур мәйданны биләгән, таш кибетләр белән уратылып алынган әлеге төзелеш ныгытма рәвешендә була, анда 329 кибет эшләгән. Ел саен, август аеннан октябрьгә кадәр Алмаш (Меновой) ярминкәсенә Хива, Бохара, Һиндыстан һәм башка дәүләт сәүдәгәрләренең кәрәваннары килгән. Ярминкәнең даны еракларга таралып, товар әйләнеше дә арткач, Алмаш ярминкәсе биләмәсендә таштан мәчет һәм чиркәү төзелә.

1789 елның 17 сентябрендә генерал-губернатор Аким Иванович Апухтин Ишмөхәммәт Заитовны «Меновой» (Алмаш) мәчетенең мөдәррисе итеп тәгаенли һәм мәчет эшчәнлеге өчен кирәкле кешеләрне билгеләүне аңа тапшыра. 1790 елда, Ишмөхәммәт хаҗи Каргалы бистәсе мәчетенә мөдәррис итеп күчерелгәч, «Меновой» мәчете мөдәррисе вазифасын Бөгелмә өязенең Баулы авылында туган Мансур улы Мөслим башкара.

Каргалы бистәсе заманында Оренбург төбәгенең мәшһүр мәгърифәт, мәдәният үзәге булган. Ул 1744 елда Оренбург шәһәреннән унсигез чакрым төньяктарак, Каргалы суының Сакмар елгасына койган урынында төзелә башлый. Аңа патшабикә рөхсәте белән Казан губернасыннан күчерелгән 200ләп татар гаиләсе нигез сала. Заманында танылган шагыйрь, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, Каргалы бистәсендә туган Каргалый Әбелмәних Ишмөхәммәт хаҗиның шәкерте була. Соңыннан Каргалый Әбелмәних үз язмаларында мөгаллимен тирән ихтирам белән искә ала.

Чыгышлары белән дөньяга билгеле Ислам дине үзәге булган Харәзмнән Ширнияз улы Ишнияз һәм Багдадтан Хәсән улы Вәлиятдин Ишмөхәммәт хаҗиның эшчәнлеген югары бәяләп: «Ул шәкертләргә генә түгел, ә безгә – мөгаллимнәргә дә остаз булды», – дип язалар истәлекләрендә.

1793 елда, мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов тәкъдиме белән, Ишмөхәммәт хаҗи Оренбургта бай казакъ балалары өчен ачылган мәдрәсәдә шәкертләрне Коръән уку серләренә төшендерә башлый.

Ишмөхәммәтнең якташы, фикердәше, Уфа өязенең Солтанай авылында туган Мөхәммәтҗан Хөсәенов Каргалы авылы, Бохара, Кабул, Оренбург мәдрәсәләрендә югары дини белем ала һәм өстәмә рәвештә Ишмөхәммәт хаҗидан Коръәнне көйләп уку осталыгына өйрәнә. Ул Көньяк Уралда Екатерина IIнең эчке сәясәтен тормышка ашыруда булышлык итә, Русия империясенең Урта Азия, Көнчыгыш һәм Төньяк Кавказда үткәргән тышкы сәясәтендә актив катнаша. Мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов, иң беренче чиратта, казакъ далаларында үз йогынтысын көчәйтергә теләп, экспедиция оештыра һәм үзе белән Ислам дөньясында зур абруй казанган Ишмөхәммәт хаҗины да ала. Юл күрсәтүчеләре – Оренбургтагы чик буе комиссиясендә хезмәт итүче калмык Әнүр Салбай була. Алар далада, кышлаудан-кышлауга күчеп, старшиналар, мулла һәм солтаннар белән очрашалар. Мөфти Мөхәммәтҗан үз вәгазьләрендә Ислам дине,

Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәяхәтләре турында сөйли, хәдисләр бәян итсә, Ишмөхәммәт хаҗи Коръәнне яттан матур итеп укуы белән җыелган кешеләрне әсир итә. Очрашып сөйләшүләр бик җиңелдән булмаса да уңышлы тәмамлана, урыс империясенең йогынтысы дала ягында сизелеп көчәя. Икенче елны мөфти, үзенә юлдаш итеп Ишмөхәммәт хаҗины да алып, берничә тапкыр башкалага юл тота һәм ел ахырында, ниһаять, алар патша белән очрашу бәхетенә ирешәләр.

Ишмөхәммәт хаҗиның күпкырлы һәм кайгыртучан остаз булуының тагын бер дәлилен искә алмыйча булмас.

1799 елда, Ишмөхәммәт хаҗи тәкъдиме һәм фатихасы белән, Оренбург җәмигъ мәчетенең имамы һәм мөдәррисе итеп Габдессәләм Габдрәхимов тәгаенләнә. Ул чорда остазыңнан фатиха алу зур ышаныч, дәрәҗә булып саналган һәм фатихалы кеше өчен һәр юл да ачык була.

Габдессәләм Габдрәхимов 1765 елда Самара губернасының Бөгелмә өязе Габдрахман авылында туа. Казан шәһәрендә Ишмөхәммәт хаҗи хезмәт иткән беренче мәхәллә мәдрәсәсе шәкерте була, Каргалы авылы һәм Оренбург шәһәре мәдрәсәләрендә укый. Оренбург мөселманнары, казакъ ханнары арасында Габдессәләм Габдрәхимовның абруе бик зур булган. Ханнар аның мәдрәсәсенә балаларын укырга җибәрәләр. Ул балалар, үсеп җитеп үзләре хан, солтан буларак, укытучылары янына төрле киңәшләр сорап килгәннәр.

1825 елның 30 сентябрендә Оренбург ахуны Габдессәләм Габдрәхимов Оренбург диния нәзарәтенең мөфтие тиеп тәгаенләнә.

1826 елның 15 февралендә янәдән Ишмөхәммәт хаҗи тәкъдиме белән Габдессәләм Габдрәхимов мөфти итеп тәгаенләнә. Иң беренче эше итеп ул урындагы идарә органнарына төзеләчәк нәзарәт бинасының проектын тәкъдим итә. 1829 елда яңа мөфти гражданлык актларын теркәүне тәртипкә сала, хәзер теркәү акча түләп башкарыла башлый һәм кергән акча махсус исәпкә туплана. Оренбург далаларында башланган остаз белән шәкертнең дуслыгы, хезмәттәшлеге 1840 елның 31 гыйваренә кадәр, Габдессәләм Габдрахимов бакыйлыкка күчкәнче, дәвам иткән.

Мөфтинең үгетләве, тәкъдиме нәтиҗәсендә сәүдәгәр Мөкмин Таһиров 1830 елда Уфада 1-нче җәмигъ мәчетен төзи. Аны ачу тантанасына Ишмөхәммәт хаҗи да чакырыла.

### *Туган якларга кайту*

Җәяүләп хаҗ сәфәренә чыгып киткән Ишмөхәммәт, күп илләр, җирләр гизеп, егерме биш елдан соң гына туган авылы Күбәкнең туфрагына аяк баса.

«...Бу вакытта яшьләре дә 47 булган икән. Фәкать бу юлы “скрипкачы Ишмөхәммәд” түгел, бәлки галим вә фазыйль Ишмөхәммәд хәзрәт

буларак мәйданга чыккан. Байлыгы күп булып, тегермән вә кярханәләр (остаханә, фабрика) салып, күп урман вә җирләргә ия булган», – дип яза Риза Фәхреддин [Фәхреддин: 2006. 174 б.].

Ишмөхәммәт хаҗи, Фатыйма исемле кызга өйләнеп, гаилә кора. Фатыйманың нәсел-нәсәбе белән Риза Фәхреддиннең «Асар» хезмәтеннән танышып була (Кара: [Фәхреддин: 2006. 40 б.]). Күбәк килене Фатыйманың затлы нәселе турында тулырак танышу өчен Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» әсәрендә бирелә (Кара: [Мәрҗани: 1989. 297–298 бб.]).

Фатыйманың туган ягы – Малмыж өязенең Адай авылы 1780–1920 елларда Вятка губернасының административ-территориаль бүленеш берәмлеге, үзәге – Малмыж шәһәре. 1780 елга кадәр Казан губернасы биләмәсенә кергән төбәк. СССРны районлаштыру барышында бетерелә, биләмәсе Киров өлкәсенә һәм өлешчә Татарстанга керә. Адай авылы бүгенге көндә Татарстанның Кукмара районына карый. Вятка елгасының уң кушылдыгы Бөре буендагы Адай 1678 елдан ук тарихта билгеле авыл.

Ишмөхәммәт хаҗиның гаилә хәлен ачыклар өчен, янә «Асар»га күз салыйк: «Ишмөхәммәднең балалары Мөхәммәдлатыйф, Габделлатыйф, Габделҗәббар, Маһитаб һәм башкалар. Бер кызы Әмирхан угылы Габделгани ахун никахында. Икенче кызы Маһитаб Шаһкол (Шакул) фамилиясеннән бер затка никахланып, Мәликә исемле кызны дөньяга китергән. Мәликә исә кенәз Сәлимгәрәй Әлмаксудыйга кияүгә бирелгән. Мөхәммәтлатыйф исемле угылы Күбәк авылында имам вә ахун булган», – дип яза Риза Фәхреддин.

Ишмөхәммәт хаҗиның тагы да ике улы бар – Гатаулла һәм Абдулҗәлил. Гатаулла бик яшьли – тугыз яшендә (1809–1819) мәрхүм була, Абдулҗәлил Күбәк авылы мәчетендә өлкән мулла, мөгаллим вазифасын башкара.

1797 елда ахун дәрәҗәсенә лаек булган Ишмөхәммәт хаҗи, кайткач, Күбәк мәчетенең имамы һәм мөдәррисе итеп тәгаенләнә. Иң беренче эше итеп, үз исәбенә мәдрәсә өчен аерым бина төзетә башлый, ә ул әзер булганчы шәкертләрен өендә укыта. Аңардан сабак алырга күрше-тирә авыллардан да киләләр. Ишмөхәммәт мөгаллим дәресләрен яңача алып барыр булган, гади, аңлаешлы итеп аңлаткан, шәкертләр дүрт-биш айда укырга-язарга өйрәнгәннәр.

Коръәнне яттан белгән Ишмөхәммәт хаҗи шәкертләрен Коръәнне дөрес һәм матур итеп көйләп укырга гына түгел, ә аның телен, стилен һәм терминологиясен дә өйрәткән. Ул Коръән-Кәримдә очраган терминнарның (мәсәлән, «хәниф», «бәшәр», «адәм», «бәнү адәм» һ.б.) һәрберсенә дә аерым күренеш, мәгънә салынганлыгына басым ясый, Коръәндәге һәр аерым сүзне дә бары тик контекста гына өйрәнү зарурлыгын аңлата.

1831 елның 23 декабрендә Күбәк авылының җомга мәчете «җәмигъ мәчете» итеп үзгәртелгәч тә аның имамы, мөдәррисе итеп янә ахун Ишмөхәммәт хаҗи сайлана һәм тәгаенләнә.

Ислам тәгълиматын таратудагы хезмәте, мөселманнар арасында патша хөкүмәтенең сәясәтен үткәрүдәге эшчәнлеге өчен ахун, хаҗи Ишмөхәммәт Заитов югары даирәләрнең Мактау Аттестатларына лаек була, ә 1833 елның 30 октябрендә, патша указы нигезендә, дин әһелләренә бирелә торган иң югары бүләк – Көмеш медаль, язулы Анна лентасы белән бүләкләнә. Гомеренең соңгы елларында патша хөкүмәтенең Бронза медаленә лаек була [Башкортстан дәүләт үзәк тарих архивы. Ф.И-295. Яз. 4. Эш-5940].

Ишмөхәммәт хаҗи авылдашларына, якташларына дини йолаларны дөрес итеп башкаруда да ярдәмләшә, дөньяви мәшәкатьләргә дә вакыт таба тынгысыз җан иясе – Идәш елгасында су тегермәне корып җибәрә. Тегермәнгә килүчеләрдән алына торган бер өлеш онны Ишмөхәммәт хаҗи ярлы яшәгән авылдашларына биреп барган.

Язуы-каллиграфиясе ифрат гүзәл булган Ишмөхәммәт хаҗи шәмаил эшли торган остаханә дә ачып җибәрә. Шәмаил – бизәп язылган дога, аять, изге сүз. Шәмаилләрнең кайчан, каян һәм ничек барлыкка килүе сер пәрдәсе артына яшеренгән. Халык аларны «аятел-көрси», «дога» дип тә атап йөртә. Ишмөхәммәт хаҗи остаханәсендә эшләнгән шәмаилләр сыйфат ягыннан бик югары була һәм алар мөселман халыклары яшәгән бик күп төбәкләргә – Казан, Уфа, Оренбург, Казакъстан, Урта Азия якларына таралган.

Ишмөхәммәтнең язылган догалары халык авыз иҗатында да чагылыш тапкан. Нәселенең чыгышы белән Күбәк авылыннан булган, ә картлыгында Алан авылында (хәзер Бүздәк районы – И.Г.) яшәгән Хәбибә Маннурова үзе иҗат иткән мөнәҗәттә:

«Юл буенча укып килдем,
Ишмә сызган догасын.
Тәкъдиргә шулай язгач,
Ничек аны бозасың», –

дип язган. Мөнәҗәттәге «Ишмә» исеме «Ишмөхәммәт» исеме белән бәйле. Әлеге исемнең халык телендә байтак кына фонетик үзгәрешләргә дучар ителеп: Ишмөхәммәт – Ишми, Ишмә, Ишмүк, Ишмәт формасында кулланылуы гадәти күренеш. Мәсәлән, «Бикмөхәммәт» исеме – Бикмәй, Бикмүш, Бикмәт, Бишмәт, дип тә әйтелгән.

Күбәк һәм Таулар авылларын салкын җилләрдән сакларга теләгәндәй бөгәрләнеп яткан Илбай тавы итәгендә безнең көннәргә «Ахун тугае» исеме белән килеп ирешкән төбәк бар. Табигатьнең матур да һәм бераз серле дә шушы урынына якын гына Уба сырты калкып тора, әрәмәлекләрендә борынгыда тамырланган карлыганнар әле дә татлы җимешләрен бирәләр.

Уба үзендә ниндидер сер саклыйдыр сыман, чөнки борынгыда, гадәттә, Уба ата-бабалар җирләнгән изге урын булып исәпләнгән һәм кешеләр анда килеп ак бабалары рухына дога кылганнар.

Убадан ерак та түгел, Илбай тавы куеныннан агып чыккан чишмә ягында, Ишмөхәммәт хаҗиның умарталыгы булган, якында гына Тарлау басу җәйрәп яткан («Тарлау» – болын яки урман уртасындагы аерым басу мәгънәсен аңлата). Әлеге җирләргә, урманнарга Ишмөхәммәтнең ата-бабалары 1707 елдан ук хуҗа булганнар.

Ишмөхәммәт хаҗи җирләренең күршесендә Шәхмәй Смаилов (Исмәгыйлев) биләмәсе булган. Аның җир алу турындагы килешү кәгазе Башкортостан дәүләт үзәк тарих архивында [Ф. 10. Яз. 1. Эш-1278. 13 б.] саклана. Шул документтан өзек китерик: «…лете 1740 марта 24 дня Уфимского уезда Казанской дороги Канлинской волости башкирцы, а именно деревни Сабаевой Сюлюк Сюлюков, Ишим Князев, Умир Якупов, Юнус Булатов, деревни Кубяковой Айдан Атиев с тов.будучи в Уфе дали сию тое же Казанской дороги Енейской волости башкирцам, а именно, деревня… Сосновой Шахмию Смаилову… в том припустили мы Сюлюк и Ишим с товарищи на вотчинную свою землю». Документ-килешүдә исемләнгән Шәхмәй Смаилов безнең тарафларга әлеге Татарстанның Балтач районы Сосна авылыннан күченеп килгән һәм азмы-күпме көн күргән төбәк безгә «Смәлән», «Шәхмәй» исемнәре белән килеп ирешкән. Алга китеп, шуны әйтеп үтик: илдә Столыпинның аграр реформасы башлангач, отруб һәм хуторларга бүленергә рөхсәт ителә.

Ишмөхәммәт хаҗиның нәсел дәвамчысы Хәләфетдин дә борынгыда ак бабалары җире булган төбәктән, 40 гектар җир алып, шунда иген игә башлый. Күбәк һәм Тугай авыллары арасындагы бу урын бүген дә «Хәләф җире» дип атала.

* * *

Гомерен, гыйлемен Ислам диненә, иленә һәм халкына хезмәт итүгә багышлаган, мөселманнарга Коръән серләрен ачарга булышлык иткән һәм күп шәкертләрнең остазы булган Ишмөхәммәт хаҗи картайган көнендә бик авыр хәлдә кала – Тарлау басуны өч вотчинник һәм 43 припущенник рөхсәтсез басып алалар, урманнары да читләргә китә, мал-мөлкәте дә тарала.

Гомеренең соңгы еллары ничек кенә авыр булмасын, Ишмөхәммәт хаҗи элеккечә үк ачык һәм йомшак күңелле, һәр сүзеннән гыйлем байлыгы сизелеп торган акыл иясе, абруйлы дин әһеле, остаз булып калган.

«Үзенең яраткан бәндәсенә Аллаһ сынар өчен байлыкны да, авырлыкны да бирер», дип юкка әйтмиләр инде.

Инде картайган этисенең авыр хәлен күреп, белеп торган улы Мөхәммәтлатыйф, яклау, ярдәм сорап, Оренбург-Самара генерал- губернаторына рапорт язарга мәҗбүр була (әлеге хат-рапорт Башкортостан дәүләт үзәк тарих архивында саклана [Ф.И-295. Язма-4. №637]). Әмма югары даирәләрдән, буш сүзләрдән гайре, юньле ярдәм күренми. Бездә элек-электән үк кеше кешегә һәм иленә көчле, гайрәтле чагында гына кирәк булган, күрәсең.

Ни хәл итмәк кирәк, адәм баласы бу дөньяларга мизгел өчен генә килә дә, вакыты үткәч, мәңгелеккә күчә. Ишмөхәммәт хаҗиның вафатыннан соң, кабер ташы югалгач, улы яңаны куя. Аңа: «Хаҗи Ишмөхәммәд Заидов, вафат булды 95 яшендә, 1 февраль, 1841 елда, яздым мин Габделлатыйф Ишмөхәммәд угылы 1870 ел, 3 сентябрьдә»,–дип язылган.

Әлеге юлларны укыгач, сорау туа: 1795 елда Оренбург губернасы Бәләбәй өязенең Күбәк авылында үткәрелгән ревизия (җанисәп) язмасында Ишмөхәммәткә 43 яшь, дип күрсәтелгән, ягъни ул 1752 елда туган булып чыга. 1816 елдагы җанисәптә ул 1753 елгы булып күренә. 1834 елда уздырылган җанисәп вакытында Ишмөхәммәткә 80 яшь дип язылган, ягъни 1754 елда туган. Ә Габделлатыйф куйган таштагы язу буенча Ишмөхәммәт 1746 елда туган булып чыга (1841 ел–95яшь=1746 ел). Баласының үз этисе турында язганы дөрес булыр, дигән уйга нигезләнеп, Ишмөхәммәт Заитовның туган елын 1746 ел дип билгелик. Бакыйлыкка күчкән вакыты төгәл билгеле–1841 елның 1 феврале.

## Әдәбият


1. Социалистик Татарстан. 1990.
2. Ризаэддин Фәхреддинов. Асар. Казан, 2006.
3. Шиһабетдин Мәрҗани. Мөстәфадел әхбәр фи әхвәли Казан вә Болгар. Казан, 1989.
4. Башкортостан дәүләт үзәк тарих архивы. Ф.И.-295. Яз. 4. Эш-5940.
5. Башкортостан дәүләт үзәк тарих архивы. Ф. 10. Яз. 1. Эш-1278. 13 б.
6. Башкортостан дәүләт үзәк тарих архивы.Ф.И.-295. Яз. 4. №637.


*Алынды: [Гатауллин Г.Ш. Ишмөхәммәт хаҗи кыйссасы. Уфа, 2015.–77 б.]*

*Басмага И.З. Гарифуллин әзерләде.*

***Римзиль Валеев***

## ЧРЕЗВЫЧАЙНЫЙ И ПОЛНОМОЧНЫЙ...

### *Деревня Дюсяново как субъект международных отношений*

В деревне Дюсяново родился и вырос революционер и государственный деятель, выдающийся дипломат Карим Хакимов. Благодаря этому факту небольшое село на берегу р. Дема, на границе Башкирии, Оренбуржья и Татарстана попало в энциклопедии и документы мировой политики. В Дюсяново всего 130 дворов. До Уфы – 280 км, до Оренбурга – 250, до Казани – 500 км. До железной дороги – 70 км. В разные времена Дюсяново относилось то к Иль-Кульминской волости Оренбургской губернии, то к Мензелинскому и Белебеевскому уездам Уфимской губернии. Сейчас входит в Бижбулякский район Республики Башкортостан, представляя собой достопримечательность родного края.

Никого не удивляет причастность VIP-персон к российской глубинке. Немало известных личностей вышли из далеких сел и малоизвестных городов. И это обстоятельство редко отражается на благополучии земляков. Исторические личности, как правило, весьма непрактичны и, занятые мировыми проблемами, не ведают о бренной жизни своих земляков. Но всегда неизменны чувства гордости земляков, повышенное внимание людей к месту, связанному с судьбой выдающихся лиц. Остаются хлопоты, связанные с приездом важных гостей, с музейно-юбилейными событиями.

Трудно объяснить, как в самых привычных условиях, среди обычных земляков формировалась незаурядная личность. Смотришь иногда на высоких руководителей, великих ученых и деятелей искусства из глубинки и диву даешься, как же именно он – один из уроженцев какого-то обычного села или поселка, в котором нет комфортных условий для раскрытия талантов, стал выдающей личностью? Если бы удалось раскрыть эту тайну и понять секрет триумфального восхождения знаменитых людей, можно было бы наладить серийное производство «гениев» и перспективных кадров.

А в целом, Дюсяново – обычная деревня. По данным Государственного архива Башкортостана, опубликованным в книгах Анвара Асфандиярова, исторической родиной дюсяновцев можно считать Восточный Татарстан. 270 лет назад, в середине XVIII в. наши предки переселились из Мензелинского уезда Уфимской губернии, нынешнего Сармановского района Республики Татарстан. Там, где уральские предгорья встречаются с оренбургскими степями, до сих пор живут, почти не выделяясь на фоне других сел, переселенцы из деревень Сарсаз-Текермян и Иман

бывшего Мензелинского уезда: жители Дюсяново, Аитово, Елбулак-Тамак, Большие Каркалы, Зильдярово, Баязитово и др. – всего 12 деревень, расположенных в Бижбулякском и Миякинском районах Башкортостана. Отметим для памяти: согласно Третьей ревизии, т.е. переписи населения, в деревне Сарсаз Текермян жили ясачные татары.

Считается, что дюсяновцы отличаются непокорным характером, продвинутостью, но в то же время они весьма скромные люди. Никаких специальных условий для проявления выдающихся качеств здесь не увидишь. Ни дипломатических курсов, ни языкового центра тут нет. Начальная школа, открывшаяся более 100 лет назад, то вырастает до восьмилетней и средней, то опять откатывается до статуса начальной школы. Есть мечеть, клуб, которым бывает нелегко выжить в суровых условиях глубинки. Сейчас открыты несколько частных магазинов. Все как везде. Почта, местная власть – в соседнем башкирском с. Биккулово.

Высокие гости района и республики, целые туристические группы часто заезжают в Дюсяново. Их привлекает настоящая достопримечательность родного края – музей Карима Хакимова, входящий в муниципальное музейное объединение Бижбулякского района. Он создан около 60 лет назад и служит хранилищем памяти и просветительским центром далеко не местного масштаба. Потому что краеведческие сведения и музейные экспонаты неизбежно затрагивают общегосударственные и международные события, проблемы мирового масштаба.

### *Достойные земляки*

Всех жителей Дюсяново можно было бы поселить в одной городской пятиэтажке. Но вряд ли можно найти в городе дом, сопоставимый по количеству незаурядных уроженцев одной маленькой деревни!

Вот малоизвестный факт: Мифтахетдин Акмулла – великий поэт и просветитель башкир, татар и казахов – тоже дюсяновец по происхождению. Можно представить, как маленький Мифтах бегал и по двору своего дюсяновского дедушки…

В книге учителя истории Магсума Каюмова и его дочери Галии Сафаргалиевой «Дюсян», изданной в уфимском академическом издательстве «Гилем» в 2005 г., приводятся данные из 4-го тома трудов религиозного деятеля Ризы Фахреддинова. Из них следует, что Мифтахетдин Акмулла родился 14 декабря 1831 г. в семье муллы Мухамедьяра, казаха по национальности, и дюсяновской татарки Бибигульсума Салимовой. Отец будущего поэта смолоду жил среди татар и башкир, учился в Стерлибашевском медресе, но умер, когда сыну было 6 лет. Овдовевшая Бибигульсум позже вышла замуж за Камалетдина Ишмухаметова – муллы башкирского с. Туксанбаево. После смерти матери мальчик, оставшийся

круглой сиротой, жил с отчимом и мачехой, а когда подрос, подался в казахские степи, где работал, учился, учительствовал по аулам. Современные уфимские ученые эту версию наверняка воспримут без восторга и доверия. Но мы, земляки Акмуллы, не можем стереть из памяти архивные факты, хотя бы из уважения к Ризе Фахреддинову и к авторам краеведческой книги «Дюсян».

Если заглянуть в эту книжку, то можно найти сведения о специалистах и руководителях районного и республиканского уровней, тружеников, удостоившихся наград и признания, об известных лидерах своей эпохи, видных инженеров, врачей, юристов, учителей, комбайнеров, животноводов и других достойных дюсяновцах. Уроженцы Дюсяново часто продвигались не только в сельском хозяйстве или муниципальном управлении, что выглядело бы логично, но и в сферах, далеких от обычного жития моих земляков – в авиации, искусстве, IT технологиях.

Дюсяново помнит знаменитого учителя-орденоносца Газиза Галимова, а также Габдуллу Гафурова, Тажетдина Шамсетдинова, Газиза Каюмова, Габдуллу Садыкова, Закира и Шакира Закировых, и других односельчан, которые героически воевали, трудились, боролись за новую жизнь. Их имена остались в памяти земляков. Дюсяновец Хажиахмет Каюмович Гильманов в Гражданскую войну воевал на Туркестанском фронте, работал в Узбекистане, в Самарской, Ростовской областях, героически воевал в годы Великой Отечественной войны, был ранен и контужен, успешно работал в Ростовской области, награжден орденами, жизнь закончил в Москве и похоронен на Новодевичьем кладбище. Примечательно, что дочь Х.К. Гильманова Аниса Хажиахметовна (Истомина Энесса Георгиевна) окончила Московский историко-архивный институт, стала доктором наук, работала в Институте истории Академии наук СССР, читала лекции во Франции в Сорбонском университете, преподает в Московском гуманитарном университете и других столичных вузах, имеет много трудов по истории отечества. Опытный журналист Лутфи Закирович Гадилов – друг и соратник дипломата Карима Хакимова, родился в Бузулукском уезде Самарской области. Он руководил радиокомитетом Башкирии, издавал труды классиков марксизма-ленинизма, занимался изучением жизни и деятельности знаменитых земляков. Собрал материалы, документы для музея Карима Хакимова, увековечил имя великого дипломата. Вместе с женой – сестрой Карима Хакимова Магнией Габдрауповной жил в Уфе; как достойные личности, они похоронены в Дюсяново. Здесь же, как и дочь Карима Хакимова Флора Каримовна, похоронен родной брат Карима Хакимова – Халик Рауфович Хакимов, участник гражданской войны, профессор и заведующий кафедрой Московского строительного институ-

та, автор разработок по фундаментам и искусственному замораживанию грунтов, благодаря которым строились заполярные города. В Дюсяново выросли прославленный, отмеченный наградами военный летчик Барый Рафиков и его брат Гани Рафиков – тоже военный летчик, руководитель авиаотряда Узбекистана и личный пилот Президента этой страны Ислама Каримова. Говорят, что Г.М. Рафиков был уволен за то, что в критической для безопасности полетов ситуации заявил: в самолете командиром (считай, «президентом») является он, а не его высокопоставленный пассажир. Деревня Дюсяново дала народную артистку Татарстана, известного драматурга Таслиму Халяф (Файзуллина). Ее сын Булат Файзуллин признан одним из ведущих специалистов компьютерной технологии в Республике Татарстан. А молодой дюсяновец Роман Набиев – чемпион мира по смешанным боям, тренер-методист Казанской спортивной школы, закончил педагогический университет и теперь завершает обучение в Академии спорта и физического воспитания. В Дюсяново родились и получили трудовую закалку первые главные редактора двух татарских журналов Татарстана и Башкортостана (гл. редактор молодежного журнала Татарстана «Идель» – Р.С. Валеев и гл. редактор башкортостанского журнала «Тулпар» – Р.М. Кашапов), а также Галия Сафаргалиева – учредительница и издатель популярного женского издания Башкортостана «Диляфруз», а его главным редактором работает родившаяся в Дюсяново Дина Мухарямова. Рустам Кильсинбаев, внук моего старшего брата Наиля Валиева, родом из башкирского города Кумертау, сейчас успешно трудится собственным корреспондентом ИТАР-ТАСС в Казани. Другой внук Наиля Салиховича – Роман Бубнов, окончил Московский литературный институт, пишет прозаические произведения на русском языке, работает на федеральном телеканале. Это тот случай, когда к литературе и публицистике на русском, татарском, башкирском языках причастны потомки уроженцев одного села.

Как же мои односельчане оказались столь колоритными личностями? Они не могут предъявить подробную родословную своих предков, показать ханские или дворянские корни и другие предпосылки героических личностей. Можно только назвать присущие жителям отдаленной глубинки черты – настойчивость, выносливость, и трудолюбие и определенный идеализм, готовность выполнить важную миссию, выдержать испытание.

***Долгое возвращение легенды***

В 60–70-е гг. прошлого века в наших краях торжественно звучало имя Карима Хакимова как революционера и дипломата, репрессированного коммуниста. В 1962 г. в Дюсяново усилиями сельчан на средства колхоза «Марс» был построен музей Карима Хакимова, который дважды был

обновлен и до сих пор служит достопримечательностью всего района и республики.

В Уфе на русском и башкирском языках издавались посвященные К.А. Хакимову 4 книги очерков Лутфи Гадилова и Фарита Гумерова, также сборники воспоминаний современников. В четырех городах (Уфе, Оренбурге, Бухаре и Ташкенте) улицы были названы именем К. Хакимова. Спектакль Башкирского академического театра по пьесе Н. Асанбаева «Красный паша» показали по Центральному телевидению СССР.

Было бы не удивительно, если бы с распадом страны и изменением политической системы интерес общественности от истории советской дипломатии переключился к иным политическим символам. Однако происходит прямо противоположное. Тема контактов европейской цивилизации с мусульманским миром даже актуализируется. Логика взаимоотношений России с исламским миром и влияние Королевства Саудовская Аравия на мировой нефтяной рынок дают неожиданный эффект.

Сейчас тема Карима Хакимова становится все более резонансной. Контакты с Ближним Востоком, поездки государственных деятелей и мусульманских делегаций на родину пророка Мухаммада, поиски путей сотрудничества со странами исламского мира возвращают Карима Хакимова в ряд влиятельных брендов международного сотрудничества. Растет интерес к реальным фактам истории отечества и международных отношений, где белых пятен очень много. В марте 2012 г. в Уфе состоялась международная конференция о российско-арабских отношениях и роли К.А. Хакимова. На ней выступали ученые и дипломаты из 35 стран! Все они подчеркивали заслуги нашего земляка в решении важных международных вопросов. В районах и городах Башкирии стали ежегодно проводиться «Хакимовские чтения» и конкурсы сочинений с участием десятков тысяч школьников! Появились новые публикации, телепередачи, документальные фильмы. Усилиями уфимского журналиста Шамиля Валеева была создана страница Карима Хакимова в Википедии, и теперь она превратилась в солидный источник информации.

Ученый Башкирского госуниверситета Руслан Хайретдинов защитил диссертацию о Кариме Хакимове. Группа уфимских кинематографистов взялась за съемку художественного фильма с использованием новейших данных из лондонских архивов. Авторы проекта обещают сенсационные факты, связанные с личностью Карима Хакимова. Если в 1950–60 гг. прошлого века он признавался революционером и дипломатом, потом его уровень был поднят до статуса государственного деятеля и выдающегося дипломата.

Сейчас все чаще упоминается роль спецслужб в международных делах, появляются в российской и зарубежной прессе публикации, раскры-

вающие К.А. Хакимова как решительного и умного разведчика. Что тоже не удивительно: сбор сведений о регионах и странах, информирование правительства о процессах, идущих в других государствах – естественная функция дипломатов и посольств.

Карим Хакимов, прибыв в бедную и воюющую мусульманскую страну, сумел организовать поток объективной информации для своего правительства, наладить коммерцию, подружиться с королями и министрами, зарубежными политиками, последовательно добиваться позитивного отношения властей и народов мусульманского мира к Советской стране. Он выполнял свою трудную миссию, умножая друзей своей страны в то время, когда недругов было очень много. Вот почему Карим Хакимов не уходит в пассивную историю. Сейчас актуализировалось изучение дипломатической работы К.А. Хакимова при активном содействии квалифицированных арабистов и востоковедов. Эксперты МИД РФ и историки внешней разведки оказывают целенаправленное внимание, отдавая отчет важности фигуры Хакимова и его действий в 1920–30 гг. прошлого века. Не исключено, что прошли сроки секретности некоторых событий и фактов, возможно, появилась целесообразность раскрытия отдельных сторон сотрудничества с Востоком.

Если в Уфе за последние 40 лет не появлялись новые книги, то в течение 1,5 лет в солидных издательствах Москвы вышли две объемные книги о К. Хакимове. Их авторы – действительный член Академии наук Российской Федерации, известный востоковед Виталий Наумкин и Чрезвычайный и полномочный посол РФ в Саудовской Аравии в 2010–2017 гг. Олег Озеров. Общий объем книг В.В. Наумкина и О.Б. Озерова составляет 700 страниц, их содержание основано на трудах Лутфи Гадилова – первого биографа К.А. Хакимова, архивных документах и научных публикациях. Они превосходят все опубликованные за предшествующие 50–60 лет биографические и историко-документальные труды!

Таким образом, жизнь и деятельность Карима Хакимова как государственного деятеля, дипломата и представителя разведывательных служб СССР становится еще более актуальной и горячей.

***Кто же он, «Красный паша»?***

Событий и сообщений много, но феномен Карима Хакимова остается не раскрытым. Чем объяснить особую значимость его деяний и судьбы?

Отправившись из дома 15 летним юношей, он работал дворником, землекопом, шахтером, строил железную дорогу в Оренбуржье и в Туркестане (это территория современного Казахстана, Узбекистана, Кыргызстана и др. стран). Учился в Каргалах (Оренбург), Уфимском медресе «Галия», учил детей в казахских степях. Познакомился с рабочим дви-

жением, втянулся в социал-демократические кружки и попал в число неблагонадежных лиц за антивоенную, антиправительственную агитацию среди рабочих.

Усвоил русский язык, взяв в мозолистые руки книги и тетради, в возрасте 24 лет окончил русскую гимназию в Томске! После Февральской революции 1917 г. стал активным революционером, вступил в партию большевиков, участвовал в становлении Советской власти. Будучи Наркомом просвещения Оренбургской губернии формировал систему светского образования. Стал настолько влиятельным комиссаром, что даже существует в виде музейного экспоната денежная банкнота, ходившая в Оренбуржье в годы Гражданской войны – она за подписью Карима Хакимова.

Он буквально воевал на фронтах Гражданской войны, командовал батальоном, формировал в Казани Татарскую стрелковую бригаду в составе 7 тыс. бойцов для защиты и укрепления советской власти. Занимал высокие посты в политуправлении армии, фронта и в руководстве ЦК Компартии Туркестана. Даже только за эти заслуги Карим Абдрауфович мог удостоиться памятника, стать одним из ведущих исторических личностей Башкирии, Оренбуржья, Татарстана.

В чем же все-таки феноменальность и международная масштабность деяний Карима Хакимова? При желании это можно понять, внимательно изучив книги академического и дипломатического сообщества. На обложке книги Виталия Наумкина «Несостоявшееся партнерство», фотография из официальной хроники 1932 г.: министр иностранных дел Саудовской Аравии, будущий король принц Фейсал, Председатель союзного Верховного Совета Михаил Калинин и Карим Хакимов. В названии книги обозначена горячая дискуссионная тема: действительно ли не состоялось партнерство с ныне влиятельным богатым королевством, лидирующим в мусульманском мире? И почему так случилось?

Новая книга, написанная О.Б. Озеровым, оказалась в центре внимания весьма компетентной публики. Презентации книги «Карим Хакимов: Летопись жизни (О судьбах ислама и коммунизма в России)», изданной Институтом системно-стратегического анализа, состоялись в онлайн режиме через IT площадки Антальи, Стамбула, Бейрута и прошли весьма успешно, с постановкой острых вопросов, привлечением серьезных аргументов.

Без книги посла Олега Озерова о Кариме Хакимове, исследования Виталия Наукина было бы невозможно представить, каким оказалось продолжение дипломатических усилий, установленных в 1891 г., когда в Джидду приехал первый генконсул Российской империи Шахимардан Мирясович Ибрагимов, татарин по национальности. Тогда было больше страхов, недоверия и непонимания в отношениях со столь разными стра-

нами, с несопоставимыми культурами. Никто не мог даже представить, каким будет размах сотрудничества буквально через 30–40 лет! И этот размах приходится на время работы Карима Хакимова и его преемника Назира Тюрякулова.

И действительно, объем и характер проведенной Хакимовым работы в арабских странах напоминают настоящую революцию. В 1920–30 гг., благодаря контактам с Советским Союзом и сокращению сферы влияния США и Великобритании, Аравийский полуостров и мусульманский мир претерпели серьезные изменения. Менялись эти страны, менялось отношение других стран к ним. Остается лишь сожалеть, что после гибели Карима Хакимова в период сталинских репрессий, Советская страна в течение 50 лет не имела дипломатических отношений с Саудовской Аравией на уровне послов...

Олег Борисович Озеров, как продолжатель этого непростого пути, понимает цену сотрудничества России и исламского мира. К.А. Хакимов был ключевой фигурой восточной дипломатии не только для 1930-х гг. Возможно, и раньше были такие же прорывные факты и личности и в налаживании связей с Китаем, Латинской Америкой, Африкой, обеспечившие мощное продвижение интересов страны. Может быть о них напишут, покажут документы и материалы, способные потрясти континенты. Как написали о разведчике-нелегале Исхаке Ахмерове, которому в Челябинске поставили замечательный памятник.

Значительное место во внешней политике современной России играет Королевство Саудовская Аравия – государство, которое Карим Хакимов превратил в друга Советского Союза. Эта страна сегодня играет ощутимую роль в мировой политике и экономике. Поскольку благополучие 146 млн россиян сегодня зависит от колебания цен на нефть, от взаимоотношений стран и народов с различными вероисповеданиями и идеалами, многое зависит от дипломатии Российской Федерации, от ее мудрости и последовательности. Такой, какой ее формировал и Карим Хакимов, заплативший жизнью в возрасте 48 лет. Он вновь возвращается в современность. Своим примером он как бы убеждает, насколько важно защищать интересы страны, побеждать, не допуская войны, не умножая числа врагов и недоброжелателей, уважая представителей других цивилизаций – королей, падишахов и простых людей.

### *Чей герой – Карим Хакимов?*

Рассказывая об исторических личностях, принято указывать их национальность. Я никогда не вступал полемику по поводу национальности Карима Хакимова. Каждый волен сам оценивать свою принадлежность к религии, национальности. Нельзя человеку навязывать со стороны каку-

ю-то иную народность или своего бога. В Конституции этот пункт обозначен термином «свобода совести». Всегда нужно спросить самого человека, если он жив. Но отдельные личности пользуются тем, что Карим Хакимов не может встать и сказать о своем происхождении и самосознании.

При жизни самого Хакимова не было сомнений по поводу его национальности. Просто эта тема тогда не была проработана. Человека воспринимали с учетом его места рождения, религиозной принадлежности (мусульманин, христианин, православный или иудаист) и, конечно, сословия, что в годы революции и Гражданской войны играло не последнюю роль. Богатые и привилегированные, как и попы, и муллы, относились к враждебной для власти категории, подлежащие изгнанию или уничтожению. Поэтому в анкетах все старались указывать свое пролетарское происхождение, акцентировали внимание на бедности семьи, не выпячивали связи с религией. «Пятая графа» о национальности могла стать актуальной по мере развития профессиональной культуры, образования, осознания вопросов истории и идентичности.

В свидетельстве Карима Хакимова об окончании 2-й Томской мужской гимназии в 1917 г. он назван «башкиром». В некоторых дореволюционных ревизских сказках, переписях населения дюсяновцы записаны башкирами. Тогда термины «башкирец», «башкир» показывали принадлежность к сословию, получившему право на владение землей и определенные налоговые привилегии. После 1917 г., когда вышел декрет об упразднении сословий и привилегий, в графе «национальность» стали указывать реальную этнокультурную принадлежность. Поэтому в анкетах Наркомата иностранных дел Карим Хакимов в графе «национальность» своей рукой вписал – «татарин». В своем письме В.В. Куйбышеву 11 ноября 1921 г., например, он пишет о своих идейных противниках: «...ведут усиленную компанию против татар вообще и в частности против меня».

Тогда в госорганах строго следили за точностью оформления классовой, религиозной и национальной принадлежности. Могли выгнать с учебы или работы, посадить в тюрьму, если кто-то окажется сыном муллы или кулака. Родным языком Хакимова, как у всех дюсяновцев, всегда был татарский. В ревизской сказке третьей ревизии жители села Сарсаз-Текермян Мензелинского уезда, откуда дюсяновцы переселились в XVIII в., указаны «ясачными татарами».

И все же я бы не стал категорично заявлять о национальности Карима Хакимова. «Пятая графа» для него была менее значима, чем классовая и идейно-политическая идентичность. Прежде всего он был большевиком, борцом за мировую революцию, посланником своей страны. И, конечно, совершенно точно, когда называют его просто уроженцем Башкортостана.

Принадлежность к мусульманству для него стала профессиональным инструментом. Знание исламских обычаев, уважение традиций и мировоззрения арабов ему помогли успешно выполнять свою миссию. Поэтому он, коммунист, член партии атеистов, совершал хадж, обсуждал мирские дела с арабами как правоверный мусульманин, чем вызвал признание и уважение партнеров. Можно сказать, метафорой: по национальности он был большевиком.

Отношение к татарскому и башкирскому национальному движению – весьма неоднозначный пункт во взглядах Карима Хакимова. Он без восторга принимал объявленное Лениным и большевиками право наций на самоопределение, выступал против создания партийных структур по этническому признаку. Возможно, создание Башкирской и Татарской республик он считал вынужденной мерой. Для многих большевицких лидеров важнее всего была победа мировой революции, установление власти Советов и строительство социализма во всех уголках Российской империи. При участии К. Хакимова была создана Бухарская Народная Советская республика. В 1920–21 гг. в Иране на территории 14 тыс. кв. км существовала Персидская Советская Социалистическая Республика! Кстати, в ее столицу Решт К. Хакимов был назначен Генеральным консулом РСФСР.

Хакимов был одним из противников проекта Татаро-Башкирской республики, утвержденного ЦК партии руководством Российской республики. Не жаловал он лидера башкир Заки Валиди и «татарского буржуазного националиста» Мирсаита Султангалиева, сторонника наделения республик в составе России относительной самостоятельностью и определенными правами.

Но судьба сыграла злую шутку: его, верного интернационалиста и преданного большевика, возражавшего против создания мусульманских структур в РКП(б) и противника учреждения Татаро-Башкирской республики, расстреляли 10 января 1938 г. Он был казнен на 2,5 года раньше того дня, когда был расстрелян его идейный противник, «буржуазный националист» и «пантюркист» Мирсаит Султангалиев. В приговоре Хакимова тоже была записана чудовищная формулировка – «За участие в антисоветской пантюркистской террористической организации». Его уничтожила система, которой он был верен до конца. Зато столь долгим и богатым на события оказалось его возвращение из небытия после реабилитации в 1956 г.

Было бы неразумно в пылу местного патриотизма идеализировать, возносить образ Карима Хакимова. Не все значительные детали установлены и обнародованы. Он пока далеко не в полной мере оценен и понят. Предстоит его разглядеть, отделив от штампов и современной шелухи,

изучить все имеющиеся документы, факты и публикации. Например, о том, как Карим Хакимов вместе с Лениным и Сталиным участвовал в работе II съезда коммунистических организаций Востока в ноябре 1919 г., III конгресса Коминтерна и других форумов. Не всем известно, что он был одним из участников создания Татарской автономной республики, членом Временного ревкома, образованного для передачи власти.

Крестьянин и пролетарий Карим Хакимов любил театр, играл на мандолине, выступал на самодеятельных концертах. По свидетельству уфимского писателя Гайнана Амири, будущий дипломат играл в спектаклях. Участвовал в представлениях татарской театральной труппы «Сайяр». Возможно, даже играл вместе со знаменитой Сахипжамал Гиззатуллиной- Волжской. Есть фотография, снятая в Коканде в 1915 г., где железнодорожный рабочий и шахтер Карим Хакимов выглядит как артист и благородный театрал. Вместе с ним сняты друзья – Ильясбек Ашказарский и Нури Сакаев – родоначальники татарского театра.

Дипломат и участник великих революционных событий, жертва кровавых репрессий Карим Хакимов – часть своего народа и истории родного края. Он дорог землякам, как ценен для дипломатической среды и широкой историко-научной общественности.

В течение всей жизни он был «чрезвычайным и полномочным послом» родной земли, выражал интересы и чаяния многоликого народа своего региона.

Первый полпред СССР на Востоке был и «нашим», дюсяновским полномочным послом. Хочется, чтобы все знали о таком ранге Карима Хакимова. Так получилось, что мы, бижбуляковцы, жители его родного края, не отказываемся от своей причастности к мировой дипломатии и международным отношениям. Он – один из нас. Земляки и близкие всегда ощущали, что вместе с ним как бы и нас наделяли полномочиями. И казнили нас тоже вместе с ним...

Хочется, чтобы крупные политики и трансконтинентальные экономические сообщества, решая глобальные проблемы, знали о наших скромных притязаниях. Пусть в парламентах, международных форумах, Генеральных Ассамблеях не забывают про землю, на которой выросли выдающиеся личности. И вообще о народах, живущих в разных концах земли, желающих мира и благополучия.

*Галия Гайнетдинова*

## САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА – АЧЫЛМАГАН ХӘЗИНӘ

Әлеге мәкаләмне Нил абый Гарифуллин турында язу белән башлап китәсем килә. Ул бүген яраткан тормыш иптәше Рәйсә апа белән Лаеш шәһәрендә яшәп ята икән. Нил абый быел миңа матур сүзләр белән автограф куеп, «Мәзәкләр» дигән китабын бүләк итте. Автографтан югары «якташым, райондашым, уңышларыңа сөенеп, чын күңелдән Нил абыең» дигән җылы сүзләр язылган.

Нил абыйны күп еллар элек Башкортостанның Тәтешле районында чыгучы «Коммунизмга» (хәзерге «Тәтешле хәбәрләре») газетасының баш мөхәррире буларак беләидем. Ул анда 1967 елдан 1984 елга кадәр эшләгән.

Минем туган авылым Сараштыда укып йөргән чакларым. Алтынчы сыйныфта укыган вакытта шушы газетада тәүге язмаларым басыла башлады. Ә 9, 10 сыйныфларны Күрдем авыл мәктәбендә укыдым. Бу вакытта инде мәкаләләрем, шигырьләрем республикабызның башка газеталарында да дөнья күрә башладылар.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң, мин Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керәм, дип Казанга китеп бардым. Шул сәбәпле, район газетасыннан бераз аерылып тордым. Нил абый турында да шулвакыттан бирле берни ишетмәдем. Аның турында якташыбыз, язучы Томас Нигъмәтҗановның «Татышлинский рай» («Тәтешле оҗмахы») китабыннан укып белдем. Лаешка күчеп килгәч, Нил абый 1984 елдан 2001 елга кадәр «Кама ягы» газетасы редакциясендә эшләгән. Гаҗәп, ул күренекле шәхес, язучы-шагыйрь Әдип Маликовның энесе икән.

Әдип Маликов, белгәнебезчә, үзеннән соң зур гына әдәби мирас калдырган талантлы шәхес, публицист язучы, күп кенә китаплар авторы. Аның тормыш иптәше шагыйрә Саҗидә Сөләйманова да – үзенең күп санлы китаплары, матур җырлары белән танылган шагыйрә. Мин, бик дәртләнеп, С. Сөләймpraснованың тормыш юлы һәм иҗаты турында кызыксына башладым. Ә кызыксынуымның сәбәбе шул: Саҗидә исемле сары чәчле кечкенә кыз минем туган авылым Сараштыда әнием белән бергә уйнап йөргәннәр. Мин бу турыда әнием сөйләгәннәрдән ишетеп белдем. Иң кызыгы шул: алар икесе дә 1926 елда туганнар.

Төрле чыганакларны актарганнан соң, шунысы мәгълүм булды: 1930 елларда колхозлашу чоры башлангач, Саҗидәнең әтисе Гаделшаны «егермебишмеңчеләр» исемлегенә кертәләр. Шуңа күрә язмыш аны колхозлар төзеп, гаиләсе белән авылдан авылга күченеп йөрергә мәҗбүр

итә. Яңавылда туган кыз әти-әнисе белән башта Урады авылында (әнисе Гыйльмулла кызы Галимәнең туган авылында) яши. Аннан – Сараштыда, соңрак – Аксәеттә. Ул чакта бу авыллар 1930 елны оештырылган Яңавыл районына керәләр иде (1935 елны яңа район оештырылгач, Сараштты белән Аксәет Тәтешле районы составына кертеләләр).

Болай күченеп йөрү бала-чагалы гаиләгә, әлбәттә, зур кыенлыклар тудыра. Булачак шагыйрәнең яшүсмер еллары Тәтешледә үтә. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Саҗидә Тәтешледән ерак түгел Шулган авылында бер ел буе мәктәптә балалар укыта. Буш вакытларында шигырьләр язу белән шөгыльләнә. Аның туган җир, тормыш, яхшылык һәм явызлык, гаделлек һәм мәхәббәт турындагы шигырьләре газета-журналларда еш басыла.

Югары Чат авылы егете Әдип Саҗидәгә гашыйк була. Күпмедер вакыттан соң, алар өйләнешәләр. Тормыш көтү аларга җиңел бирелми. Күп тә үтми, алар Татарстанның Минзәлә шәһәренә барып урнашалар. Минзәләдә Илдар исемле уллары туа. Биредә 2 ел яшәгәннән соң бу гаилә тормыш итәр өчен Әлмәт шәһәрен сайлый. Әлмәт бу вакытта әле төзелеп кенә килә. Биредә яшәгәндә Саҗидә Сөләйманова белән Әдип Маликов гаиләсендә тагын бер малай – Әнвәр туа. Язучылар гаиләсе тормыш мәшәкатьләрен иҗат белән үреп яши. Берсе шигырь, поэмалар язу белән мавыкса, икенчесе повесть, хикәяләр яза. Хәзер инде Саҗидәне киң укучылар массасы белә, ярата. Ул – укытучы да, журналист та, тормыш йөген тартып баручы ир хатыны да, бала анасы да.

Миңа үткән җәйдә туган авылыма кайткач, Тәтешледә яшәп ятучы Алия апада булырга туры килде. Алия апа – С. Сөләймpraнованың кече сеңлесе. Без аның янына Тәтешледә туып үсеп, бүгенге көндә Казанда яшәүче язучы-журналист Томас Нигъмәтҗанов белән бардык. Юлыбызның ничек аңа алып килүе турында берничә сүз әйтәсем килә.

Томас Тимерханович Тәтешле урамында үзенең классташы Клара Сафинаны күреп ала да, безнең Саҗидә Сөләймановaның бертуган апасы Мәдәния апа белән күрешеп сөйләшергә баруыбыз турында әйтә. Тик, кызганычка каршы, Клара апа: «Мәдәния апаны, хәле авырайгач, улы Азат Баталов Чаллыга үзләренә алып китте, хәзер ул анда яши», – ди. Бу сүзләрдән соң Мәдәния апа белән күрешү насыйп булмаганга күңелләр бик төшкән иде. Шулчак Клара апаның: «Сез аның бертуган сеңлесе Алияне күрә аласыз. Ул хәзер өендәдер», – дип әйтүе инде сүнгән өметкә җан өргәндәй булды. Без, өчәүләп, Алия апаларга киттек. Аның белән озак кына сөйләшеп утырдык, фотога төштек.

Дикъкать белән пөхтә итеп җыештырылган бүлмәдән, стенада эленгән сурәтләрдән, өстәлдә яткан китаплардан күзләрем Саҗидә Сөләймановага кагылышлы истәлекләр эзләде. Бар да тәртиптә, бар да авылча. Әнә, өстәл

өстендә соры тышлы калын китап ята. Тышында шагыйрәнең фотосы. Тукта, бу китапны әле күптән түгел районның Туган якны өйрәнү музеенда күрдем түгелме соң? Әйе, шунда күрдем мин аны. Бу китапның битләре С. Сөләйманова турында күп нәрсә сөйләргә тиеш бит. Каян табарга? Алия апа белән сөйләшә торгач, шуны белдек: Саҗидә апаның улы Әнвәр Әдип улы Маликов гаиләсе белән Казанда яши икән. Әлеге китапны аның аша табып булмас микән дип, телефон номерын язып алдык.

Шагыйрә белән бәйле юлыбыз әлегә уңышлы бара, дип, эчтән генә шатланам. Башымда Казанга баруга, һич кичекмәстән, Әнвәр Маликов белән очрашырга кирәк, дигән уй туа. Башкача әлеге китапны ничек тапмак кирәк? Ә алда күпме хыяллар... Беренчедән, Саҗидә Сөләймановага багышлап шигырь язмасам, үземне тиешле эшен үтәмәгән кеше сыман хис итәчәкмен. Чөнки шигырьнең идеясе инде күптән башка кереп оялаган, тик материал җитми. Икенчедән, С. Сөләйманова премиясе лауреатлары белән гимназиябездә очрашу кичәсе үткәрүне дә җәйдән үк планга кертеп куйган идем. Өченчедән, Саҗидә Сөләймановага багышлап, бер матур тема буенча укучым Ралинә белән Каюм Насыйри исемендәге фәнни практик конференциягә чыгыш әзерләсәк, күңелемдә бер тынычлык урнашыр иде.

Җәйге отпускам төгәлләнеп Казанга килгәч, Әнвәр Әдибовичка шалтыраттым, Саҗидә Сөләйманова турындагы китабын үземдә булдырыр өчен кайда һәм кайчан очраша алуыбыз турында белештем. Ул баш тартмады, бик ягымлы тавыш белән шунда ук үзләренә дәште. Әнвәр Әдибович бик җылы каршы алды. Сөйләшеп утырдык, бик кызыклы, матур әңгәмә килеп чыкты безнең арада. Китәр алдыннан әнисе Саҗидә Сөләйманованың һәм әтисе Әдип Маликовның «Сайланма әсәрләр», «Со звездами наедине», «Гомер мизгелләре» китапларын һәм үзенең тормыш иптәше Асия Маликова белән бергә язган «Шигъриятнең күкчәчәге» исемле китапларын бүләк итте. Өстәвенә, ул безне 5 ноябрьдә Әлмәт шәһәрендә үткәреләчәк шигърият бәйрәменә чакырды. Минем аның бу тикле юмарт һәм киң күңеллелегенә исем китте. Без Әнвәр Әдибовичны 5-нче гимназиядә үткәреләчәк әдәби-музыкаль кичәгә чакырып, саубуллаштык. Мин әлеге очрашудан, сирәк очрый торган ниндидер бик затлы кош тоткандай, бер кочак китаплар күтәреп, канатланып кайттым.

Әлеге китапларда С. Сөләйманованың тормышы һәм иҗаты, ул яшәгән чор һәм әдәбият, аның турында замандашларының истәлекләре, хатлары һәм башка безгә кирәкле мәгълүматлар җитәрлек. Без аларны укучыларым белән фәнни эшләр язганда рәхәтләнеп файдалана алабыз.

Шагыйрәнең иҗаты белән мавыгып китүем, ничектер, шулай көтмәгәндә, уйламаганда килеп чыкты. Әллә шундый танылган шәхеснең

безнең авылда яшәп киткәнлеген белеп алуыммы, әллә аны әнием күреп белгәнгәме, әллә шигырьләренең йөрәгемә үтеп кереп, мине иҗатка канатландыруымы, белмим. Әмма мине җитди эзләнү эшенә Саҗидә Сөләймановaның кабатланмас матур иҗаты, тормышны яратучы батыр йөрәкле, көчле рухлы хатын-кыз һәм үзеннән соң килүче буынга якты эз күрсәтүче остаз була алуы этәргеч булгандыр. Мөгаен, шулайдыр.

Татарстанда да, Башкортостанда да халыкның күпчелеге Саҗидә Сөләймановaны бик яхшы беләләр, дип әйтеп булмый. Шуңа күрә аның галимнәр тарафыннан әле ачылмаган иҗат хәзинәсен дөньяга танытырга кирәк, минемчә. Берничә шигыренең дәреслекләргә кертелүе генә җитми. Аның тормыш юлы һәм иҗаты турында томнар язарга кирәк!

2019 елның октябрь аенда Казан шәһәренең 5-нче гимназиясендә шагыйрә Саҗидә Сөләймановага багышланган «Ач, шигърият, серләреңне!» дигән әдәби-музыкаль кичә оештырдым. Биредә С. Сөләйманова сүзләренә Мәсгут Имашев язган җырлар башкарылды, укучылар шагыйрәнең шигырьләрен бик яратып, яттан укыдылар. Дистәләгән китап, иллегә якын җыр авторы С. Сөләйманованың тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу өчен гимназия китапханәсенә яңа китаплар өстәлде. «Со звездами наедине», «Саҗидә Сөләйманова – шигъриятнең күкчәчәге», «Сайланма әсәрләр», «Гомер мизгелләре» исемле бу китапларны китапханәгә шагыйрәнең улы, «Девон» мәгълүмат агентлыгы директоры Әнвәр Маликов бүләк итте. Кичә ахырында Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты Рәиф Зиннәтуллин, Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары мәгариф бүлеге методисты Илгизә Ильясова, гимназия директоры Альфред Рәхимшин чыгыш ясадылар. Алар үз чыгышларында: язучы-шагыйрьләребезне чакырып, мондый кичәләр үткәрелеп торганда, балалар туган телләрендә аралаша белгәндә татар теленең киләчәге дә дәвамлы булачагын ассызыклап үттеләр. Саҗидә Сөләймановага багышланган әлеге кичә укучылар күңелендә матур истәлек булып, озак сакланыр, дип уйлыйм. Чөнки шагыйрәнең иҗаты – тирән эзле, гаҗәеп матур иҗат ул. Юкка гына Хәсән Туфан аны татарның Анна Ахматовасы дип атамаган.

5 ноябрьдә нефтьчеләр башкаласы Әлмәт шәһәрендә «Шигърият бәйрәме» үтте. Бу бәйрәм матур традиция буларак, күп еллар дәвамында шигърият сөючеләрне үзенә җыя. Биредә үзләренең иҗатлары белән танылган язучы-шагыйрьләргә, сәнгать әһелләренә Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия тапшырыла. Бәйрәмдә катнашып, бу тамашаны үз күзләрем белән күрү миңа да насыйп булды. Башта С. Сөләйманованың һәйкәле янында галимнәр, язучылар чыгыш ясады, аннан һәйкәл эргәсенә чәчәкләр куелды. Кунакларның ярты өлеше автобуста экскурсиягә китсә, яртысы Әлмәт татар дәүләт драма театры бинасында әдәби дис-

куссиядә фикер алышты. Бәйрәмнең иң дулкынландыргыч мизгеле – Татарстан Язучылар берлеге «Татнефть» компаниясе белән гамәлгә куйган Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр тапшыру тантанасы Әлмәт татар дәүләт драма театры бинасында үтте. Аны «Татнефть» иминият фондының «Рухият» программасы ел саен зурлап оештыра. Чираттагысы да бик матур оештырылган иде. Еллык әдәби премияләр шагыйрә Фәүзия Галиуллинага (Казан), язучы Рәмзия Габделхаковага (Лениногорск), Тәүфикъ Кәримовка (Казахстан), кызыксындыру премияләре Лира Вәлидигә (Алабуга), Рухия Ахунҗановага (Сарман, Җәлил), Александр Аввакумовка (Казан) тапшырылды, ә 10 студентка С. Сөләйманова исемендәге степендия бирелде. Ул вакыттагы Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов әйтүенчә, бу әдәби бүләк хәтта Россия күләмендә дә танылган. Әйе, кайчандыр өч мәртәбә Г. Тукай премиясенә тәкъдим ителеп тә, Саҗидә Сөләймановага бу бүләк бирелми кала. Ә бүген, күрәсезме, инде ничә еллар буе талантлы әдәбият әһелләренә шагыйрә С. Сөләйманованың үз премиясе бирелеп килә.

Шигърият бәйрәме ахырында Әнвәр Маликов премия ияләренә, әлеге чарада актив катнашучыларга, оештыручыларга рәхмәт белдерде, сәламәтлек һәм иҗат уңышлары теләде. Бәйрәм Саҗидә Сөләйманова сүзләренә язылган «Урсал тауда» җыры белән тәмамланды. Бу матур традиция киләчәктә дә шулай дәвам итсен, аның географик чикләре киңәйсен, С. Сөләйманованы бөтен татар дөньясы белсен иде, дигән теләктә калам.

Сүземнең ахырында шуны әйтәсем килә. Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов Саҗидә Сөләйманованың иҗатын югары бәяләп: «...Җиде-сигез ел эчендә шагыйрә баш әйләндерерлек биеклеккә күтәрелде, ир-ат шагыйрьләр өйрәнерлек, Туфаннар хөрмәт итәрлек Шагыйрь булып җитеште...» – ди.

Шигырь Саҗидәнең тормышына, җан сердәшенә әверелә. Ул – хисле лирик шагыйрә. Бу аның туган җиренә, туган халкына, туган теленә карата мәхәббәт белән сугарылган шигырьләрендә ап-ачык күренә.

Шагыйрь Зөлфәт: «...Ул поэзиядә бик күп шагыйрьләр ирешә алмаган биеклеккә күтәрелде. Укып карасаң, аның шигырьдәге һәр юлы көтелмәгән. Ул – чын мәгънәсендә – оста... Мастер!» – дип соклана.

Әйе, кемдер аны «шигъриятнең кукчәчәге» дип, кемдер «шигъриятнең олы тукталышы» дип, ә кемдер «халкыбызның йөзек кашы» дип атый. Асия Маликова сүзләре белән әйткәндә, Саҗидә Сөләйманованы һәр кеше үзенчә күрә, үзенчә тоя, үзенчә ишетә.

*Хәмидә Гарипова*

## ИРЕК СӨЙГӘН САНДУГАЧНЫ САГЫНАМ

Әгәр исән булса, бөркеттәй кыю йөрәкле милләтпәрвәр шәхес, кабатланмас тавышлы моңлы сандугачыбыз – РСФСР ның атказанган (1988), ТАССРның (1981) һәм Каракалпакстан АССРның (1988) халык артисткасы Вафирә Гыйззәтуллинага 2021 елның 13 февралендә 75 яшь тулган булыр иде. Кызганычка, ул юк инде...



Бүгенгедәй хәтеремдә, 2001 елның апрелендә җырчының 55 яшьлек юбилее уңаеннан Камал театры сәхнәсендә гаҗәеп җылы мохиттә узган кичәсендә иҗатына мөкиббән авылдашлары аңа «Ока» машинасы бүләк иткән иде, рәхәтен күрергә язмаган икән. Туган ягында (Менделеев районы) концерт куеп, башкалабызга кайтып килгән чагында, 17 сентябрьдә Уфа-Мәскәү трассасында килеп чыккан юл һәлакәтендә аның гомере фаҗигале төстә өзелүен ишетеп, чын мәгънәсендә тетрәнү кичергән идек.

Сөекле сандугачбызны югалтуыбызга егерме елга якын вакыт узуга карамастан, дөнья буйлап сибелгән рәхмәтле тамашачысы хәтереннән җуелмады ул. Сагынабыз, юксынабыз сине, Вафирәкәй! Бенефисында

күрсәткән гаҗәеп матур соңгы тамашаң әлегәчә исемнән чыкмый. Ул кичтә Вафирә ханым 35 ел дәвамында туплаган байлыгын тамашачысы белән ихластан бүлеште. Бүгенге эстраданы оятсызларча басып алган, ярым ялангач килеш сәхнәгә чыгып, чикерткә кебек сикеренгән, фонограммага авыз ачып, тамашачының зәвыгын бозучы күп санлы җырчылардан аермалы буларак, талант иясе Вафирәбез өч сәгатькә якын сузылган концертында үзе җырлады. Күпме җырласа да, тыңлап туеп булмас кебек иде. Вафирә апа үз-үзенә, сайлаган җырларының текстына, көенә бик таләпчән иде. Беркайчан да өч көнлек такмазага, бер көнлек мәгънәсез шалтыравык-ялтыравыкка кызыкмады. Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Әнвәр Бакиров, Заһит Хәбибуллин, Мансур Мозаффаров, Алмаз Монасыйпов, Сара Садыйкова, Фасил Әхмәтов, Ренат Еникиев, Марс Макаров, Александр Ключаревларның гаҗәеп көчле әсәрләрен җиренә җиткереп башкара иде ул. Камера музыкасын үстерүгә, халыкка танытуга зур өлеш керткән, татар композиторларының вокал өчен язылган көйләрен, лирик яңгырашлы романсларын беренче башкаручы булып танылган шәхес тә иде әле Вафирә. Кигән киеме дә зәвыклы булды. Бенифисының беренче өлешенә сылу аккош, икенчесенә кара карлыгач булып киенеп чыгуы исемдә. Уртадан аерып тарап, баш артына өелгән чем-кара көлтә чәченә кадаган кыстыргычына тиклем зәвыклы иде аның. Чын сәнгатьтә образ бар, анда һәр сызык, һәр буяу, һәр мизгел, күз карашы, керфекләр тибрәнеше очраклы түгел шул. Йөрәктән чыккан гына йөрәккә үтеп керергә сәләтле. Чын матурлык кына тамашачыда эчке ләззәт хисе уята, күңел кылларын тибрәндерә ала. Зәвыклы артисткабыз боларның барысын да аңлый иде. Искиткеч бормаларга, нәфис мелизмнарга бай көчле тавышы үзенә ияртеп әллә кайларга алып китә, ул башкарган җырлар безне иксез-чиксез кыпчак далаларына, болгар бабаларыбыз гомер сөргән Идел буйларына, сихри калын урман эчләренә алып керә, йолдызлы күкләргә күтәрә, тетрәндерә, сокландыра, иркәли, күңелдә өермәләр уята, мең төрле халәте белән җаныбызны сугарып, рухыбызны баетып, сафландырып янәдән җиргә төшереп бастыра иде. Чын сәнгать әсәрләрен тыңлау, шулар белән ләззәтләнү тамашачыга авырлыкларны җиңеп яшәрлек рухи көч бирә. Вафирәнең җырларын тыңлаганда, син үзеңнең галәмәт зур җиһанда ком бөртеге генә булуыңны тойган хәлдә дә ялгызлык хисе кичерми идең, чөнки янәшәңдә милләтең, терәгең, таянычың барлыгын тоемлыйсың. Вафирә апаның үзе белән ихластан аралашу, иҗаты белән якыннан танышу миндә шундый хисләр өермәсе уяткан иде. Залны үзенә җәлеп итү, тамашачы белән бөрбөтенгә әверелү бәхете – зур талантлы артистларга гына хас күркәм сыйфаттыр, алар яулаган биеклектер, мөгаен.

Милли моңлы халкыбыз җәүһәрләрен СССРның барлык төбәкләрендә генә түгел, хәтта Германия, Австрия, Америка Кушма Штатлары, Куба сәхнәләреннән яңгыраткан затлы җырчы иде ул. Чирек гасыр дәвамында меңәрләгән чакрымнарга сузылган гастрольләрдән кайтып кермичә, тау астыннан ургылып чыккан чишмәнекедәй көчле, назлы-нәзакәтле, ягымлы тавышы белән җыр-моңга сусаган меңәрләгән милләттәшләребезнең күңелен сугарды, рухын ныгытты. Вафирә үзе дә көчле рухлы, туры сүзле, кыю йөрәкле, кимсетелгәннәрне яклаучы, авыр хәлдә калганнарны кайгыртучы ханым иде. Бу хакта аның элеккеге хезмәттәшләре Флера Сөләйманова, Кирам Сатиев истәлекләрендә тәфсилләп язылган. Ул җөмһүриятебезгә мөстәкыйльлек, халкыбызга азатлык яулаган милли хәрәкәтнең үзәгендә кайнаган куркусыз, башбирмәс холыклы милләтпәрвәр көрәшче, бер үк вакытта шагыйранә нечкә күңеле шәхес булып, халык күңеленә мәңгелеккә уелып калды. «Ирек» мәйданындагы көрәштәшләре, кыю йөрәкле ханымнар – язучы Фәүзия Бәйрәмова, җырчы Гөлзада Сафиуллина аның батырлыгы турында сокланып, горурланып сөйлиләр.

Үзен белә башлаганнан бирле җырлый Вафирә. Аның тәрҗемәи хәленә күз салсак, искиткеч гүзәл гамьнәр гади авыл баласының күңеленә кайдан тупланган? – дигән урынлы сорауга җавап табылыр төсле. Бәлки Чулман буеның әкияти гүзәл табигате, чәчәкле-җиләкле болыннары иҗатка рухландыргандыр аны. Туган авылы Камай инешенең талтирәкләренә кунып сайраган сандугачлары, алтын башаклы иген кырлары өстендә тибрәлгән тургайлар җырын оттымы икән? Әллә үзе сихәтле суын эчеп үскән көмеш сулы чишмәнең челтерәве сизгер кыз бала күңеленә бәлзәм булып тамганмы? Китап җене кагылган кыз туган авылында 8 классны тәмамлагач, Алабуга мәдәни-агарту училищесына юл тота. Диплом алып, туган оясына әйләнеп кайткач, авыл китапханәсендә эшли башлый. Тумыштан килгән сәләте, җыр-моңга гашыйклыгы тышка бәреп чыга, авыл клубында үзешчән сәнгать сөючеләрне туплап, хор оештыра, аның солисты була. Җырга-моңга һәвәс Бондюг чибәркәе, тәвәккәлләп, Казан музыка училищесына юл тота. 1965 елда аны уңышлы тәмамлап, Казан дәүләт консерваториясенә укырга керә, Валентина Лазько классында вокал буенча югары белем ала. 1971 елда Казан телестудиясе төшергән «Идел көйләре» дип исемләнгән фильм-концертта сәләтле студент кыз данлыклы җырчылар Гали Ильясов, Рәхилә Мифтахова, Ренат Ибраһимов, Эмиль Җәләлетдиновлар белән бергә чыгыш ясый. Диплом яклыйсы елында Воронежда узган Бөтенроссия җырчылары бәйгесендә һәм Гаванада булып узган Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивалендә лауреат исемнәренә лаек була, СССР күләмендә оештырылган Ха-

лык җырлары конкурсында җиңү яулый. 1974 елда диплом алгач, нибары бер ел Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында эшләп ала. Ирек сөючән кызга театр режиссеры куып керткән тар кысаларга сыешу авыр тоела. Ул филармониягә күчәргә карар кыла. 1975–1994 елларда Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә намуслы хезмәт куя, әйдәп баручы солистларның берсенә әверелә. 1978 елда Эстониядә РСФСР сәнгате көннәрендә Татарстаннан Нәҗип Җиһанов һәм Вафирә Гыйззәтуллина катнаша, Алла Пугачева, Геннадий Хазановлар белән бергәләп сәхнә күген балкыталар.

Филармониядә узган егерме елга якын вакыт эчендә иҗаты халыкка киң таныла, мактаулы исемнәргә ия була, дөнья гизү бәхетенә ирешә. Барасы юлы анык, изге максаты ачык, яулыйсы офыклары киңәйгәннән-киңәя барган бер мәлдә, усал язмыш җилләре башбирмәс холыклы Вафирәбезнең тез астына китереп суга. 1994 елда Россиянең Чечен республикасына гаскәр кертүенә каршы кискен протест йөзеннән, Камал театры каршындагы мәйданга митингка чыккан халык алдында, Вафирә Рәсәйнең атказанган артисткасы исеменнән баш тарта, таныклыгын тураклап утка ата. Хакимият сәясәтенә каршы кылган гамәле эзсез узмый, аны эштән кыскарталар. Тормыш-көнкүреше авырая, иҗади карьерасына нокта куела. Эстрада бүлеген ябабыз дигән сылтау белән, штат кыскарту дулкынына Флера Сөләйманова, Таһир Якупов, Закир Сафин һ.б.лар эләгә, җәмгысе унбишләп сәнгатькәр урамга чыгарып җибәрелә.

Тозлы маңгай тирен түгеп, фидакарьләрчә баш күтәрми эшләвенә, сокландыргыч һөнәри осталыгына карамастан, Казандагы тормыш-көнкүреше бер дә мактанырлык булмый шул Вафирәбезнең. Кызы Камилә сөйләвенчә, өч кешедән торган гаиләнең ипи белән сөт алырга акчасы калмаган вакытлары аз булмый. Ярдәмгә мохтаҗ кызы белән оныгына, гаиләсенә азык-төлек сатып алу өчен, Вафирә затлы концерт күлмәкләрен чыгарып сатарга мәҗбүр була. Нинди гаделсезлек! Тукай әйтмешли, чын кеше кадере бармыни соң бездә? Каракалпакстандагы гастрольләреннән соң, аңа бу республиканың халык артисты исеме бирелүе мәгълүм. Әлеге җөмһүриятнең җитәкчелеге аны үзләренә эшкә чакыра, мәдәният министры вазифасына алынуын үтенә. Башка берәү булса, ике дә уйламыйча ризалашыр, түрә булып, балда-майда йөзеп яшәр иде. Милли җанлы Вафирәбезнең җавабы катгый була: «Тәкъдимегез өчен рәхмәт, әмма мин үз туган җиремдә,үз халкыма кирәгрәк», – ди ул.

Ут йөрәкле ханым республикабыз халкы бердәм булып суверенлык яулаган, җөмһүриятебезнең язмышы хәл ителгән шанлы 1990-нчы елларда аеруча актив була, дистәләгән протест акцияләренең үзәгендә кайный. Казанның «Ирек» мәйданында ясаган ялкынлы чыгышлары, җыелган

халык каршысына басып, дәртләндергеч хәрби рухлы «Ком бураны» җырын җырлап, кешеләрнең эчке рухын ныгытырга, бирешмәскә, изге максаттан кире чигенмәскә чакыруы исебездән чыкмый. «*Азатлык байрагы, чын хаклык байрагы,Татар халкының үз кулында!*»–дип җырладылар Гөлзада Сафиуллина белән Вафирә Гыйззәтуллина. 1992 елда җөмһүриятебезне тулы азатлыкка ирештерәчәк Татарстан Конституциясен кабул итүләрен Дәүләт советы депутатларыннан таләп итеп, үз гомерен куркыныч астына куеп, трамвай юлы рельсларына аркылы ятуы каһарманлык түгел мени?! Татарстан суверен дәүләт булырга, анда чыгарылган кара алтын-җөмһүрият байлыгы үзебездә калырга тиеш дип, милли каһарманыбыз Марат Мөлекев җитәкчелегендәге бер төркем Әлмәт шәһәре яныннан узучы «Дружба» нефть үткәргеч торбасын ябарга ниятләп, сәфәргә чыга. Аларны кыйнап имгәтәләр. «Зеленая сука», дип типкәләп, Вафирәне паромда яшел яулыгыннан өстерәп йөртәләр. Ул чакта бармакларын каерып сындырсалар да, көрәшче рухын сындыра алмыйлар.

Милләтпәрвәр Вафирә берничә мәртәбә Дәүләт советына депутат булып сайланырга омтылып карый, халыкның хәерхаһлыгына карамастан, хакимияттәгеләр аны уздырмыйлар. «Алар Вафирәнең теленнән курыктылар, дөресен әйтүеннән шүрләделәр... Кат-кат сайлауларда төшеп калганнан соң, Вафирәнең хакимият белән арасы шактый бозылды. Бу хәл аның тормышына, матди хәленә дә бик нык тәэсир ясады. Аны хөкүмәт концертларына чыгармый башладылар, телевидениедән, бирсәләр дә, иске язмаларын гына бирергә тырыштылар. Акча юклыкка чыдый алмыйча, Вафирә радиога ярты ставкага эшкә керде. Бу хәлне белеп алуга, аның пенсиясен туктаттылар, ул чакта шундый тәртип иде. Ә Вафирәнең кулында кызы, оныгы бар бит, аларны ашатырга, киендерергә кирәк. Хәле ничек кенә авыр булса да, Вафирә беркайчан да сер бирмәде. Халык алдына ялт итеп киенеп, елмаеп килеп чыга иде»,–дип искә ала язучы, экс-депутат Фәүзия Бәйрәмова.

Вафирә апа белән очрашкан, якыннан аралашкан вакытларымда, мине бу фидакарь шәхеснең күпкырлы талант иясе булуы аеруча сокландыра иде. Ирләрнекеннән ким булмаган көчле холыклы, кирәк вакытта үз фикерен турыдан ярып салырга сәләтле, җитәкчеләр тарафыннан кыерсытылган сәнгать әһелләренең мәнфәгатьләрен кайгыртып, баласына куркыныч янаганда дошманына ташланган ана арысландай, үз-үзен аямыйча ахыргача көрәшүе, шул ук вакытта түрәләрдән үзе өчен берни дә сорап ала алмаучы, шагыйранә нечкә күңеле гап-гади татар хатыны иде ул. Гадилеге белән галилеге янәшә иде шул аның. Көмеш аскуймага талир тәңкәләр коелышкандагы сыман челтерәтеп көлеп җибәрүләре, кирәк чакта усал итеп «чеметеп» алырга маһирлыгы белән үзенчәлекле

иде ул. Иҗаты һөнәр югарылыкка күтәрелгән, халык мәхәббәтенә ирешкән танылган җырчы, мәҗбүриләп филармониядән чыгарылганнан соң, кирәксезгә калып, очраклы хезмәт хаклары белән очын очка көчкә ялгап, өч ел дәвамында тилмереп яшәде. 1997 елда гына «Татарстан» теле-радио ширкәтенә эстрада оркестры солисты итеп кабул ителә.Анысы да ярты ставкага гына.Өч кешелек гаиләне бу акчага ашатып, яшәтеп, киендереп кара... Гомеренең азагына чаклы шунда хезмәт куя ул. Җырчының кызы Камилә Гыйззәтуллина әнисе турында: «Соңгы елларда аның яшисе килмәде. Дөнья кысаларын тарсындымы, күпме генә өзгәләнсә дә, хәтерсезлек корбаны булу күз алдына килдеме – белмим. Еллар узган саен тормышның тизлеге арта бара, дия иде әни», – дип искә ала.

